ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

Раиф Мәрданов

# ТАТАР КУЛЪЯЗМАЛАРЫНЫҢ ПАЛЕОГРАФИЯСЕ

«МИЛЛИ КИТАП»

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

Раиф Мәрданов

# ГАРӘП ХӘРЕФЛЕ ТАТАР КУЛЪЯЗМАЛАРЫНЫҢ ПАЛЕОГРАФИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2024

**УДК 930.27+821.512.145**
**ББК 63.223.9+83.3(2=632.3)**
**М 90**

**М 90 Раиф Мәрданов.**
**Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре.** – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2024. – 248 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 34 нче китап).

Китап гарәп хәрефле татар кулъязма текстлары белән эшләүчеләргә киңкырлы мәгълүмат бирү һәм аларның гамәли үзенчәлекләре белән берникадәр таныштыру максатында хәзерләнде. Урта гасырлардан алып 1920 нче елларга кадәрге язылыш үзенчәлекләре мисаллар белән аңлатылды.

Ярдәмлек гарәп хәрефләрен танып белүчеләр һәм татар кулъязмаларын гомуми рәвештә булса да күзаллаучылар, шулай ук аларны өйрәнүчеләр өчен тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-88473-108-0**

**УДК 930.27+821.512.145**
**ББК 63.223.9+83.3(2=632.3)**

© Мәрданов Р.Ф., 2024
© «Милли китап» нәшрияты, 2024

# КЕРЕШ

Татар кулъязма китабының һәм гомумән татар кулъязмачылыгының күп гасырлык, искиткеч бай тарихы бар. Галимнәр һәм археографлар тарафыннан дистә меңнәрчә кулъязма истәлекләр хәзерге вакытка кадәр сакланып калган. Алар биниһая зур язма байлыкның рәхимсез тарихи чорлардан бүгенгәчә килеп ирешкән аз микъдары дип бәяләнә. Татар җирлегендә гарәп хәрефләре белән теркәлгән кулъязма ядкярләрнең гомуми язмышын күздән кичереп, галим Миркасыйм Госманов «Безнең көннәргә хәтле сакланып килгән – җыелган һәм әле җыелмаган – кулъязма байлыгыбыз элекке реаль, ягъни тудырылган репертуарның якынча өч-дүрт процентын гына тәшкил итәдер. Артык булмастыр кебек»[1] дип язган иде.

Сүзебез башында бу китапта күп кулланылачак палеография һәм археография терминнарын искә төшереп китү зарур. Палеография – кулъязма чыганакларның тарихи үсештәге үзенчәлекләрен өйрәнә. Палеография язу материалын, язу билгеләрен һәм төрләрен, язу коралларын, кулъязмаларның бизәлешен, язу караларын һәм буяуларын, кәгазьләрдәге су билгеләрен, штемпельләрне, кәгазьнең форматын һәм кулъязма китап тышлыкларын өйрәнә. Археография – тарих һәм тел-әдәбият фәннәренең уртак тармагы. Ул палеографиядән аерылгысыз. Археография язма документларны, кулъязма истәлекләрне туплау, тасвирлау, өйрәнү һәм матбугат мәйданына чыгаруны үз эченә ала.

[1] Госманов М. Үткәннән – киләчәккә: фәнни-публицистик мәкаләләр. – Казан: Татар. китап нәшр., 1990. – Б. 174.

Татар археографиясе дигәндә татарлар тарафыннан иҗат ителгән яки күчереп язылган, татарлар укып файдаланган, гомумән, татар халкының белем-мәгърифәтенә хезмәт иткән, аның рухи дөньясын чагылдырган, татар җирлегендә сакланган кулъязма истәлекләр күздә тотыла. Татар язма ядкярләрен туплау, өйрәнү һәм текстологик тикшеренүләрнең бай тарихы шушы өлкәдә армый-талмый күп еллык хезмәт куйган галимнәр Альберт Фәтхи, Миркасыйм Госманов, Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан нигезле итеп өйрәнелгән[2]. Татар археографиясенең аерым мәсьәләләрен башка галимнәр дә тикшерде. XX гасырның икенче яртысында татар кулъязма мирасын җыю-туплауга күп галимнәр һәм студентлар катнашты.

Археография – күпкырлы гыйльми хәзерлек, сабырлык һәм даими тырышлык таләп итә торган мавыктыргыч фәнни юнәлеш. Татар кулъязмалары 1920 нче еллар ахырына кадәр тулаем, аннан соң 1970 нче елларга хәтле өлешчә гарәп хәрефләре белән язылганлыгын исәпкә алганда, мәсьәләнең никадәр катлаулы булуы тагын да аңлашылыр. Чөнки гарәп, фарсы, госманлы төрек телләрен белү, Ислам дине тәгълиматыннан яхшы ук хәбәрдар булу белән берлектә, гарәп язуының палеографик һәм каллиграфик серләрен аңлау да зарур. Татар язма истәлекләренең фәнни өйрәнелгән хәтлесе бер өлеш булса, өйрәнелмәгән кадәресе йөзләгән өлеш күбрәк. Халкыбызның тупланган язма байлыгы дистә меңнәрне тәшкил итә, тик хәзерге вакытта шул мирасны тирәнтен өйрәнүчеләр бер дистәгә дә җыелмый. Гомумән, татар археографлары элек тә сирәк белгечләр булганнар, хәзер дә шулай. Татар археографиясендә исемнәре

---

[2] Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Тулыл. икенче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 1994. – 463 б.; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – 270 б.; Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Тамга» нәшр., 2007. – 400 б.

киң танылган, үткән гасырлардагы һәм хәзерге дәвернең галимнәре турындагы белешмә-мәкаләләр тупламында XIX гасыр башыннан алып XXI гасыр башына кадәрге 14 белгеч турында язылган иде[3].

Шунысы мөһим – әлегәчә өйрәнелмәгән кулъязма ядкәрләрдә мәдәниятебез тарихы өчен билгесез, ачылмаган күпме серләр, никадәрле фәнни яңалыклар ята.

Хәзерге вакытта татар кулъязма китапларының дистә меңнәрчә күчермәләре, нигездә, Казан, Петербург, Мәскәү һәм Уфа шәһәрләрендәге архивларда, фәнни китапханәләрдә һәм музейларда саклана. Шулай ук Әстерхан, Төмән, Касыйм һ.б. калаларның, Урта Азия, Европа һәм шәрык-мөселман илләренең китапханә, музей һәм архивларында саклана торган татар кулъязмалары да аз түгел.

Татар кулъязмалары турында гомуми мәгълүмат һәм аларны өйрәнү тарихы, үзенчәлекләре, тасвирламалары, шулай ук татар палеографиясе мәсьәләләре Әбрар Кәримуллин, Нил Юзиев, Миркасыйм Госманов, Фазыл Фәсиев, Альберт Фәтхи, Марсель Әхмәтҗанов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Кадыйров һ.б. хезмәтләрендә язылган. Аларның китапларыннан һәм мәкаләләреннән татар археографиясе һәм палеографиясе мәсьәләләре белән танышырга мөмкин. Татар әдәбияты тарихына багышланган күптомлыкларда да гарәп язулы ядкярләргә бәйле мәгълүматлар шактый.

Дистә меңнәр белән исәпләнә торган татар кулъязмаларының палеографик хасиятләре гаҗәеп күп. Һәр кулъязмада ук булмаса да, ике-өч кулъязманың берсендә ниндидер палеографик үзгәлек күренә. Аларның һәммәсенә дә тукталу, аңлатма бирү мөмкин хәл түгел. Без күргән һәм

---

[3] Шәрекъ кулъязмалары: өйрәнелүнең хәзерге торышы һәм алдагы бурычлар: түгәрәк өстәл материаллары (Казан, 2011 ел, 1 декабрь) = Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения: материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.) / сост.: Р.Исламов, С.Галимов. – Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2011. – Б. 211–260.

укыган меңнәрчә кулъязма истәлекләрдәге палеография мәсьәләләренең һәммәсен аңлату-белдерү бу хезмәтнең максаты итеп куелмады. Ешрак очрый торган һәм кулъязма текстлар белән эшләүчеләр өчен читенлек тудырырдай палеографик үзенчәлекләрне гомумиләштереп аңлатырга тырыштык. Кулъязма истәлекләрнең XVI гасырдан алып XX гасырның беренче һәм кайбер очракларда икенче яртысына караган нөсхәләрендәге үзенчәлекләрен игътибар үзәгенә куйдык. Китапта татар кулъязмаларының эшләнешләре, текстологик үзенчәлекләре турында да кыскача мәгълүмат бирелде. Кулъязма истәлекләрдәге палеографик хасиятләрнең мисаллары тәкъдим ителде. Гасырларга һәм чорларга хас кайбер үзенчәлекләре дә аерып күрсәтелде.

Бу китапта кырык елга якын өзлексез кулъязмачылык эшчәнлегемнең гамәли тәҗрибәсе нәтиҗәсендә хасил булган фикерләр һәм күзәтүләр дә бәян ителде. Шул сәбәпле, мисал итеп китерелгән очракларның да шактые үзебезнең эш тәҗрибәсенә нигезләнде. Бу китапта күрсәтелгән гарәп хәрефләрендәге язылыш мисаллары барысы да иске кулъязма истәлекләрдән күчереп тәкъдим ителде.

Хезмәтебез гыйльми диссертация түгел, шунлыктан, бернинди теоретик рaслауларга дәгъва итми. Татар палеографиясенең күпкырлы үзенчәлекләре турында башка галимнәр тирәнтен һәм тәфсиллерәк, тагын да киңрәк мәгълүматлы хезмәтләр язарлар әле.

Үз тарихында берничә төрле графика кулланган татар халкының бу китапта, нигездә, гарәп хәрефле кулъязмаларындагы палеографик үзенчәлекләр тасвирланды. Татар эпиграфик истәлекләренең дә палеографиясе мавыктыргыч һәм гаять кызыклы, үзе аерым бер зур дөнья. Әмма татар ташъязмаларына бәйле мәгълүматларга охшашлыклар һ.б. уртаклыклар булганда гына бу өлкәгә мөрәҗәгать итү белән чикләндек.

Күпчелеге архивларда саклана торган мөселман татар метрикалары да татар кулъязма ядкярләренең зур бер төре. Аларның палеографик үзенчәлекләре башка кулъязмаларныкыннан бик аерылмый. Шулай да, метрикалар билгеле бер мәсьәләгә бәйле булганлыктан, аларның текстологик даирәсе киң түгел. Татар метрикаларының үзләренә генә хас булган кайбер специфик хасиятләренә тукталмадык. (Шөкер, хәзер татар метрика язмаларын укучы белгечләр дистәләгән һәм, ихтыяҗ булса, махсус тикшеренү хезмәте язучылар булыр). Ә тематика һәм жанрлар төрлелеге ягыннан татар археографиясенең башка материаллары, метрика язмалары белән чагыштырганда, чиксез бер галәм кебек.

Китап өч бүлектән тора. Беренчесендә татар кулъязма истәлекләренең төрле мәсьәләләре бәян ителде, икенчесендә аларның язылыш үзенчәлекләре аңлатылды, өченчесендә исә гарәп хәрефләре белән теркәлгән чыганаклар белән эш иткәндә палеографик үзенчәлекләрне исәпкә алмау нәтиҗәләре туплап бирелде.

Китапханәләрдәге, архивлардагы һәм музейлардагы татар кулъязмаларын өйрәнүчеләр, аларга мөрәҗәгать итүчеләр киләчәктә дә, һичшиксез, булачак. Фәннең катлаулы бу тармагы белән кызыксынучыларга әлеге хезмәтнең күпмедер файдасы булыр дип өметләнәбез.

***

Бу хезмәтебезне басмага хәзерләгәндә күрсәткән зур ярдәмнәре өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсе директоры урынбасары Ирек Һадиевка, китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллинга, Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге мөдире Энҗе Сабировага ихлас рәхмәтләремне белдерәм.

# I БҮЛЕК: ГОМУМИ МӘСЬӘЛӘЛӘР

## Иске татар палеографиясенә караган хезмәтләр

XX гасырның икенче яртысыннан алып хәзерге чорга кадәр гарәп хәрефләрендәге иске татар язмачылыгын өйрәтүгә багышланган дәреслекләр, ярдәмлекләр һәм гамәли кулланмаларны[4] искә алып китү зарур. Мәсәлән, татарларда гарәп язуының кулланылу тарихы һәм аның төп үзенчәлекләре галим Хәлиф Курбатовның махсус хезмәтендә тәфсилләп аңлатылган[5]. Ул гарәп алфавитының тугызынчы гасырда – ислам дине белән бергә кабул ителүен белдереп, «...бу алфавитның аннан элегрәк – фарсылар аркылы сәүдә мөнәсәбәтләре нәтиҗәсендә килеп кергәнен әйтүчеләр дә бар» дип искәрткән[6]. (Галимнәр билгеләвенчә, болгар кабиләләренә гарәп язуы VIII гасырның икенче яртысында керә башлаган).

Курбатов хезмәтендә гарәп алфавитының татар язуы өчен кулланылган хәрефләре, хәрәкәләр, имля үзенчәлекләре һәм аның тотрыксызлыгы, язылыш вариантлары, татарлар өчен алфавитны камилләштерү фикерләре һәм тәкъдимнәре, совет чорындагы орфографик кагыйдәләр һ.б. бик җентекләп язылган.

Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе кулъязмаларының тасвирламасы

---

[4] Андый хезмәтләрнең бөтенесен дә биредә тасвирлап чыгу максаты куелмады.

[5] Курбатов Х. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. – Казан: Татар. китап нәшр., 1960. – 130 б.

[6] Шунда ук. – Б. 25.

буларак нәшер ителгән белешмә хезмәтләрнең, аерым алганда археограф галим Альберт Фәтхи төзегән «Татар әдипләре һәм галимнәренең кульъязмалары» дип аталган дүрт чыгарылышның (1960, 1962, 1968, 1986) әһәмияте чиксез зур булды. 1968 елда нәшер ителгән китапның кереш мәкаләсендә А.Фәтхи болай дип язган: «Бу тасвирлама университетның татар филологиясе бүлегенең укыту эшендә файдалану өчен методик ярдәмлек, кулланма буларак төзелде. «Татар әдәбияты тарихы» (Борынгы чор һәм XIX гасыр), «Татар әдәби теле тарихы», «Борынгы татар теле» кебек курсларны укытканда татар теле һәм әдәбияты тарихының төп чыганаклары – борынгы кульъязмалар белән эшләргә өйрәтү дә күз алдында тотыла...»[7]. Билгеле булганча, Альберт Фәтхи 1960 нчы елларда университет студентларына «Кульъязма чыганаклар белән эшләү», «Иске татар теле» һәм башка махсус курсларны укыткан. Ул хәзерләгән тасвирламалар хәзерге вакытка кадәр белгечләр өчен бик файдалы һәм алыштыргысыз ярдәмлек булып хезмәт итә.

Гаяз Ишмөхәммәтевнең 1961 елда университет нәшриятында дөнья күргән «Гарәп графикасы нигезендә татарча әлифба» кулланмасы, үзендә әйтелүенә караганда, «татар әдәби теле һәм тюркология тарихын өйрәнүче студентлар һәм яшь гыйльми эшчеләргә ярдәмче материал буларак»[8] төзелгән. Анда 1919–1924 еллардагы әлифба, методик аңлатмалар, уку өчен текстлар (Г.Тукай, М.Гафури һәм К.Насыйри кульъязмаларының факсимилеләре), матур язу күнегүләре бирелгән.

Казан дәүләт университетының Татар теле кафедрасы тарафыннан 1965 елда 300 данә тираж белән бастырып чы-

[7] Кульъязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш: Татар әдипләре һәм галимнәренең кульъязмалары. Өченче бүлек / төз. А.Фәтхи. – Казан: ун-т нәшр., 1968. – Б. 9.

[8] Ишмөхәммәтев Г. Гарәп графикасы нигезендә татарча әлифба: уку-язу күнекмәләре (гарәп әлифбасы нигезендә). – Казан: ун-т нәшр., 1961. – Б. 3.

гарылган (исеме рус телендә бирелгән) иске татар теле буенча текстлар җыентыгын[9] әйтергә кирәк. Күләме 78 битле бу җыентыкның төзүчесе Альберт Фәтхиев, җаваплы редакторы Мостафа Ногман булган. Анда Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә» поэмаларыннан басма гарәп хәрефләрендәге өзекләр бирелгән, шул текстлардагы график үзенчәлекләргә аңлатмалар язылган, Шәмсетдин Зәки, Мәүла Колый, Габделҗәббар Кандалый шигырьләреннән үрнәкләр урын алган. Аксак Тимер турындагы дастанның тулы тексты, Сабан туен тасвирлаган язма, мәкальләр һәм ике әкият тексты тәкъдим ителгән.

Университетның Татар әдәбияты кафедрасы басмалары буларак студентлар өчен татар әдәбияты тарихы буенча 1966, 1967 һәм 1970 нче елларда нәшер ителгән өч җыентык[10] та кызыклы. Аларның беренчесе Сәйф Сараиның «Гөлстан» тәрҗемәсе җыентыгындагы шигырьләрнең Венгрия Фәннәр академиясе бастырып чыгарган кулъязма факсимилесеннән бер өлешен һәм хәзерге графикадагы бирелешен тәшкил итә. Икенчесендә күпчелеге XVIII гасырга караган, беразы XIX гасыр кулъязмаларындагы шигырьләр, җырлар һәм бәетләр хәзерге татар язуына күчермәдә һәм факсимилеләр итеп туплап бирелгән. Өченче китапта исә Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» әсәренең кулъязма күчермәләреннән алынган тексты хәзерге графикада, кереш мәкалә, искәрмә һәм аңлатмалар, сүзлек белән тулыландырып басылган.

---

[9] Тексты по старотатарскому языку / сост. А.Фатхиев. – Казань: офс. лаб. Казан. ун-та., 1965. – 78 с.

[10] Татар әдәбияты тарихыннан студентларның практик дәресләре өчен материал / төз.: Х.Госман, З.Максудова. – Казан: ун-т тип., 1966. – 40 б.; Татар әдәбияты тарихыннан студентларның практик дәресләре өчен уку материалы / төз.: Х.Госман, З.Максудова. – Казан: ун-т тип., 1967. – 100 б.; Татар әдәбияты тарихыннан студентларның практик дәресләре өчен уку материаллары / төз.: Х.Госман. – Казан: ун-т тип., 1970. – 68 б.

Алтын Урда чоры шагыйре Котбның 1342 елда фарсы теленнән тәрҗемә иткән «Хөсрәү вә Ширин» поэмасының тексты гарәп хәрефләре белән машинкада басылып, 1970–1971 елларда студент-тюркологлар өчен кулланма рәвешендә ике китапта дөнья күргән[11]. Аны әсәрнең Парижда – Франция Милли китапханәсендә саклана торган 1383 елгы кульъязма күчермәсе нигезендә профессор Хатыйп Госман һәм Зәйнәп Максудова басмага хәзерләгәннәр. Китапларның бит саннары тоташ куелган булып, ике кисәгенең гомуми күләме 440 битне тәшкил иткән.

Казан дәүләт университетында татар филологиясе белгечлеге буенча белем алучы студентлар өчен Мостафа Ногманның 1971 елда басылып чыккан «Иске татар язуы үрнәкләре»[12] дигән хрестоматиясе төп кулланмаларның берсе булып хезмәт иткән. Гомуми күләме 218 битне тәшкил иткән бу җыентык дүрт бүлектән тора: «Укыргаязарга өйрәтү нигезләре», «Яңартылган орфография үрнәкләре», «Иске әдәбият үрнәкләре» һәм «Кульъязмалардан үрнәкләр».

Әлеге китапның беренче бүлегендә гарәп әлифбасын өйрәтү дәресләре һәм гарәп хәрефләрендәге текстлар урын алган. Анда Г.Тукай һәм Дәрдмәнд шигырьләре, Ф.Әмирхан һәм Г.Ибраһимов әсәрләреннән өзекләр басма гарәп хәрефләрендә бирелгән. Шунысы игътибарга лаек – Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыре бу китапта тулы

---

[11] Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте: студент-тюркологлар өчен дәреслек = Книга рассказов о Хосрове и Ширин: пособие для студентов-тюркологов. – Казань: офс. лаб. КГУ, 1970. – 220 б.; Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте: студент-тюркологлар өчен дәреслек = Книга рассказов о Хосрове и Ширин: пособие для студентов-тюркологов. Икенче дәфтәр. – Казань: офс. лаб. КГУ, 1971. – 221–440 б.

[12] Ногман М. Иске татар язуы үрнәкләре: югары уку йортларының филология бүлеге студентлары өчен уку китабы. – Казан, 1971. – 218 бит.

рәвештә – ягъни, дога сүзләре язылган соңгы строфасы да кертеп басылган[13].

Икенче бүлегендә шулай ук басма хәрефле текстлар (Гали Рәхим мәкаләсе, Ф.Әсгать, К.Рәхим әсәрләре һәм М.Ногман поэмасыннан өзек) яңа имляда бирелгән. Өченче бүлектә иске татар әдәбияты үрнәкләре – Ф.Халиди, К.Насыйри, Х.Мөслими, Г.Утыз Имәни, Мөхәммәдьяр, Котб, Кол Гали, Хәрәзми әсәрләреннән өзекләр тәкъдим ителгән.

Китапның дүртенче бүлегендә төрле чорлардагы кульъязмалардан үрнәкләр һәм аларның текстлары басма гарәп хәрефләрендә бирелгән. Анда РСДРПның 1905 елгы прокламациясе, Г.Тукай, Һ.Такташ, Хәсәнгата Габәши, Нугай морзаларының хатлары, С.Рәмиев шигыре, К.Насыйри хезмәтеннән өзек, Пугачёв чорына бәйле документлар, XVII гасырдагы дипломатик грамоталарның факсимилеләре һәм текстлары урын алган. Тиражы 500 данә булган әлеге кызыклы җыентык, үз заманына күрә, бик яраклы булып, вазифасын уңышлы үтәгән.

Әдәбият галиме, Шәрыкне өйрәнүче Габдрахман Таһирҗанов китабында гарәп язулы борынгы чор палеографиясенә караган әһәмиятле фикерләр һәм тәфсилле аңлатмалар шактый[14].

Сәйф Сараиның ике кисәктән торган, Хатыйп Госман һәм Зәйнәп Максудова тарафыннан хәзерләнеп, Казан университеты нәшриятында бер мең данә тираж белән 1980

---

[13] Билгеле булганча, Совет хакимлеге заманында бу шигырьнең соңгы дүртьюллыгы еш кына төшереп калдырылган. Шул хактагы белешмәгә мөрәҗәгать итик: «...Атеистик Совет чорында, бигрәк тә мәктәпләр өчен басылган җыентыкларда шигырьнең Аллага мөрәҗәгать иткән соңгы юллары төшереп калдырыла килде... Демократик үзгәрешләр, азатлык өчен көрәш чорында «Туган тел» тулы килеш басыла башлый» // Габдулла Тукай. Энциклопедия. – Казан: Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты, 2016. – Б. 640.

[14] Таһирҗанов Г. Тарихтан – әдәбиятка. – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – 168 б.

елда басылып чыккан «Гөлстан бит-төрки» китабын[15] да искә алырга тиешбез. Ул – мәшһүр шагыйрь Сәгъди иҗат иткән әсәрнең 1391 елда башкарылган ирекле тәрҗемәсе. Бу әсәрнең ахырында Сараи үзенең һәм башка чордаш шагыйрьләренең лирик шигырьләрен дә урнаштырган. Әлеге басманың ике кисәге дә каллиграф Рәшит Кадыйров тарафыннан гарәп хәрефләрендә бик күркәм итеп күчереп язылган.

Китапның кыска гына кереш сүзендә Сараи әсәренең Лейден (Һолландия) университеты китапханәсендә саклана торган күчермәсенең фотокопиясе нигезендә 1960 нчы елларның икенче яртысында ук бастырырга хәзерләнгән булуы әйтелгән, 1968 елда Ташкент, 1969 елда Будапешт басмаларының дөнья күрүе нәтиҗәсендә кичегүенең сәбәпләре күрсәтелгән. Ул басмаларда төп чыганактан аермалы (ялгыш) укылган сүзләрнең таблицасы да китапта бирелгән.

1983 елда Миркасыйм Госмановның университет студентлары өчен иске татар язуы нигезләре буенча ярдәмлегенең беренче кисәге басылган[16]. Анда гарәп хәрефләренә нигезләнгән иске татар язуының тарихы, аны өйрәнүнең әһәмияте, уку-язу һәм куллану кагыйдәләре тәфсилләп аңлатылган, хәрефләрнең язылыш таблицалары урнаштырылган. Ярдәмлектәге гарәп алфавиты һәм хәрефләрнең язылыш үрнәкләре каллиграф Рәшит Кадыйров тарафыннан башкарылган.

Казан дәүләт университетының тарих факультетында

---

[15] Сәйф әс-Сарайи. Китабе Гөлстан бит-төрки = Сайф эс-Сараи. Гулистан бит-тюрки / подг.: Х.Усманов, З. Максудова. Ч. I. – Казань: изд-во ун-та, 1980. – 138 б. Сәйф әс-Сарайи. Китабе Гөлстан бит-төрки = Сайф эс-Сараи. Гулистан бит-тюрки / подг.: Х.Усманов, З. Максудова. II часть. – Казань: изд-во ун-та, 1980. – 124 б.

[16] Госманов М. Иске татар язуы нигезләре: студентлар өчен методик кулланма-таблицалар. Беренче кисәк. – Казан: ун-т нәшр., 1983. – 34 б.

укыган студентлар тарафыннан «Татар палеографиясе буенча альбом» дип аталган, 17 биттән гыйбарәт, төрле кульъязма үрнәкләре тупланган ярдәмлек практик дәресләр өчен файдаланылганын искәртик. Әлеге альбомның үзендә аның кайсы елда басылган булуы, кем тарафыннан төзелгәнлеге һәм башка мәгълүматлары күрсәтелмәгән. 1980 нче еллар уртасында хәзерләнгән бу ярдәмлек, мөгаен, М.Госманов тарафыннан 1983 елда бастырылган китапчыкның икенче кисәге буларак дөнья күргәндер. Чөнки 1983 елда нәшер ителгән «беренче кисәк»нең «икенче кисәк» дип аталган башка басмасы чыкмаган. Альбомда бәетләр, шигъри өзекләр («Кыйссаи Йосыф»тан, Г.Кандалый һ.б.), Г.Тукайның һәм Х.Фәезхановның хатлары, Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә»сеннән бер бит, Бәхтияр Канкай улына язылган «рипурт» кульъязмаларының факсимилеләре урын алган.

1983 елда басылган «Кыйссаи Йосыф» китабында поэма күчермәләренең тасвирламаларына багышланган шактый күләмле махсус бүлек урын алган. Анда кульъязма истәлекләр белән кызыксынучылар өчен күп мәгълүмат тупланган, шул исәптән күчермәләрнең төрле палеографик хасиятләре дә (кәгазе, язу төре, үзенчәлекләре һ.б.) күрсәтелгән[17].

Тарихчы галим, археограф Миркасыйм Госмановның 1984 елда нәшер ителгән «Каурый каләм эзеннән» китабында татар археографиясе һәм палеографиясенең шактый мәсьәләләре мавыктыргыч итеп хикәяләнгән иде. Китапның тулыландырылган икенче басмасы 1994 елда дөнья күрде, анысында мәгълүмат тагын да әтрафлырак.

Казан дәүләт университетында гарәп һәм фарсы телләрен, шулай ук иске татар телен укыткан Җәмил Зәйнуллинның

---

[17] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) = Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе) / төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кульъязмаларның тасвирламасын язучы Ф.С.Фәсиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – Б. 426–494.

студентлар өчен хәзерләп бастырган «Гарәп язуы төрләре» исемле махсус ярдәмлеге 1988 елда чыккан иде.

Җәмил Зәйнуллинның гарәп әлифбасын үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен хәзерләгән һәм 1989 елда дөнья күргән дәреслеге[18] халкыбызның милли һәм рухи күтәрелеше чорында иң күп файдаланылган, гаять популяр китапларның берсе булды. Беренче басмасы 300 мең данә тираж белән чыккан китапның, студентларны укыту өчен кулланылуы белән бергә, гарәп язуына өйрәнергә теләгән һәркем өчен дә ярдәме, һичшиксез, зур иде. Бу китапта, гарәп хәрефләрендә язылган татарча текстларны укырга өйрәтү нигезләре, әдәби әсәрләр, халык авыз иҗаты әсәрләре һәм гарәп хәрефләрендәге башка төр басма текстлар, гарәп язуының каллиграфик үрнәкләре һәм алар турында мәгълүмат, кульъязма истәлекләрнең аерым факсимилеләре урын алган.

Югарыда саналган хезмәтләр гарәп язуындагы татар палеографиясе буенча үз вакытларында, һичшиксез, зур файда китергәннәр.

Кульъязма чыганакларга турыдан-туры бәйле, үзенчәлекле тагын ике басманы искә алырга тиешбез. Беренчесе – Пугачёв күтәрелеше вакытындагы, гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган өндәмәләр һәм документлар җыентыгы[19]. 1988 елда басылып чыккан бу китапта архивларда саклана торган, 1773–1775 елларга караган 188 язма документ текстлары гарәп хәрефләрендә һәм русчага тәрҗемә ителеп, искәрмәләр-аңлатмалар белән тулыландырылып бирелгән. Китапның гарәп хәрефле текстларын каллиграф Рәшит Кадыйров язган. Икенче китапта «Кәлилә вә Димнә» исемле борынгы фольклор әсәре, XVI гасыр

---

[18] Зәйнуллин Җ. Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба: үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен. – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – 112 б.

[19] Воззвание и переписка вожаков пугачевского движения в Поволжье и Приуралье / сост.: Усманов М.А., Алишев С.Х., Гилязов И.А., Хисамова Ф.М.; каллиграф Кадыров Р.М. – Казань: изд-во ун-та, 1988. – 464 с.

кулъязмасыннан күчерелеп, гарәп хәрефләрендә 1996 елда дөнья күрде[20]. Бу китаплар – элекке язма истәлекләрне өйрәнү ихтыяҗы ягыннан бик кирәкле, файдалы һәм кызыклы хезмәтләр. Әмма аларның текстлары хәзерге татар язуында һәм телендә бирелмәгән булуы, безнең карашыбызча, зур җитешсезлек. Чөнки татарлар өчен һәм татар телендә язган татар кешеләренә хөрмәт йөзеннән әлеге мирас истәлекләрен үз телебездә бастыру зарур иде. («Кәлилә вә Димнә» китабының кереш мәкаләсе 2,5 бит чамасы гына икәнлеген дә әйтергә кирәк).

Рәшит Кадыйров татар палеографиясенә багышланган гыйльми хезмәт язып, 1999 елда тарих фәннәре кандидатлыгы диссертациясен яклаган иде[21]. Әлеге кыйммәтле фәнни хезмәт китап рәвешендә басылып чыкса, галимнәр өчен дә, студентларга һәм, гомумән, мондый мәсьәләләр белән кызыксынучыларга файдасы зур булачагы бәхәссез.

Кадыйров хезмәтендә Идел-Урал буйларындагы язма истәлекләрнең палеографиясе, һичшиксез, тирәнтен өйрәнелергә, бу юнәлештә XIX–XX гасырлардагы эпиграфик һәм кулъязма чыганаклар да тәфсилләп тикшерелергә тиешлеге әйтелгән. Ул эпиграфиканы һәм кулъязмаларны җентекләп өйрәнү болгар-татар палеографиясе буенча махсус дәреслекләр өчен нигез хасил итәр һәм аның гамәли әһәмияте зур булыр иде, дип белдергән[22].

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 1972–2012 еллардагы археографик эзләнүләре нәтиҗәсендә табылган кулъязма истәлекләрнең тасвирларын археограф

[20] Кәлилә вә Димнә: хикәятләр / төз. Җ.Зәйнуллин. – Казан: Мәгариф, 1996. – 271 б.

[21] Кадыров Р. Источники по истории старотатарской письменности (XIII–XVIII вв.) и их палеографические особенности. – Дисс. ... канд. истор. наук. – Казань, 1999. – 220 с.

[22] Шунда ук. – Б. 167–168.

һәм татар әдәбияты тарихы галиме Марсель Әхмәтҗанов аерым китаплар итеп бастырды. Алар барлыгы сигез кисәк итеп 2011–2016 елларда нәшер ителделәр[23]. Әлеге тасвирламаларда палеографик үзенчәлекләргә дә әһәмият бирелгән.

Казан федераль университеты галимнәре – тарихчылар Җәүдәт Миңнуллин белән Эльмира Сәлахованың студентлар өчен кулланма рәвешендәге махсус хезмәте 2014 елда дөнья күрде[24]. Китапта гарәп хәрефләренә нигезләнгән татар палеографиясе буенча этрафлы мәгълүмат тупланган. Анда татар кулъязмаларының кайбер гомуми үзенчәлекләре, төрки-татарларда язмачылык тарихы, гарәп язуының төрләре, язу материаллары, филиграньнәр, каләм, кулъязма китапның үзенчәлекләре, эшләнеше һәм бизәлеше, эпиграфика, текстология һ.б. мәсьәләләр турында язылган, гарәп хәрефләрендәге басма һәм кулъязма текст үрнәкләре тәкъдим ителгән. Бу китап татар кулъязмалары турында нигезле мәгълүмат алу өчен, һичшиксез, бик файдалы. Хезмәтнең авторлары: «Әлбәттә, югарыда язылганнар гына иске язуыбызның барлык үзенчәлекләрен тасвирлап бетерә алмый. Иске язуыбызның күпчелек хосусиятләрен бары тик озак вакытлар дәвамында практик эшчәнлек нәтиҗәсендә генә үзләштерергә мөмкин»[25], – дип, бик хаклы искәрткәннәр.

1990 нчы елларда һәм 2000 нче еллар башында халкыбызның рухи, милли һәм фәнни күтәрелеше чорында – татар кулъязмаларын өйрәнергә тиешле яшь белгечләргә ихтыяҗ булган вакытта – татар палеографиясен киңрәк

---

[23] Ахметзянов М. Татарская археография. Отчеты о результатах археографических экспедиций (1972–2010 гг.). Часть 1. – Казань, 2011. – 188 б.; Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе: соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кулъязмаларның тасвирламалары (1972–2012 еллар). Алтынчы кисәк. – Казан, 2016. – 211 б. һ.б.

[24] Миңнуллин Җ., Сәлахова Э. Иске татар язуы: уку-укыту кулланмасы. – Казан: «Яз» нәшр., 2014. – 216 б.

[25] Шунда ук. – Б. 46.

рәвештә өйрәтү-укыту өчен тәфсилле дәреслек яки ярдәмлек булмавы үзен бик сиздергән иде. Моның шулай икәнлеген ул елларда үзем дә Казан дәүләт университетында һәм Татар дәүләт гуманитар институтында «Иске татар теле» һәм «Татар палеографиясе» курсларын студентларга укытканда шәхси тәҗрибәмдә ачык белдем. Ул чорда студентларга гарәби кульязмаларның серләрен өйрәтү буенча дәреслек-ярдәмлек хәзерләргә ниятләп талпынган идем талпынуын. Ләкин башка бер коллегабыз «мин аны үзем эшлим» дигәч, ул вакытта тыелып калдым[26].

Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «Татар археографиясе» сериясе нәшер ителә башлагач ук, күздә тотылган басмалар турында әлеге сериянең кереш мәкаләсендә язып, татар палеографиясе буенча практик ярдәмлек хәзерләргә ниятләвебезне белдердек[27]. Шунлыктан, бу мәсьәлә көнделебездә бер бурыч кебек торды. Инде аның да нәүбәте җитте – менә бу хезмәт элекке ниятебезнең хәзерге вакыткача кичегеп килгән нәтиҗәсе.

2008 елдан башлап хәзерге вакытка кадәр, һәр елда икешәр китап рәвешендә «Татар археографиясе» сериясендә Татарстан Милли китапханәсе тарафыннан нәшер ителеп килә торган басмаларда палеография мәсьәләләренә дә әһәмият бирелде. Бу сериядән хәзерге вакытка кадәр дөнья күргән 33 китапның һәммәсендә диярлек гарәп хәрефләре белән язылган татарча текстларның археографик һәм палеографик үзенчәлекләренә игътибар ителде, шулай ук кульязмаларның тасвирламалары урын алды. Сериядәге аерым басмаларда XVII–XX гасырлардагы татар кульязмаларының факсимилеләре тәкъдим ителүе – язма ми-

[26] Бу хакта элегрәк язган идек: Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр..., 2007. – Б. 351.

[27] Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2008. – Б. 7.

расыбызны киңрәк күзаллау, белмәгән нәрсәләрне өйрәнү-төшенү, белгәннәрне шомарту өчен – гомумән, гамәли яктан да файдалы. «Татар археографиясе» сериясе басмаларында урын алган, палеографиягә караган мисалларның берникадәр өлеше шушы китапта да искә алыначак.

Безнең бу китап, алда әйтеп үтелгән Ж.Миңнуллин белән Э.Сәлахова кулланмасындагы кебек мәсьәләләргә багышланганга күрә, кайбер кабатлаулар һәм охшашлыклар булачагы табигый. Университет галимнәренең китабында тәфсилле язылган мәсьәләләрнең кайберләре монда гомуми тасвир рәвешендәрәк яисә ихтыяҗга күрә генә телгә алынды.

## Язу материалы

Безнең җирлектә язу материалы буларак иң әүвәл каен агачының кайрысы – каен тузы кулланылган дип, шикләнмичә әйтергә мөмкин. Тарихчы Рәшит Кадыйров Биләр каласы урынында археологик эшләр вакытындагы табылдыкларга нигезләнеп, Болгар дәүләтендә язу материалы булып иң башта, күрәсең, каен тузы кулланылган дип язды[28]. Алтын Урда заманында да кәгазьдән тыш каен тузын файдаланганнар[29].

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә кәгазьнең барлыкка килгән вакыты, аның аталышы белән бергә, каен тузы һәм аңа язылган татар текстлары турында да мәгълүмат бирелгән[30]. Автор Идел буендагы археологик казулар вакытында тузга язылган текстлар табылуын да искәрткән, «Степан Разин кузгалышы вакытында Иштирәк абызның татар

[28] Кадыров Р. Источники по истории старотатарской письменности..., 1999. – С. 23.

[29] Абзалов Л. Ордынская канцелярия. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – С. 241.

[30] Тимергалин А. Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек. 3 томда. 2 т.: Й–Р хәрефләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 2017. – Б. 116–117.

халкына өндәмәләре каен тузына язылган була (кайберләре сакланган)»[31] дип белдергән.

Һәрхәлдә, каен тузының язу материалы буларак кулланылганлыгы тарихта билгеле. Халкыбызның «тузга язмаганны сөйләмә» дигән әйтеме – шуның ачык дәлиле. Үткән гасырлардагы догалык китапларында да «тузга язу» гыйбарәсе очрый. Мәсәлән, XIX гасыр башына караган бер җыентыкта «һәр кем ирсәнең нәрсәсе юк булса, тузга бу доганы битеб утка салсын...» дигән сүзләр бар[32].

Кәгазьнең тарихын кыскача гына искә төшереп үтик. Аны хәзерләү Кытайда безнең эраның 105 нче елында башланган. III гасырда Көнчыгыш Төркестанда да кәгазь ясауга керешкәннәр. Урта Азиядә кәгазь җитештерү киңәйгән, бигрәк тә, «Сәмәрканд кәгазе» мәшһүр булган һәм ул күп территорияләргә таралган. Бу кәгазь яхшы сыйфатлы, чыдам булганлыктан, аның бәясе дә кыйммәт торган. Даими һәм туктаусыз сугышлар нәтиҗәсендә XVI–XVIII гасырларда Сәмәрканд кәгазен җитештерү кимегән, XIX гасырга таба бөтенләй бетә язган.

Гарәпләргә кәгазь 751 елда Урта Азиядә әсирлеккә төшкән кытайлылардан кергән. VIII гасыр ахырында Гыйракта кәгазь җитештерү җайга салынган. Бәгъдадта беренче кәгазь фабрикасы 794 елда төзелгән, Мисырда 800 елда, Андалузиядә (Көньяк Испаниядә) 950 елда эшли башлаган. Кәгазь җитештерүнең башлануы мөселманнарда фәннең

---

[31] Бу мәгълүматның кайдан алынган булуы безгә билгесез. Тарихчы Сәлам Алишев китабында болай диелгән: «...бер документта Иштирәк абыз Степан Разинга кушылырга үгетли һәм шул турыда русча, татарча хатларны юкә кайрысына төреп ком өстенә куеп калдыра» (Алишев С. Каһарман бабайлар: Татар крестьяннарының сыйнфый һәм милли азатлык хәрәкәте тарихыннан очерклар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1976. – Б. 23).

[32] Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендә «8144т» шифры белән саклана торган кульъязма, 2а кәгазь. *Кем ирсә* – кеше, берәү; *битеб* – язып.

үсешенә этәргеч булган – китапларның бәяләре төшкән, китапханәләр барлыкка килгән. Шул рәвешчә, кәгазьнең барлыкка килүе Кытайда булса, аны фабрика технологиясе белән җитештерү гарәп галимнәренең казанышы дип санала. Шуны да искәртергә кирәк, хәзерге вакытта дөньяда 630 мең тирәсе гарәп кульязмасы бар.

Гарәпләрдән Европага Димәшкъ кәгазьләре X гасырда үтеп керә башлаган һәм андагы пергаментны кысрыклап чыгарган. XV–XVI гасырларда Европада кәгазь җитештерү күбәйгән. Россиядә кәгазьне күпләп эшләп чыгару император Пётр Беренче чорында башланган.

Идел буе Болгар дәүләтендә Гыйрактан, Кытайдан һәм Һиндстаннан килгән кәгазьләр кулланылган дип язалар галимнәр. Алтын Урда[33] һәм аннан соңгы татар ханлыклары чорында шәрык мөселман һәм Урта Азия илләрендә эшләнгән кәгазьләр кулланылган. XVI–XVII гасырларда мөстәкыйль дәүләтчелектән мәхрүм ителгәч һәм гасырлар дәвамында урнашкан сәүдә мөмкинлекләре киселгәч, татарларда язу эшләре өчен рус дәүләтенә Европадан (башлыча Франция белән Һолландиядән) кергән яхшы сыйфатлы юка кәгазьләр файдаланылган. Сакланган чыганаклардан күренгәнчә, XVIII гасыр башындагы татар кульязмаларының күпчелеге Һолландия кәгазендә.

XVIII гасырда Россиянең үзендә кәгазь җитештерү эше гамәлгә куелгач, татарлар да ил эчендә эшләнгән кәгазь материалын, шулай ук Европадан һәм Урта Азиядән китертелгән кәгазьләрне файдаланганнар.

1780–1790 нчы елларда татар сәүдәгәрләре һәм байлары тарафыннан да кәгазь мануфактуралары оештырылган.

[33]Алтын Урда чорындагы төп язу материалы – кәгазь һәм аның эшләнгән урыннары, төрләре, форматлары һәм башка үзенчәлекләре турында тулырак карагыз: Усманов М. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. – Казань: изд-во ун-та, 1979. – С. 88–89; Абзалов Л. Ордынская канцелярия..., 2013. – С. 235–241.

Аларның продукциясе, нигездә, Урта Азиядән китерелгән мамык чималыннан эшләнгән һәм, гадәттә, аксылрак төстә булган. Мөхәммәт Рәхимов 1789 елдан, Монасыйп Мәмәтов 1798 елдан, Мөхсин Хуҗасәетов 1815 елдан, шулай ук Үтәмешевләр һ.б. бу хезмәтне гамәлгә ашырганнар. Мәшһүр сәүдәгәрләр һәм җәмәгать эшлеклеләре Үтәмешевләр нәселенең Бөр елгасы буена урнашкан Мәчкәрә авылындагы (хәзерге Татарстанның Кукмара районында) кәгазь җитештерү фабрикасы XIX гасырда да шактый вакытлар эшләп килгән. Анда эшләнгән кәгазьне татарлар «Бөр буе кәгазе» дип йөрткәннәр[34]. XVIII гасырның соңгы чирегеннән алып XIX гасыр урталарына кадәр Мәчкәрә мәдрәсәсендә күчерелгән кульъязма истәлекләрне (ә андыйлар китапханәләрдә шактый саклана) махсус өйрәнгән очракта Үтәмешевләр карамагында эшләнгән кәгазь төре турында тулырак мәгълүмат күзаллануы мөмкин.

Шулай итеп, Идел-Урал буе татарларында XIX гасырның беренче яртысында, күбрәк рус мануфактураларының кәгазьләре белән беррәттән, татар җитештерүчеләре хәзерләгәннәре, өлешчә Урта Азиянеке һәм Европаныкы кулланылган.

XIX гасырның беренче чирегенә хәтле диярлек рус мануфактураларында эшләнгән кәгазьләр шактый түбән сыйфатлы (бик калын һәм өслекләре тупас, кытыршы). Рус кәгазьләре, гадәттә, соры һәм соргылт төсләрдә, ә якынча 1780–1825 нче елларда берникадәр өлеше, чималга бакыр купоросы кушылуы сәбәпле, яшькелт-зәңгәрсу (төгәлрәк әйткәндә, XVIII гасырның соңгы чирегендә – ачык күк төстә, ә XIX гасыр башында – зәңгәр) төстә булган. Кәгазьләрнең мондый хасияте – кульъязмаларның вакытын-датасын билгеләү өчен бер дәлил булып торуы ягыннан әһәмиятле.

---

[34] Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2018. – Б. 12–13, 20.

Россиядә кәгазь җитештерүдә 1820 нче елларда машиналар һәм чимал итеп целлюлоза кулланыла башлаган, шул сәбәпле сыйфат ягы камилләшә барган. Кәгазь табакларына 1828 елдан җитештерелгән фабрикасын белдергән махсус штемпельләр төшерелә башлаган. XIX гасырның икенче яртысында Россиядә хәзерләнгән кәгазь материалы инде шактый яхшы сыйфатка ирешеп, сәүдә мәйданында күп төрле сортлары пәйда булган.

Шуны искәртергә кирәк, сугыш вакытларында дары ясау өчен кәгазь күп кулланылганга күрә, матбугат басмаларының һәм язу кәгазьләренең сыйфатлары шактый начар булган. Моның шулай икәнлеген Беренче һәм Икенче Бөтендөнья сугышлары вакытларындагы китаплар, газета-журналлар, шулай ук төрле язу эшләренә (көндәлекләр, куен дәфтәрләре, хатлар һ.б.) кулланылган кәгазьләрдән күрергә мөмкин.

Сирәк булса да, татар кульязмаларының ефәккә яисә башка тукымага кара белән язылган очраклары да булган. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «324г.(266)» шифры белән саклана торган, XIX гасыр ахырына нисбәтле, 52х72 см зурлыгындагы ефәккә язылган дини текст шундыйлардан.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, татар кульязмалары тарихында төп һәм киң кулланышлы язу материалы булып кәгазь файдаланылган.

## Су билгеләре

Кәгазьләрдәге су билгеләре (яктыга тотып карагач күренә торган нинди дә булса рәсем яки язулар) фәндә «филигрань» дип атала.

Көнчыгыш илләрендә (шул исәптән, Урта Азиядә) хәзерләнгән кәгазьләрдә су билгеләре кулланылмаган диярлек.

Европа илләрендә урта гасырлардан ук һәм XVIII гасыр башыннан алып Россиядә җитештерелгән кәгазьләргә су билгеләрен төшерү киң таралган. Ә XVII–XVIII гасырлардагы кайбер кәгазьләрдә филиграньнәр бөтенләй булмаган.

Европа кәгазьләренә су билгесе итеп шәһәр герблары (Амстердам һ.б.), таҗ билгесе, шамакай башы, арслан һәм башка күп төрле рәсемнәр, кала исемнәре, төрле инициаллар төшерелгән. Башлангыч чорда рус кәгазьләрендә дә Европа (бигрәк тә, һолланд) кәгазьләренеке кебек, һәрхәлдә, аларга охшаш филиграньнәр ясалган. Рус шәһәрләренең исемнәре, Россия империясенең һәм Мәскәү шәһәренең герблары, аю, якорь рәсемнәре, аббревиатуралар, кәгазь фабрикантларының инициаллары һ.б. су билгеләре итеп төшерелгән. 1760 нчы еллардан алып рус кәгазьләренең эшләнгән еллары да су билгесе итеп бирелә башлаган. (Көнбатыш Европа кәгазьләренең филиграньнәрендә ел күрсәтү XVI гасыр уртасында гамәлгә кергән).

Фәнгә берничә дистә мең филигрань билгеле. Россиядә XVIII гасыр уртасыннан кулланылган кәгазьләрдә 1500-дән артык төрдәге филигрань мәгълүм.

Кәгазьләрнең су билгеләре иске кульязмаларның эшләнгән вакытларын һәм урыннарын ачыклау өчен аеруча әһәмиятле.

Европа һәм рус кәгазьләрендәге филиграньнәргә багышланган белешмә хезмәтләр, махсус альбомнар бар. Кәгазьләрдәге су билгеләренең һәр элементы да әлеге хезмәтләрдә күрсәтелгән рәсемнәргә тулы төгәллеге белән тәңгәл килеп бетмәскә дә мөмкин.

## Язу кораллары

Язу өчен татарлар гасырлар дәвамында камыш һәм кош (каз һ.б.) каурыеннан эшләнгән каләмнәр кулланганнар. Аларның очларын үткен пычак белән бераз кыйгачлап ки-

сеп, язу карасы агып төшәргә очыннан уртасын бераз ярып ясаганнар. Дөрес һәм матур итеп язу өчен каләмне бөтен шартларын (киселеш авышлыгы, почмаклары бик очлы һәм үткен булмавы һ.б.) төгәл үтәп ясау зарур булган. Алтын Урда чорында Якын Көнчыгыш, Иран һәм Урта Азия камышыннан ясалган каләмнәр, шулай ук каурый һәм сөяк каләмнәр дә кулланылган дип язалар галимнәр[35]. Безнең җирлектә иң күп кулланылган язу кораллары турында кульязма китап колофоннарында еш очрый торган «Моны язганда кыш иде, каләмем камыш иде», шулай ук җырлардагы «Каз канаты каурый-каурый, хатлар язарга ярый...» кебек дәлилләр бик күп.

XIV гасырда җимерелгән Сарай-Бәркә шәһәре урынындагы археологик эзләнүләр вакытында табылган металл каләм – Алтын Урда чорыннан калган әһәмиятле истәлек. Ул Идел буенда гына түгел, бөтен Европада металл каләмнең беренчеләрдән кулланылганын раслый[36]. Европада XVIII гасыр ахырында гамәлгә керә башлаган металл каләмнәр 1830 нчы елларда Россиягә дә кергән. Рус мәктәпләрендә металл каләмнәр белән язу 1880 елда рәсмиләштерелгән. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына караган татар кульязмаларында тимер каләмнәр кулланылышка керә башлаганлыгы күренә. Шул ук чорда татарларда графит карандашлар да язу өчен кулланылган һәм XX гасыр башында мәктәп-сабак дәфтәрләрендә һ.б. текстларда гади карандаш шактый киң файдаланылган. XX гасыр башында төсле карандашлар да кулланылган.

Каурый, камыш һәм тимер каләмнәр белән җайлы һәм матур язу өчен аларны дөрес итеп тоту кагыйдәләрен үзләштерү таләп ителгән. Камыш һәм каурый каләмнәр, чагыштырма-

---

[35] Усманов М. Жалованные акты..., 1979. – С. 92–94; Кадыров Р. Источники по истории старотатарской письменности... 1999. – С. 100; Абзалов Л. Ордынская канцелярия..., 2013. – С. 245–254.

[36] Усманов М. Жалованные акты..., 1979. – С. 93.

ча йомшаграк һәм бөгелүчән-сыгылмалы булулары сәбәпле, кәгазь өстендә шома һәм җайлырак йөреп, хәрефләр-сүзләр нәфис рәвештә тезелгән. Тимер каләмнәрнең катылыгына күрә, күнегеп киткәнче алар шактый уңайсызлыклар тудырган һәм кәгазьгә төртелеп-кадалып интектергән. Нәфис итеп язу, әлбәттә, кәгазьнең сыйфатына һәм каләм тоткан кешенең сәләтенә-тырышлыгына да бәйле булган.

## Язу каралары

Урта гасырларда кулланылган язу каралары турында галимнәр тарафыннан шактый язылган[37].

XIX гасырның беренче яртысына кадәр татарларда язу өчен табигый матдәләрдән хәзерләнгән язу каралары кулланылган. Үсемлек тамырларын, агач (имән, шомырт, тал һ.б.) кайрыларын кайнатып, шулай ук корым, купорос һ.б. матдәләрдән язу карасы хәзерләгәннәр. Аны шәкертләр, кулъязма күчерү белән шөгыльләнүчеләр үзләре ясаган. Гасырлар дәвамында татарлар кулланган язу каралары көрән һәм кара, кызыл һәм саргылт төсләрдә булган. Мәсәлән, кара төстәгесен яшь имәннең язгы кайрысын яки имән агачының яфрагына ябышып үскән төерсыман үсентене төеп, шуңа бакыр купоросы кушып кайнату ысулы белән хәзерләгәннәр. Кызыл төстәге кара, гадәттә, яшь кызыл талның язгы кайрысына бакыр купоросы кушып, кайнатып ясалган. XVII гасырда кулланылган язу карасының составында матдәләр пропорциясе төгәл үтәлмәгәнгә күрә (аерым бер матдәнең күбрәк кушылуыннан), ул чордагы татар кулъязма истәлекләренең шактыеның кәгазьләрен язу карасы зарарлап үтәли тишкәләгән. Андый күренеш XVIII

---

[37] Усманов М. Жалованные акты..., 1979. – С. 89–92; Абзалов Л. Ордынская канцелярия..., 2013. – С. 242–245.

гасыр кулъязмаларында да күзәтелә, XIX гасырныкыларда да очраштыргалый.

Язу каралары ясарга өйрәткән киңәшләр кулъязма истәлекләрнең үзләрендә дә теркәлгән. Мәсәлән, Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «5532т» шифры белән саклана торган кулъязмада алтын, көмеш, яшел һ.б. төсләрдәге язу караларын ясау турында аңлатылган.

Кулъязма китапларның төп текстында караңгы төстәге бер төрле язу карасы файдаланылган булса, бүлек исемнәре яисә аерым гыйбарәләр еш кына кызыл төс, кайчагында яшел, зәңгәр һәм сары төсләр белән язылганнар. Биттәге текстны каймалаган сызыкча-кысалар да еш кына шундый ук төсләрдәге кара белән сызылган.

Химик матдәләр кушып ясалган язу каралары Россиягә XIX гасырның урталарында килеп кергән, аннан соң ил эчендә дә ясалган. Шәмәхә төстәге химик язу карасы татарларда 1870–1880 нче елларда кулланыла башлаган. XIX гасырның ахырында һәм XX гасыр башында андый язу карасы татар кулъязмаларында шактый очрый. Тик шулай да татарларда электән килгән гадәти саргылт-көрән төстәге язу карасы XX гасыр башына хәтле иң төп кара булып калган. Аны акрынлап төрле төсләрдәге (шәмәхә, зәңгәр, яшел, кызыл) химик язу каралары алмаштырган.

Гомуми бер нәтиҗә ясасак, татар язма чыганакларының зур күпчелеге табигый (нигездә, саргылт-көрән – зәгъфран төсендәге) язу каралары белән теркәлгән.

Эш тәҗрибәбездә сыек кара белән язылган текстлары тулаем уңып, бик начар күренә торган кулъязмалар да очраттык. Кайбер кулъязма текстларда исә (бигрәк тә элеккерәкләрдә – XVII–XVIII гасырларга нисбәтлеләрендә) бүлек исемнәре, баб, фасыл һ.б., шулай ук башка китаплардан өземтәләр бүтән төстәге – гадәттә, кызыл яисә сары кара белән теркәлгән булып, бөтенләй уңып беткән очраклар бар. Кулъязмалардагы андый урыннарда, гүяки, бөтенләй

буш калдырылган кебек дәрәҗәдә хәреф эзләре һәм элементлары да күренми-шәйләнми торганнарына юлыкканыбыз булды.

## Татар кулъязмасы – ул нәрсә һәм нинди?

Халыкның язуга ия булуы – китапның һәм белемнең төп асылын тәэмин итә. Идел-Урал буйларында яшәгән борынгы бабаларыбыз Ислам дине белән бергә гарәп язуын да кабул итеп, халкыбыз бу язуны мең елдан артык кулланган. Гарәп язуы һәм гарәп хәрефле китаплар татарларның җанына ук изгелек күзәнәкләре кебек үрелгән. Билгеле булганча, гарәп язуы ислам диненнән бераз иртәрәк кулланыла башлаган һәм ул шушы дин дөньяга таралган чорда аның язуы буларак киң танылган.

Ислам динендә Китап атамасы изге Коръәнне белдергән. Мөселманнар буларак, татарлар да, Китап дигәндә, иң беренче нәүбәттә, Коръәнне күздә тотканнар. Коръән сүзе, ягъни китап сүзе халкыбыз өчен иң газиз һәм мәртәбәле дәлил буларак кабул ителгән. Гыйлемгә, укуга, китапка югары дәрәҗәдәге мөнәсәбәт һәм тирәнтен хөрмәт Ислам диненең нигезенә үк салынган. Пәйгамбәрнең күп хәдисләрендә гыйлем олыланган. Татар халкының аң-белемгә, китапка багышланган йөзләгән мәкальләре һәм әйтемнәре, борынгы чорлардан алып хәзергәчә яшәгән әдипләрнең шигырьләре һәм тирән мәгънәле канатлы сүзләре Китапны изгеләштергән.

Төрки-татар телендәге беренче дәвер борынгы китаплар гарәп хәрефләре белән язылган. Ягъни, кулдан күчерелгән язма китаплар кулланылышка кергән. Татар кулъязма китабының мең елдан артык тарихы булуы – зур дәрәҗә. Чөнки Идел-Урал буйларына гарәп язуы үтеп кергәч тә, Коръән һәм башка дини китапларны күчереп язу, шул рәвешчә тарату, мәктәпләр өчен дәреслек-кулланмалар булдыру тормышка ашырыла башлаган. Гарәп язуы һәм гарәп

теле мөселман төрки-татарларның рухи тормышында озак дәверләр мәртәбәле урын биләп килгән.

Миркасыйм Госманов билгеләвенчә, татар кульязма китабы үсешенең иң югары ноктасы мәшһүр татар дәүләтләренең яшәү дәверенә – XIV–XVI гасырларга туры килгән. Әмма Казан ханлыгы һәм аннан соң башка татар ханлыклары яулап алынгач, татарларның рухи һәм дини, гомумән, төрле яклап кысрыкланулары нәтиҗәсендә, милли китапның яшәү һәм үсү мөмкинлекләре бик тарайган, татар кульязма китабының эшләнеш сыйфаты түбәнәйгән. Тик мәсьәләнең икенче ягы куәтләнгән: ата-баба динен һәм туган телне саклау юнәлешендә татар китабы төп таяныч-терәккә, көчле идеологик һәм иҗтимагый факторга әверелгән. Татар басма китабы да китапчылык өлкәсендә бай тәҗрибә тупланган җирлектә туган. Табигый күренеш буларак, татар кульязма китабының сыйфатлары басма китапларга да күчкән.

Тарихчы һәм дин галиме Ризаэтдин Фәхретдин халкыбызның фаҗигале үткәненә бәйләп, татар язма мирасы турында болай дигән: «Өлкәне басып алганнан һәм тырнакларын батырганнан соң, руслар мәчетләрне, мәктәп һәм мәдрәсәләрне ваттылар, җимерделәр, изге Коръән һәм башка китапларны яндырдылар. Язулы кәгазь һәм дәфтәрләрдән, язмалардан берсе дә калмады... Тарихыбыз булмауның, ата-бабаларыбызның, кавем һәм кабиләбезнең хәлләре һәм гомер сөрүләре яхшы беленмәүнең сәбәбе үткәндәге галимнәрнең тик торулары, халкыбызның тарих гыйлеменә бәя бирмәүләре түгел, бәлки бу эшкә мөмкинлек булмау һәм заман тарафыннан ярдәм ителмәүдер»[38]. Археограф Миркасыйм Госмановның сүзләрен дә искә төшерик, ул болай дип язган иде: «Казан кремленең стенасы шартла-

[38] Фәхреддинев Р. Болгар вә Казан төрекләре / төз. Ә.Хәйруллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1993. – Б. 52.

тылган көнне Җамигъ мәчет янындагы мәдрәсә җимерелеп, үзәк китапханәнең януы тарихчыларга мәгълүм...»[39].

Ризаэтдин Фәхретдин 1916 елда «Шура» журналында бастырган бер мәкаләсендә татар кульязма истәлекләре аз сакланган булуның сәбәпләрен: Болгар дәүләтенә монголлар явы вакытында, Казан ханлыгы руслар тарафыннан яулап алынганда һәм алардан соңгы Батырша, Сәед Җәгъфәр, Акай, Пугачёв күтәрелешләре вакытларында юкка чыккан дип язган. Сүзен дәвам итеп, ул болай дигән: «Аннан соңгылар да һәрвакыт булган ут казаларында янып, таралып торалар вә бик күп адәмнәр балалар кулларында йөртеп иске китапларның таралуларына вә ертылып бетүләренә сәбәп булалар». Галим шулай ук иске әсәрләрнең саклана алмавының сәбәпләрен пунктлап күрсәткән, саклау өчен күрелергә тиешле чараларны атаган[40].

Гарәп хәрефле татар кульязма китапларының һәм, гомумән, кульязма истәлекләрнең шактый өлеше 1920–1930 нчы елларда совет илендә барган идеологик һәм сыйнфый көрәш дәверендә юкка чыгарылган. Шуңа карамастан, кульязма китап мирасыбызның сакланып калган хәтлесе дистә меңнәрчә нөсхәне тәшкил итүе – бу байлыкның элек гаҗәеп зур күләмдә булганлыгын белдерә.

Татар археографиясе даирәсендә «кульязмалар» дигәндә беренче нәүбәттә төрки-татар телендә гарәп хәрефләре белән татар кешеләре кулдан күчереп язган һәм татарлар кулланган бөтен төр язмалар: зур һәм калын китаплар, төрле күләмдәге дини әсәрләр, мәдрәсә шәкертенең уртача форматтагы күпсанлы конспектлары, тышлыклары җуелган шигъри һәм чәчмә әсәрләр, дәва-тыйбб язмалары, куен дәфтәрләре зурлыгындагы бәетләр, шигырьләр, җырлар һ.б.

[39] Госманов М. Каурый каләм эзеннән..., 1994. – Б. 453.
[40] Ризаэтдин Фәхретдин. Иске әсәрләрне саклау хакында // Шура. – 1916. – №16. – Б. 388–389.

күп нәрсәләрне үз эченә алган дәфтәрләр, уч төбенә генә сыярдай догалык китапчыклары, ялгыз бер кәгазьдәге сугышчы хаты, ярты бит кәгазьдән торган хосусый килешү документы – барысы да күздә тотыла. Татар хаттатлары яисә шәкертләре тарафыннан күчереп язылган изге Коръән китабы, шулай ук гарәп һәм фарсы телләрендәге мәдрәсә дәреслекләре, дини һәм әдәби әсәрләр дә татар кулъязмасы дип исәпләнә.

Хәзергәчә килеп ирешкән кулъязма татар китаплары эчтәлек ягыннан күптөрле тармакларга: дини әсәрләргә, тарих, фәлсәфә, әдәп-әхлак, медицина, математика, география һәм башка күп фәннәргә, матур әдәбиятка, халык авыз иҗатына карый.

Татар кулъязма истәлекләренең XVIII гасырдан элеккерәк чорларда иҗат ителгәннәре иҗтимагый, тарихи һәм табигый сәбәпләр (сугышлар, көчләп чукындыру, тузу, таушалу, янып юкка чыгу, дингә каршы көрәш һәм башка төрле бәлаләр) аркасында аз сакланып калган. Кәгазьнең табигый саклану вакыты чикләнгән булуы да иң җитди сәбәпләрнең берсе. Мамыктан ясалган кәгазьнең яше 400–500 ел чамасы белән билгеләнә, ә башка төр чималдан эшләнгән кәгазьнең «гомере», яхшы шартларда саклаганда, бер йөз ел тирәсе дип исәпләнә. Мәшһүр шагыйрь Кол Гали 1233 елда иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» поэмасының да йөзләгән күчермәләре[41] барысы да диярлек XVIII һәм XIX гасырлардагы кулъязмаларда сакланган, ә XVII гасырга караганнары берничә

[41] Хәзерге көндә «Кыйссаи Йосыф» поэмасының фәнни оешмаларда, китапханәләрдә һәм музейларда саклана торган кулъязма күчермәләре, безнең исәпләү буенча, 300 берәмлектән артык. Аларның иң күбе – 260-тан артыгы Казан шәһәрендәге китапханәләрдә һәм фәнни оешмаларда саклана (Казан университеты Фәнни китапханәсендә – 165 күчермә, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында – 50 берәмлек, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә 44 берәмлек, шулай ук музейларда һәм шәхси кулларда да бар). Калганнары Петербургта, күрше Башкортстанда, Касыйм шәһәрендә, чит илләрдә һ.б.



*Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы. XVII гасыр күчермәсе (Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

генә. XVI–XVII гасырларда иҗат ителгән әсәрләр аеруча сирәк нөсхәдә очрый. Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат иткән бөек татар шагыйре Мөхәммәдьяр әсәрләреннән 1541 елда язган «Нуры содур» поэмасының хәзерге вакытка төрле күләмдәге 14 күчермәсе барлыгы һәм аларның

иң әүвәлгеләре XVII гасырга нисбәтле[42], күпчелеге XVIII гасыр күчермәләре икәнлеге билгеле иде. 2024 елда тагын өч күчермәсе (берсе тулы) табылып ачыкланды һәм бу сан хәзер 17-не тәшкил итә.

Казан һәм башка татар ханлыклары дәверендәге кулъязма ядкярләр күп сакланмаган. Безнең җирлектәгеләрдән Сахибгәрәй хан исеменнән 1523 елда бирелгән тарханлык ярлыгын, Аднищ хафизның 1554 елгы кулъязма җыентыгын әйтергә мөмкин. Аларның тарихи кыйммәтләре белән бергә, язылу рәвешләре һәм палеографик үзенчәлекләре үз вакытларының ачык дәлилләре булуы ягыннан да бик мөһим. XVI гасырның икенче яртысына караган, безнең җирлеккә бәйле берничә архив документы һәм китап кына мәгълүм.

XVII гасырга нисбәтле татар кулъязмалары инде күбрәк санда (якынча әйткәндә – йөзләрчә), ә XVIII гасырныкылар, бигрәк тә ул гасырның икенче яртысыныкы – шактый ук (якынча – меңнәр). XIX гасырга караган һәм XX гасырның беренче чирегендәге татар кулъязмалары бик күп – дистә меңнәрчә берәмлекне тәшкил итәләр. Шушы сакланган хәтле тарихи һәм мәдәни истәлекләрнең исә төрле сәбәпләрдән юкка чыккан биниһая зур язма байлыкның хәзергә хәтле килеп ирешкән бер өлеше генә икәнлеген истә тоту зарур.

Татар кулъязмалары тематик яктан искиткеч киң булулары белән бергә, күләмнәре һәм зурлыклары (форматлары) буенча да гаять күп төрле.

Кадими мәдрәсәләрдә мөселман дөньясының төрле дәвер һәм төрле ил-дәүләт галимнәре тарафыннан язылган фәнни китаплар гамәлдә булган. Ислам мәдәниятенең югары үсешкә ия булган чорында – урта гасырларда иҗат ителгән хезмәтләр аеруча күп кулланылган. Татар мәктәп-

[42] Мәрданов Р. Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы кулъязмалары // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 32–39; Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2022. – Б. 197–198.

мәдрәсәләрендә, XII–XVI гасырларда гарәп һәм фарсы телләрендә язылган дәреслекләр белән бергә, XIII–XVIII гасырларда төрки-татарча иҗат ителгән әдәби һәм фәнни әсәрләр файдаланылган.

Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә гасырлар дәвамында кульъязма дәреслекләр укылган. Искечә (кадими) татар уку йортларында «Иман шарты», Коръән, Һәфтияк, «Гакаид», «Фәраиз»,«КыйссаиЙосыф»,«Бәдәвам»,«Кыйсасел-әнбия»,«Мөхәммәдия», «Нәсихәтес-салихин», «Сөбател-гаҗизин» һәм башка күп төрле китаплар дәреслек буларак файдаланылган. Кадими татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку-укыту системасы, нигездә, Бохара һәм Урта Азиянең башка калаларындагы уку йортлары үрнәгендә алып барылган. Дагыстанда белем алган татар шәкертләре татар уку йортларында да андагы үрнәк буенча укытып, андагы дәреслекләрне кулланганнар. Бохара якларында белем алучылар XIX гасыр урталарына хәтле күп булган. Бу, әлбәттә, дәреслек китапларының кулланылуында да чагылган. Кадимчә уку йортларында Ислам дине һәм шәригать өйрәтмәләре, гарәп теле, фәлсәфә, мантыйк, әхлак, хисап һәм башка фәннәр тирәнтен өйрәнелгән. Дәреслекләрнең күпчелеге гарәп телендә, калганнары төркитатар һәм фарсы телләрендә булган.

Гарәп хәрефләре белән теркәлгән татар кульъязмаларын эчтәлекләре ягыннан төркемләп, характеристика бирергә шактый читен булса да, китапханәләрдә, музейларда һәм архивларда саклана торганнарын якынча күзаллау өчен берникадәр омтылыш ясап карыйк.

Халкыбыз кульъязма мирасының шактый күп өлешен (якынча 50% чамасы яисә күбрәк дияргә мөмкиндер) дини әсәрләр һәм мәктәп-мәдрәсә дәреслекләре алып тора. Алар арасында Коръән китабы һәм аның тәфсирләре, пәйгамбәрләр тарихы, гарәп теле буенча дәреслекләр, төрле материаллар язылган сабак-дәрес дәфтәрләре иң күбеседер, мөгаен. Ислам шәригатенең төрле тармакларына караган

хезмәтләр, мантыйк-фәлсәфә әсәрләре һ.б. бихисап. Болар эченә шулай ук догалыкларны кертергә кирәк. Догалар белән бергә юраулар, тәгъбирнамәләр һәм ырымнар, тыйбб-медицина язмалары, төрле зәхмәтләрдән саклану, дәва-шифа һәм өшкерү догалары кулъязма җыентыкларда, гадәттә, бергә йөртелгән. Күләмле тыйбби әсәрләр, гадәттә, аерым язылып йөртелгән, шулай ук төрле җыентыклар эчендә дә урын алган. Төрле сырхаулардан саклану, дәва-шифа һәм өшкерү догалары, аерым җыентыклардан тыш, теләсә нинди эчтәлектәге кулъязма мәҗмугаларның буш калган битләрендә һәм кәгазь читләрендә дә күп теркәлгән.

Барлык татар кулъязма мирасының калган ярты өлешен матур әдәбият һәм халык авыз иҗаты, тарихи әсәрләр, хосусый язмалар (хатлар, көндәлекләр, гаилә язмалары һ.б.) алып тора дисәк, бик ялгышмабыз шикелле. Әдәби әсәрләрдән төрле хикәяләр, чәчмә һәм шигъри кыйссалар, шигырьләр, фольклордан – дастаннар, бәетләр, мөнәҗәтләр, җырлар, мәзәкләрне әйтергә мөмкин. Әдәби әсәрләрнең авторлары билгеле булганнары һәм билгесезләре, ачыкланмаганнары да бик күп. Күләмле берничә шигъри текст, еш кына, бер җыентыкка тупланган була. Мәсәлән, Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф»ы (1233), Вафаиның «Раунакыль-ислам»ы (1464), Раушаниның «Чубаннамә»се (XV гасыр) һ.б. Уртача күләмлеләре шулай ук бер үк төптә очрый. Мәсәлән, «Бәдәвам», Сөләйман Бакырганиның «Ахыр заман» һ.б. әсәрләре бер җыентыкта, «Кисекбаш», «Сәкам кыйссасы», «Авык кыйссасы», «Кыйссаи Әхтәм» кебекләр бер җыентыкта булырга мөмкин.

XVII–XVIII гасыр кулъязмаларында шигырьләр, гадәттә, «Хикмәте хәким» яисә «Илаһи бәет» исемнәре астында теркәлгәннәр. Әхмәт Ясәвинең, Сөләйман Бакырганиның, «Бакырган китабы»ндагы төрле авторларның һәм Мәүла Колыйның шигырьләре «хикмәт», «Хикмәте хәким» дип аталган.

Күпсанлы бәетләр һәм мөнәҗәтләр, җырлар, гадәттә, аерым дәфтәрләрдә теркәлгән. Солдат һәм сугыш, әсирлек турындагы бәетләр, якын туганнарны сагыну-юксыну кебек сагышлы мөнәҗәтләр – хәрби хезмәттәге ир-егетләрнең куен дәфтәрләрендә тупланган. Шәхси фаҗигаләр, «Сак-Сок», солдат һәм сугыш бәетләре – фольклор әсәрләре арасында иң күп очрый торганнардан. Дастаннар һәм риваятьләр сирәк. Бәетләр, мөнәҗәтләр һәм шигырьләр бергә язып йөртелгән җыентык-дәфтәрләр бик күп. Җырлар һәм кыска җырлар да шактый, аларның күпчелеге XX гасыр башына, 1920–1930 нчы елларга нисбәтле.

Тарихка багышланган әсәрләрдән «Дәфтәри Чыңгызнамә», Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария», авыл тарихлары, шәҗәрәләр, сәяхәтнамәләр, хосусый актлар һ.б. әйтергә кирәк. Тарихи әсәрләр, сәяхәтнамәләр («Исмәгыйль ага сәяхәте», «Мөхәммәтәмин сәяхәтнамәсе», хаҗнамәләр), чагыштырмача, сирәк очрый. Шәҗәрә мәгълүматлары аерым кәгазьләргә, җыентыкларның буш битләренә теркәлгән. Тулы һәм күп мәгълүматлы яисә фрагмент рәвешендәге шәҗәрәләрне шактый күрергә мөмкин. Хосусый актларның төп нөсхәләре дә, онытылмасын өчен берәр дәфтәрнең яисә китапның буш битенә язып куелган күчермә текстлары да еш очрый.

Төрле чорлардагы хатларның тулы күләмдәгеләре яки кыскача вариантлары бик күп микъдарда сакланган. Хат язу караламалары һәм аларның калып-үрнәкләре шулай ук байтак.

Татар кулъязмаларының бер өлеше, искәртеп үткәнебезчә, тематикага карап тупланган. Мәсәлән, тарихи язмалар, әдәби әсәрләр, бәетләр, шигырьләр, җырлар, алышбиреш язулары һ.б. Шул ук вакытта урта яки кече форматлы кулъязмаларда, гомумән, күп төрле мәсьәләләргә караган текстларны: шәкерт шигырьләре, җырлар, тәҗвид дәресләре, зәхмәтләргә каршы догалар, хат калыбы, адрес, бала тууы,

кемнең дә булса вафаты, сарык бәрәнләве, чәчүлек орлыклар исәбе, базардан сатып алган әйберләр – гомумән, бихисап мәсьәләләргә кагылышлы текст парчаларын күрергә мөмкин. Шулар ук калын кульязма китапның башындагы-ахырындагы яки буш калган урынындагы теләсә кайсы битенә дә теркәлгән булуы гаҗәп түгел. Тематиканың күп төрлелеге һәм, гомумән, тәртипсез рәвештәге чуарлыгы кульязма ияләренең холыксызлыгыннан булмаган, әлбәттә. Мондый хәл, беренче нәүбәттә, кәгазь кытлыгыннан, дөресрәге – аны сатып алу мөмкинлеге булмау нәтиҗәсендәге үтә сакчыллыктан килеп чыккан. Икенчедән, ашыгыч теркәп куеласы язма өчен якындагы кәгазьгә үрелү гадәте дә адәм баласына хас табигый күренеш.

Археограф Миркасыйм Госманов эчтәлекләре ягыннан шактый чуар булган кульязмаларга карата «шәкерт дәфтәрләре» дигән махсус атама кулланып, китабында аларга зур бүлек багышлаган иде[43]. Болай тәгаенләнгән, нигездә, җырлар һәм бәетләрдән торган дәфтәрләрне мәдрәсәдә укыган кешеләр үзләре белән еш кына хәрби хезмәткә һәм сугышка (рус-япон, Беренче бөтендөнья сугышларына) да алып киткәннәр. Элекке гыйшык җырлары язылган андый дәфтәрләргә хәрби хезмәткә бәйле һәм сугыш чоры вакыйгалары, күбесенчә, солдат һәм сугыш бәетләре өстәп язылган. Шунлыктан, кеше гомеренең шәкерт чагына бәйле дәфтәрләр «солдат дәфтәре» дә булып киткәннәр. Кайчакларда яшьлек хатирәсе буларак андый дәфтәрләр өлкән яшькә ирешкән муллаларда да кадерләп саклаган. М.Госманов «шәкерт дәфтәрләре» турында бик тәфсилләп язса да, ул тәкъдим иткән атама хуплау табып җитмәгәнлеген искәртергә кирәк. Чөнки шәкерт дәфтәре дигәндә, беренче нәүбәттә, укучының сабак дәфтәре яисә дәрес конспектлары күз алдына килә. Ә Госманов башкача мәгънәне – шигырьләр һәм

[43] Госманов М. Каурый каләм эзеннән..., 1994. – Б. 95–156.

фольклор җыентыкларын күздә тоткан. Кыскасы, андый сыйфатламаның исеме җисеменә туры килеп җитмәгән. Шуңа күрәдер, «шәкерт дәфтәрләре» сүзтезмәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә дә, А.Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә дә юк. «Татар энциклопедиясе»ндә аларга багышланган махсус мәкалә бар һәм анда да «эчтәлеге билгеле бер системага салынмаган, тематик яктан күптөрле»[44] буларак характерланган.

Дингә (шул исәптән, искелек калдыгы дип исәпләнгән гарәп хәрефләренә, язмаларына һәм китапларына) каршы совет дәүләтенең рәхимсез сәясәте хөкем сөргән чордагы татар кулъязмалары да аерым әһәмияткә ия. XX гасыр башында һәм әле 1920 нче елларда да гарәп әлифбасы буенча белем алган буын вәкилләре үзләре өчен уңайлы булган гарәп графикасында язуларын дәвам иткәннәр. 1970–1980 нче елларга хәтле көндәлек язмалар, хатлар, дини текстлар, күңел юанычы өчен язып йөртелгән шигырьләр, җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр һ.б. гарәп хәрефләре белән теркәлгән. 1950–1970 нче еллардагы дәфтәрләрдә халкыбызның күп гасырлар дәвам итеп килгән кулъязма күчерү традициясенең чагылышын да күрергә мөмкин: «Кыйссаи Йосыф», «Бәдәвам», «Ахыр заман», «Кисекбаш» кебек борынгы әсәрләрне совет чоры әби-бабайлары да үз дәфтәрләренә күчергәннәр. XX гасырдагы татар фольклоры үрнәкләре арасында 1930 нчы еллардагы мәчетләрне җимерү («Манара» бәетләре) һәм дин әһелләрен эзәрлекләүгә багышланганнары күп, дини-тарихи текстлар (мәсәлән, 1945, 1953 һ.б. еллардагы хаҗнамәләр) һәм бүтән төрле язмалар бар.

Татар кулъязмаларының төп хосусиятләре гомуми һәм кыскача рәвештә күзаллаганда шушылардан гыйбарәт. Монда әйтелмәгән кайбер үзенчәлекләре турында башка бүлекләрдә өлешчә язылды.

[44] Татар энциклопедиясе: 6 томда. 6 т. 2 кис.: Ш–Я. – Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2021. – Б. 42.

## Тематик җыентыклар

Төрле мәсьәләләргә караган текстлар һәм әсәрләр татар кульъязма китаплары арасында еш кына бер төптә туплап йөртелгән кебек, тематик яктан берләштерелгәннәре дә булган. Беренче төрдәгеләрен Г.Рәхим «мәҗмуга» дип атап, андыйларны бик төгәл характерлаган[45]. Бер үк яки якын темага язылган әсәрләр йә аларның аерым өлешләре кыскача (абзацлап, яртышар битләп) җыентык сыйфатында туплап йөртелгән. Намаз кагыйдәләре турында төрле чыганаклардан алынган күчермәләр бер дәфтәрдә, фикъһ мәсьәләсенә караган текстлар бер мәҗмугада, шигъри әсәрләр бер җыентыкта, бәет-мөнәҗәтләр янә аерым, гарәп теле грамматикасы белән тәҗвид кагыйдәләре бергә, тыйбб-медицинага багышланган эреле-ваклы күчермәләр башка кульъязмада, кечкенә сүрәләр һәм кыска күләмле догалар җыйнак догалыкларда һ.б. рәвешле – үзләренчә тематик яктан классификацияләнгән хәлдә дә язып тупланган. Шулар кебек үк, тарихка багышланган әсәрләр һәм төрле тарихи хәбәрләр белән вакыйгалар аерым җыентыкларга берләштерелгән. Мәсәлән, Казан университеты китапханәсендәге «40т» шифрлы кульъязмада «Җамигыт-тәварих» белән «Дәфтәри Чыңгызнамә» бер мәҗмугада булуы, «Чыңгызнамә» тексты теркәлгән башка кульъязмаларда еш кына «Тәварихы Болгарийә» һәм Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» әсәре бергә язылган хәлдә йөртелүе дә тематик җыентыклар булганын дәлилли.

Татар кульъязмаларындагы тематик җыентыкларның кайберләре үзләре бер әсәр сыйфатында оештырылу омтылышын кичергәннәр. Мәсәлән, «Чыңгызнамә» («Дәфтәри

---

[45] Г.Рәхим, Г.Газиз. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. Икенче басма. – Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты нәшере, 1925. – Б. 84–85.

Чыңгызнамә») исеме белән танылган китап та, электән бер җыентыкта күчереп йөртелгән һәм төрле чорларга караган, башлангычта мөстәкыйль текстларны бергә туплап, мөмкин кадәр бер тәртипкә тезеп, телен һәм стилен бераз шомартудан хасил булганга күбрәк охшый. Текстындагы кайбер даталарга һәм тарихи фактларга нигезләнеп фикер йөрткәндә, аның XVII гасыр ахырында эшкәртелгәнлеге аңлашыла.

Галимнәр электән үк игътибар иткәнчә, «Чыңгызнамә» исеме астында берләшкән текстларның Чыңгыз хан, Аксак Тимер һәм Амәт турындагы дастаннары әүвәлгерәк чорлардан килгән. Ә «Тарих дастаны» өлеше исә аерым бер автор тарафыннан гына иҗат ителмичә, электән язылып һәм өстәлеп килгән мәгълүматларны бергә туплап оештырылганга күбрәк тарта. Ул бүлекнең соңгырак гасырларда өстәмәләр белән тулыланып дәвам итә баруы да татар кулъязмаларына хас күренеш. «Чыңгызнамә»нең бербөтен рәвешендәге төгәл генә исем-атамага ия булып җитмәгәнлеге шулай ук аның җыентык калыбы хасиятен белдерә. Китаптагы кайбер (Аксак Тимер, Амәт, Идегәй, ханнарның биләмәләре турындагы) бүлекләрнең ахырларында «Валлаһу әгъләмү бис-саваби» («чын дөреслекне Аллаһы белә») дигән гыйбарә бар. Менә мондый сүзләр, гадәттә, кулъязма җыентыкларга төрле китаплардан күчереп алынган кыскача язмалар яисә кем дә булса сөйләгәнне теркәгән очракларда текст ахырына өстәлгән. «Чыңгызнамә»дәге шундый гыйбарәләр дә – төрле бүлек рәвешендәге мөстәкыйль текстларның җыелма буларак бергә тупланганына ишарә итә. Әлеге китапны кайбер галимнәрнең шартлы рәвештәге «Дастаннар мәҗмугасы» яки «Дастаннар китабы» дип атарга тәкъдим итүләре шулай ук «Чыңгызнамә»нең җыентык сыйфатына бәйле.

«Чыңгызнамә»нең бер әсәр рәвешендә тупланганлыгы аның икенче бер чордашы – суфичылык әдәбияты җыентыгы



*«Чыңгызнамә» әсәренең XIX гасыр башы  күчермәсе*
*(Татарстан Республикасы*
*Милли китапханәсе)*

«Бакырган китабы»на да охшаш. «Бакырган китабы» – шулай ук XVII гасыр ахырында төрки шагыйрьләрнең әсәрләре

бергә җыелган шигърият антологиясенең бер үрнәге[46]. Тематик яктан төрле әсәрләр булсалар да, «Чыңгызнамә» белән «Бакырган»ның китаби калыпларында кайбер охшаш яклар бар. Әйткәнебезчә, алар икесе дә бер чорда – XVII гасыр ахырында төзелгәннәр. Икесенең дә исемнәре китапларның тулы эчтәлегенә туры килеп бетми. «Чыңгызнамә» турында алда сүз булды, ә «Бакырган китабы» шулай ук аерым бер автор – Сөләйман Бакыргани әсәрләре генә тупланганлыгын белдерми. Димәк, китапның «Бакырган китабы» дигән исеме дә «Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») кебек үк шартлы. Алар җыентыктагы беренче шигъри әсәргә яки дастан текстына күрә шулай исемләнгәннәр. Гомумән, элек татарларда китапны беренче гыйбарәсенә бәйләп атау күренеше киң таралган булган. «Бакырган китабы» исеме андагы беренче шигырьнең «Бакыргандин сәфәр кыйлсам...» дигән юлларына нисбәт ителгән дип саныйбыз[47].

«Бакырган китабы»нда XII–XVII гасырларда яшәгән дистәләгән авторның шигырьләре тупланган. Галим Габ-

[46] Бу мәсьәләгә беренчеләрдән булып әдәбият галиме Гали Рәхим игътибар иткән. Ул «Бакырган китабы» турындагы мәкаләсендә, «таркау әсәрләрдән җыелып бер-ике кеше тарафыннан тәртип ителгән бер мәҗмуга» дип, анда ничә шагыйрьнең күпме шигыре кергәнлеген һ.б. ачыклап язган (Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Икенче бүлек. – Казан: Татарстан җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты, [1923]. – Б. 102–108). Борынгы язма ядкәрләрне өйрәнгән галимә Зәйнәп Максудова «Бакырган китабы»н махсус тикшереп, аны нәкъ менә Мәүла Колый төзегән дигән нәтиҗәгә килгән.

[47] Гали Рәхим җыентыктагы беренче шигырь ахырында (гомумән, ул китапта бер генә мәртәбә) автор буларак язылган Сөләйман Бакыргани исеменә бәйләдер дип фаразлаган. Әмма шигъри калыптагы «Кисекбаш» китабын татарлар беренче сүзе буенча «Башлагали» дип атаганны, XIII гасырның мәшһүр шагыйрьләреннән Шәрәфетдин Бусыйриның «Касыйдәи бөрдә» исемле шигъри әсәрен беренче юлындагы башлангыч сүзләре «Әмин тәзәккүр...»гә бәйләп, татарлар «Әмин тәзәк» дип йөрткәнен, Фәридетдин Гаттарның «Пәнднамә» әсәрен беренче сүзләре буенча «Хәмде би-хәдд» дип атау гадәте булганны исәпкә алганда, «Бакырган китабы»ның да исеме текстындагы беренче сүзенә нисбәт ителгән. Мондый мисаллар тагын да бар.

драхман Таһирҗанов әлеге китапның чыганак буларак әһәмияте турында язганнарны искә алу бик урынлы булыр. Ул авторлар турында мәгълүмат биреп, болай ди: «Бу авторларның Кол Шәриф белән Касыйм шәехтән башкалары – тугандаш халыкларның әдәбият тарихларында мәгълүм шәхесләр. Ләкин үзенә күрә антология кыяфәтен алган «Бакырган китабы»нда тагы Бәйза, Бәһбүди, Кол Шәрәфи, Мискини кебек шагыйрьләр дә очрый. Аларның исемнәре югарыда телгә алынган Нәвои китабында да, Хәсән Нисариның «Мөзәккер әл-әхбаб» исемле зур антологиясендә дә, Үзбәкстанда чыгарылган сигез томлык кульязмалар тасвирламасында да, шулай ук башка белешмәләрдә дә очрамый. Шуңа күрә аларның кайберләре болгар-татар җирлегендә формалашкан шагыйрьләр булуы бик тә ихтимал. «Бакырган китабы»ның Урта Идел буенда төзелгән булуын игътибарга алсак, безнең фикер тагы да куәтләнә төшә. (Урта Азиядә бу антология күчермәләренең юк дәрәҗәсендә аз очравы бу фикергә тагын көч бирә)»[48].

«Бакырган» җыентыгын соңгырак чорда әдәбият галиме Фәрит Яхин тикшерде һәм анда барлыгы 20 шагыйрьнең 143 шигъри әсәре теркәлгәнен, шуларның өчтән бере Сөләйман Бакырганиныкы икәнлеген әйтеп, бу китап XVIII гасырда Пугачёв күтәрелеше алдыннан яисә шул елларда төзелгән дип белдерде[49].

«Бакырган китабы» исеме астында тупланган шигъри әсәрләр тематик җыентыклар булганлыгы турындагы алда әйтеп узылган фикергә өстәмә бер дәлил булып тора. Иң мөһиме – «Бакырган» китабы»нда алты гасыр эчендә иҗат ителгән әсәрләр бергә җыелган булу факты – «Чыңгызнамә»дә тупланган дастаннарның да төп

[48] Таһирҗанов Г. Тарихтан – әдәбиятка..., 1979. – Б. 63.

[49] Бакырган китабы: XII–XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре / төз. Ф.Яхин. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 3–8.

нигезләре бер чорга (һәрхәлдә, XVII гасырга) гына карамаганын раслый.

Бер чор-дәвердә иҗат ителгән әсәрләр татар кулъязма җыентыкларында еш кына бергә язып йөртелгән булуын да искәртү зарур. Мәсәлән, Казан университеты Фәнни китапханәсенең бер кулъязма җыентыгында Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы һәм «Кыз хикәяте» бергә булуы, шулай ук Татарстан Милли китапханәсендәге җыентыкта «Нуры содур» белән «Кыйссаи Мансур» әсәрләре бер төптә саклануы[50] – бу әсәрләрнең заманын билгеләү өчен өстәмә дәлил.

Кулъязмачылык традициясендә боларга охшаш серле һәм хәзергәчә тәгаенләнеп бетмәгән әсәрләр һәм текстлар тагын да бар.

## Кулъязмаларның эшләнеше

Бу мәсьәлә галимнәрнең хезмәтләрендә яктыртылган булса да, шушы китапның хасиятенә күрә, аны гомуми тасвирлап китәргә ихтыяҗ бар.

Татар кулъязма китаплары, нинди эчтәлекле булуларына карамастан, мөселман китабының бай традицияләрен сакларга тырышып, ләкин мөмкинлекләргә күрә, төрлечә сыйфатта эшләнгәннәр. Татар язма китапларының төзелеше һәм сәнгати бизәлеше XVI гасырның урталарыннан алып, халкыбызның иҗтимагый-сәяси хәле белән турыдан-туры бәйле рәвештә, үз үсешендә тоткарлык кичергән. Шулай да, гаять гүзәл кулъязма истәлекләр дә сакланып калган. Мөстәкыйль дәүләтләрдә яшәгән мөселман төрки

[50] Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «5228т» шифры белән саклана торган кулъязма; Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1116т» шифры белән саклана торган кулъязма.

халыкларның китаплары белән чагыштырганда, гасырлар дәвамында колониаль изелүдә яшәгән татар халкының кулъязма китабы, эшләнүе һәм бизәлеш сыйфаты ягыннан калышса да, мәгънә һәм сан җәһәтеннән бирешмәгән. Татар дәүләтләре туздырылгач рәсми китапханәләрнең һәм мөселман китап базарының гамәлдә булмавыннан, затлызиннәтле китаплар күчерергә ихтыяҗ юклыктан, дини һәм милли изү аркасында кулъязма китапларны сәнгати яктан нәфисләп эшләүгә зарурият тә, мөмкинлек тә чикләнгән.

Татар кулъязма китаплары бары тик хосусый ихтыяҗга нигезләнгән – кешенең үз кирәге өчен эшләнгән. Шул ук вакытта китапларның эчтәлек ягы шактый киң даирәне үз эченә алган – һәр дәвернең үз галимнәре, әдипләре һәм шагыйрьләре булган, халык авыз иҗаты әсәрләре дә шәкертләр кулы белән күчерелеп төрле төбәкләргә таралган.

Кулъязма китапның якынча зурлыгына күрә (ә аны чамалау читен булмаган – ул күчереләсе китап-протографның күләме буенча билгеләнгән) кәгазь табакларын җитәрлек күләмдә кисеп һәм бөкләп, дәфтәрләп хәзерләгәннәр. Бөтен текст күчерелеп беткәннән соң дәфтәрләрне җыеп тегеп, китап итеп төпләгәннәр һәм катыргы белән тышлаганнар. Татар кулъязма китапларының күпчелек өлеше мәдрәсәләрдә укыган шәкертләр тарафыннан күчерелгән. Азрак күләмдәге өлеше муллалар һәм каләм хезмәтенә күңел куйган һәм шуның белән кәсеп иткән хаттатлар тарафыннан күчереп язылган.

Муллалар арасында төп хезмәтләреннән – имамлыктан берничә айга яисә яртышар, хәтта берничә елга ял алып, махсус китап күчерү белән шөгыльләнүчеләр булган. Мәсәлән, 1863 елда Мамадыш өязенең Эзмә Пүкәл авылы имамы Минһаҗетдин Фәхретдин улының мәдрәсәдән үзенә кирәкле китапларны күчереп алу өчен вазифасын-

нан ике елга китүе турындагы мәгълүмат күргән идек[51]. Мәдрәсәләрдә дини китаплар тупланганлыгы, элеккедән дәвам итеп эшләп килгән мәшһүр уку йортларында (мәсәлән, Эстәрлебашта) бай китапханәләр булганлыгы билгеле.

Мәдрәсә остазлары үзләренә кирәкле китапларны, гадәттә, белемлерәк һәм матур язуга сәләтле шәкертләргә кушып күчерткәннәр. Бу шөгыльдә остарган, тырыш шәкертләр китаплар күчереп үзләренә азмы-күпме матди табыш та алганнар. Бер үк әсәрнең аерым дәфтәрләре төрле кеше кулы белән язылган китаплар да очрый. Ашыгыч күчерелүе зарур булган әсәрне берничә шәкерт өмә итеп, үзара өлешләп, күмәк рәвештә дә күчергәннәр. Бу хакта Шиһабетдин Мәрҗани дә язып калдырган. Мәсәлән, аның Бохарада укыган вакытында кайбер китапларны 10–15 шәкерттән күчертеп яздыртканлыгы мәгълүм[52].

Китаплар күчергәндә шәкертләр еш кына бер-берсенә ярдәмләшкәннәр. Кульязмаларның үзләрендә аны күчергән кешенең исеме язылып, шунда ук «лиәҗел дустым фәләнгә» дигән гыйбарәләр очравы – моны ачык раслый. («Лиәҗел» – гарәп телендә «өчен» мәгънәсендә)[53].

Шәкертләр, өлкәнрәк агаларыннан яисә этиләреннән калган дәрес китабы булмаган очракта, укыячак фән буенча (мәсәлән, гарәп теле сарфы һәм нәхүе, мантыйк, шәригать хөкемнәре һ.б.) әсәрне-китапны үзләре күчереп язарга тиеш булган. Мәдрәсәләрдә укыган чордагы кульязма дәрес китапларының аерым бер өлешендә күп очраган ха-

---

[51] Башкортстан Республикасының Милли архивы. – И-295 фонд, 2 тасвир, 100 саклану берәмлеге, 616 кәгазь.

[52] Шиһабетдин Мәрҗани / төз.: Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Әлмәт: «Рухият» нәшр., 1998. – Б. 69.

[53] Бу сүзне аерым бер кешенең нисбәсе итеп кабул итүчеләр дә бар: «Кәтәбәһе: Габделшәкүр бине Сөләйман Ләҗәли Зарифҗан бине Сабирҗан...» (Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре: Т. III. – Казан: Татар. китап нәшр., 2019. – Б. 208).

талар аларны тема белән яхшы таныш булмаган яшь шәкерт күчерүдән (бигрәк тә, ашыгычлыктан һәм вакыт кысынкылыгыннан) хасил булган.

Кулъязма китапларны төпләп тышлаган вакытта аларның башларына һәм ахырларына төрле санда буш-чиста кәгазьләр (гадәттә, 3–5-тән алып 10–20-гә хәтле) тегеп калдырганнар. Алар әсәр текстына бәйле өстәмәләр язар өчен махсус тегелгән.

Китапның тексты форзацтан соңгы эчке тарафыннан (кәгазьнең «б» ягыннан) башланган. Текст, гадәттә, битнең уртасыннанрак яки өчтән икенче өлешеннән язылып киткән. Ә беренче битнең югары – «гонван» дип аталган өлеше зиннәтле, күпчелек очракта схематик-гади генә итеп бизәлгән һәм анда эрерәк хәрефләр белән, кайвакытта каллиграфик нәфис рәвештә «бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим» гыйбарәсе язылган. Сәнгать белгечләре гонванны чәчәк бәйләме белән тиңлиләр. Күпчелек китапларның текстлары (бигрәк тә шигъри әсәрләр) төрле төсләрдәге рамкаларга алынган. Алар параллель икешәр, кайчакта өчәр катлы да булган. Дәреслекләр һәм дини-шәргый китапларның төп текстлары кәгазь битендәге мәйданның яртысы күләмендә генә өлешен алып, төп текстка карата шәрех-аңлатмалар язар өчен битнең өстендә һәм астында, читендә чиста-язусыз шактый мәйдан калдырылган. Искәрмәләр һәм тәрҗемәләр юл араларында да теркәлгән. Күләмле шигъри әсәрләр бер биттә, гадәттә, ике баганада язылган. Алар еш кына вертикаль сызыклар белән, ә кайчакта бизәк-орнаментлар белән бүленгән.

Җанлы затларның рәсемнәрен сурәтләү Ислам дине тарафыннан тыелганга, татар кулъязма китапларында андый рәсемнәр ясалмаган. Китапларда күбесенчә үсемлек һәм чәчәксыман бизәкләр, кайчагында мәчет яисә бүтән биналарның рәсемнәре һәм башка төрле сурәтләр ясалган.

Бер үк мәдрәсә шәкертләре яисә бер үк хаттат, китап күчерүче тарафыннан әсәрләрнең гонваннарында бер

төрле үк бизәкләр кулланылган. Мәсәлән, Бәрәскә авылы мәдрәсәсендә күчерелгән гарәп теле дәреслеге кулъязмаларының шундый үзенчәлегенә игътибар иткән идек.

Текстлар язылган аерым кәгазьләрнең «б» якларының һәрберсендә түбәнге сул почмакта киләсе битнең башындагы беренче сүзе язып куелган. Татарларда аны «хафиз» дигәннәр. Фәндә ул «кустод» дип атала. Татар кулъязмаларының кустодлары күбесенчә диагональ буенча авыш итеп, еш кына гади яисә бизәкле кыса-рамка эчендә язылган. Шул рәвешле, кулъязма китапның аерым кәгазьләрен һәм дәфтәрләрен җыеп теккәндә уңайлы гына табып, тәртибе белән урнаштырырга мөмкин булган. Кустод-хафизлар кулланылганлыктан, кулъязма китапларда бит саннарын (пагинацияне) кую ихтыяҗы булмаган диярлек. Кустодлы булсалар да, пагинация куелган кулъязмалар да аз түгел.

Кустодларның хәзерге археографлар өчен дә файдасы бик зур. Чөнки таркау битләре генә сакланган яисә кәгазьләре үзара буталган кулъязманың текстын эзлекле һәм дөрес итеп урнаштырганда белгечләр кустодлар буенча эш итәләр.

Текстларның юллары тигез рәвештә, юл аралары һәм читләре һәр биттә тәңгәл урнашсын өчен кулъязма күчерүчеләр мистарлар (транспарантлар) файдаланганнар. Калын кәгазьгә языласы текстлар өчен юан тегәрҗепне юлюл итеп кәгазьгә беркетеп-тегеп куелган мистарлар кулланылган. Шундый мистар өстенә кәгазьне куеп, кул белән җиңелчә басып сыпыргач яки авыр әйбер белән бастырып торгызгач, юл сызыклары кәгазьләрдә беленеп калган. Ә юка кәгазьләргә язганда мистарның башка төрлесе – аерым кәгазь битенә калын итеп юллар сызылганы кулланылган. Әлеге мистарны күчереп языласы бит астына куйганнар. Кәгазьләрдәге язу юлларын сөяк каләм белән сызып чыгу ысулы да булган.

Кулдан күчереп язылган китапларның зурлыгына килгәндә, алар төрле форматта: кеп-кечкенә миниатюр нөсхәләрдән алып, хәзерге журналлардан да зуррак рәвештәгеләре булган. Язма китапларның форматы эчтәлек күләменә һәм әһәмиятенә карап билгеләнгән.

Татар кулъязмаларының күп кулланылган форматларыннан төп өч төрне әйтергә мөмкин. Россиядә эшләнгән кәгазьне нигез итеп алганда, беренчесе – зур кулдагы (ягъни, форматлы), якынча 34х22 см тәшкил иткән. Ул бер табак кәгазьнең ярты өлешенең зурлыгы. Андый форматка татарлар тарафыннан Коръән һәм тәфсирләр, зур күләмле дини-шәргый әсәрләр, Рабгузиның «Кыйсасел-әнбия»сы, Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабы һ.б. язылган. Андыйлар, гадәттә, калын томнарны тәшкил иткән.

Икенчесе – уртача кулдагы, бер кәгазь табагының дүрттән бер өлеше зурлыгында, иңе-буе, гадәттә, 17х22 см. Бу формат татар кулъязмалары өчен иң күп кулланылганы. Коръән, «Кыйссаи Йосыф», Утыз Имәни әсәрләре һ.б. әдәби җәүһәрләр, Мөслиминең «Тәварихы Болгария»се, күпсанлы хикәятләр һәм кыйссалар, мәдрәсә дәреслекләре, дини һәм башка төрле җыентыклар күбесенчә нәкъ шундый зурлыктагы, уртача калынлыктагы кулъязмаларда сакланган.

Өченчесе – кече кулдагы, иңе-буе 11х17(18) см зурлыгындагы кулъязмалар. Андыйлар, гадәттә, дәфтәр рәвешендә булып, аларга бәет-мөнәҗәтләр, шигырьләр, мәктәп дәресләре, көндәлек һәм алыш-биреш язмалары, дини текстлар, җырлар һәм бүтән күп төрле текстлар теркәлгән. Мондый форматтагыларның калынлыклары төрлечә булган.

Бу өч төрле форматтагы кулъязмалардан тыш башка зурлыктагылары да булган. Стандарт булмаган форматлылары, озынча рәвештәгеләре һәм еш очрый торган тагын берсе – учка сыярлык кына кечкенә догалык җыентыклары. Андыйларның күбесендә төрле догалар, шул исәптән, дәвасихәт, өшкерү өчен һ.б. язылган, кайберләрендә исә кыска



*Миниатюр догалык. XIX гасыр*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

җырлар, мөнәҗәтләр кебек төрле текстлар да бар. Археографик табышлар арасында XVIII–XIX гасырларга караган кече кулдагы шундый татар догалыклары шактый күп очрый. Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган, иңе – 5 см, буе – 4,4 см һәм калынлыгы – 2,3 см тәшкил иткән, тексты каурый каләм белән язылган һәм күн белән тышланып төпләнгән, XIX гасырга нисбәтле кульъязма догалык – миниатюр татар кульъязмаларының игътибарга лаек бер үрнәге.

Соңгылары турында «күбрәк гыйлемнәре чамалы, хәтерләре тишек мулла кисәкләренең шпаргалкаларын-

нан, ягъни уч төбендә яшереп тотып, мәгәр яттан сөйләгән кебек кычкырып укый торган догалыклар»[54] дип, түбәнсетүле бәяләмә белән килешеп булмый. Беренчедән, аларны һичничек наданлык һәм мәкерле максатлар белән бәйлисе килми. Нинди эчтәлекле булуларына карамастан, кулъязма китапларның аерым бер төренә – догалык җыентыкларына ихтирамлы мөнәсәбәт сакланырга тиеш. Икенчедән, андый догалыкны укымышлы ир-атлар гына түгел, хатын-кызлар да бик үз иткән. Төрле мәҗлесләргә, кич утыру һ.б. очрашу урыннарына һәрвакыт алып йөртү өчен дога китапларының нәкъ шундый җыйнак форматлары кулай булган дип уйлыйбыз.

Татар-мөселман китапларының титул битләре булмаган. Әсәрнең авторы һәм исеме текст башланган беренче биттә күрсәтелгән яисә текстның бетем өлешендә – колофонда әйтелгән. Колофонда әсәрнең исеме, авторы, кайда, кайчан һәм кем тарафыннан күчерелгән булуы теркәлгән. Традицион кулъязмачылыкта колофон тексты түбәнгә таба юллардагы сүзләре азая барып, очлаеп (почмакланып) төгәлләнгән. Кулъязма истәлекнең иң мөһим бу өлеше, татар кулъязмаларының ахыргы битләре еш кына җуелган булуы сәбәпле, сакланмаган. Сакланганнарында да мәгълүмат тулы түгел.

Колофоннарның тарихи чыганак буларак әһәмияте аеруча зур. Билгеле булганча, милли тарихыбызны язучылардан Шиһабетдин Мәрҗани һәм Ризаэтдин Фәхретдин иске кулъязма китапларның колофоннарындагы мәгълүматлардан аерым шәхесләр турында шактый информация туплаганнар. Татар кулъязма истәлекләренең колофоннарын максатчан өйрәнү, гомумән, китап күчерүчеләр, мәдрәсәләр һәм мөдәррисләр турында шактый тәфсилле мәгълүмат хасил итү өчен файдалы.

---

[54] Госманов М. Каурый каләм эзеннән..., 1994. – Б. 114.

Шуны да искәртергә кирәк, татар кулъязмаларының колофоннарында фарсыча язылган бетем өлеше сүзләре һәм шигъри юллар XVII–XVIII гасырда чагыштырмача күбрәк. Ул чор истәлекләрендә гарәп телендәге традицион «тәммәт тәмам» сүзләренә өстәмә рәвешендәге (шул ук мәгънәдә) фарсыча «шоде әст» гыйбарәсе ешрак очрый.

Тезмә текстларның исеме, иҗат ителгән вакыты һәм авторы, мөселман әдәбиятына хас булганча, гадәттә, әсәрнең ахыргы шигъри юллары эчендә белдерелгән.

Кулъязма китапларның һәм дәфтәрләрнең төп текстан буш урыннары соңрак хуҗалары, аларның балалары яки чит кешеләр тарафыннан өстәмәләр (мөнәҗәтләр, җырлар, туучы һәм вафат булучылар яисә башка вакыйгалар турындагы мәгълүматлар) белән чуарланган була. Балалар тарафыннан сызып-бозып, рәсемнәр ясап тутырылганнарын да еш күрергә мөмкин. Андый соңгы чор өстәмәләренең бер өлеше кәгазьгә мохтаҗлык булган 1920–1940 нчы елларга нисбәтле, ягъни XIX гасыр татар кулъязмаларының шактые шул чорда чуарлануга дучар булган.

Кәгазь кытлыгына һәм кыйммәтле булуына бәйле рәвештә, шулай ук башка сәбәпләр аркасында да кайбер авторлар һүм күчерүчеләр кулъязмаларны вак итеп язып терки торган булганнар. Мәсәлән, Габдерәхим Утыз Имәни, җәяү йөргәндә китапларын үзе белән йөртүе сәбәпле, йөге авыр булмасын дигән ният белән бик вак итеп язганлыгы турында шагыйрь Нигъмәтулла Солтанбәков теркәп калдырган[55].

Билгеле шәхесләрдән шагыйрь Хәсән Туфан гарәп хәрефләре белән иң вак язган кешеләрнең берсе булгандыр. Аның «язуы үтә вак (еш кына хәрефләренең биеклеге нибары 1,5–2 мм тәшкил итә), ләкин шуңа да карамастан, бик

[55] Нигъмәтулла Солтанбәков әсәрләре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 62.

пөхтә, хәрефләре тигез»[56] – миниатюр дәрәҗәдә булган.

Монда тасвирлап үтелгән үзенчәлекләр, әлбәттә, гомуми рәвештә сыйфатланды. Татар кульязмаларының бөтен хасиятләрен дә аңлатып бирү мөмкин түгел, алар бик күп.

## Кульязмаларның сакланышы

Хәзергәчә килеп ирешкән татар кульязмаларының сакланыш дәрәҗәләре төрлечә: бик яхшы хәлдә сакланганнары булган кебек, бөтенләй теткәләнеп-ертылып беткәннәре һәм битләре укмашып ябышканнары – гаять начарлары да бар. Татар кульязмаларының сакланышы турында гомумиләштереп әйтсәк, аларның күпчелеген уртача дип билгеләргә була. Тышлыклары төшкән яисә төпләреннән аерылган, кәгазь читләре тапланган булсалар да, андыйларны уртача сакланганнарга нисбәт итәргә мөмкин. Дөрес, шактый гына кульязма китап-дәфтәрләрнең башларындагы һәм ахыргы битләре җуелган була. Текст читләрендә язылмыйча буш калдырылган кәгазьләре чагыштырмача соңрак кисеп алынган нөсхәләр дә аз түгел. Алар исә, гадәттә, тәмәке төреп тарту өчен һәм кәгазь кытлыгы заманнарында вактөяк язу эшләренә куллану өчен киселгәннәр.

Күп укып файдаланылган кульязма китапларның таушалган урыннарын, ертылган кәгазьләрен хуҗалары тарафыннан элек үк реставрацияләргә омтылышлар ясалган. Алдагы һәм ахырдагы кәгазьләре төшкәннәренә реставрацияләүчеләр яңа битләр өстәп, тулыландырып язганнар. Узган гасырларда ук бик зур тырышлык белән, искиткеч пөхтә итеп яңартылган һәм төзәтелгән кульязма китаплар бар.

Еллар узган саен археографлар тарафыннан табыла торган кульязмаларның сыйфатлары начаррак кебек то-

[56] Мөстәкыймов И., Гәрәева А. Хәсән Туфанның тормышына һәм иҗатына караган яңа чыганаклар // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2020. – №1. – Б. 44.



*Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре.*
*XVII гасыр күчермәсенең фрагменты*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

елырга мөмкин. Ләкин моннан бер гасыр чамасы элекке археографларның табышлары да төрле дәрәҗәдә саклан-ган истәлекләрдән гыйбарәт булган. Мәсәлән, танылган татар археографы Сәед Вахиди (1887–1937) җыйган кулъ-язмалар белән тулырак һәм якыннан танышудан бу ачык күренә. Шулай ук археографик табышларның сыйфаты елдан-ел начар булуының, кулъязма истәлекләрнең башы-ахыры булмавының сәбәпләре, беренче нәүбәттә, таби-гый таушалуга һәм начар шартларда саклауга бәйле булса

да, бүтән үзенчәлекләре дә бар. 1980–1990 нчы еллардагы экспедицияләрдә дә яхшы сакланган, әйбәт тышлыклы кулъязмаларның 80% чамасы гарәп телендәге мәдрәсә дәреслекләре булганын искәртик. Аларның хуҗалары мәдрәсәне тәмамлаганнан соң аз файдаланганга күрә андый китаплар чагыштырмача төзегрәк хәлдә сакланганнар. Ә татар телендәге әдәби һәм тарихи әсәрләр теркәлгән яки башка төр кулъязмалар күп укылып, еш кулланылганлыктан әүвәлге заманнарда ук таушалу-теткәләнүгә дучар булган. Кулъязмаларның вакыт ягыннан искерә барып, физик тузулары белән бергә, соңгырак чорда җыелган ядкярләрнең бер өлеше элеккерәк еллардагы археографик эзләнүләрдән калган әйберләр икәнлеге дә истә тотылырга тиеш.

Хәзер табыла торганнары арасында аеруча кызыклы һәм фәнни яктан кыйммәтле истәлекләрнең очрап куюлары – эзләнүләрне туктатмаска, дәвам итәргә кирәклегенә ишарәли. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең 2024 ел җәендәге археографик экспедициясендә аеруча сирәк ядкярләр: Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәре һәм Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы күчермәләренең тулы (!) нөсхәләре[57] табылуы – моның ачык дәлиле. Әле халыкта сакланган хәтле мирасны җыю өчен тырышлыкны сүрелдермәскә иде. Һәрхәлдә, якындагы берничә дистә елларда кулъязмалар җыю эшенең туктатылмавы зарур.

## Текст төзелешенең кайбер үзенчәлекләре

Кулъязма истәлекләрнең кайбер текстологик үзенчәлекләренә игътибар итик.

Гарәп хәрефле кулъязма һәм басма иске текстлар белән эш иткән кешеләргә мәгълүм ки, элекке шигъри-тезмә әсәрләр

[57] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклану шифрлары: «8612т» һәм «8667т».

бер кәгазь битендә икешәр, ә кайбер очракларда дүртәр багана итеп язылганнар. Алар күз күреме өчен хәзерге газета-журналлардагы баганаларга охшаш булсалар да, башта бер багананы һәм аннары икенчесен уку тәртибендә түгел, ә иң башта беренче юлдагы ике баганадагы ике юл да рәттән укылып, калганнары шулай дәвам итәргә тиеш[58]. Әгәр дә бер биттә дүрт багана икән, алдан дүртесенең дә беренче юллары укылып, алга таба шул ук рәвешчә дәвам ителә.

Кайбер кульязма истәлекләрдә тезмә юллар баганалап бүленмичә, тоташ текст итеп язылган очраклар да аз түгел[59]. Андыйларда, гадәттә, тезмә-шигъри өлеш ахыры саен чәчәксыман гади генә бизәк рәсеме ясалган була.

Иске кульязма текстларда (бигрәк тә, шигъри әсәрләрдә) күчергән кеше тарафыннан юлларның тәртибе ялгыш язылган булса, андыйларны, гадәттә сызмыйча-бозмыйча, күп нокталар белән бер-берсен алыштыруны белдергән ишарәләр куелган.

Иҗат ителгән вакытлары элеккегерәк әсәрләрнең күчермәләрендә юлларның урыннарын дөресләү яки бер юл эчендәге сүзләрнең тәртибен алмаштыру өчен махсус ишарә-билгеләр кулланылган. Мәсәлән, Мөхәммәдьярның «Нуры содур» (1541 ел) поэмасының XVIII гасырдагы берничә кульязма күчермәсендә юлдагы ялгыш язылган сүзләрнең (кайбер очракта сүз өлешләренең) дөрес вариантын белдерү өчен алыштырасы компонентларның берсе өстенә кечкенә генә итеп «мим» һәм икенчесе өстенә ноктасыз «хә»

[58] Иске кульязма һәм басма текстлар белән эш итүче кайбер замандашларыбызның шигъри әсәрләрдәге менә шундый үзенчәлекне белеп җиткермәү мисаллары соңгы чорда чыккан китапларда күренгәли. Кайберләре бу китапның III бүлегендә искә алынды.

[59] Мәсәлән, XVII гасыр кульязма җыентыгындагы җыр тексты шундый рәвештә иде (Халык җырлары: XVII–XX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2019. – Б. 123). XIII–XX гасырлардагы татар кабер ташларында да шундый язылышлар күзәтелә.

хәрефләре (аерым язылыштагы рәвешләре) теркәлгән. Шулай итеп, «мим» белән тамгаланган сүз икенче урынга күчәргә, ә «хә» белән билгеләнгәне алдан укылырга тиешлеге күрсәтелгән. Кайбер очракларда «хә» хәрефе урынына ноктасыз «гайн» язылган яисә «v» рәвешендәге тамга куелган. Текстта ялгыш язылган юллар тәртибенең үзгәртелергә тиешлегенә дә кәгазь читендә «мим» һәм «хә» хәрефләре белән ишарә ителгән.

Күчерүче тарафыннан текстның бер яисә берничә сүзе төшереп калдырылган булып, кәгазь читендә өстәп язылган очраклар бик күп. Өстәмә сүз (сүзтезмә яки җөмлә) урыны төп текстта махсус берәр тамга белән билгеләнеп, кәгазь читендә шундый ук тамга рәсеме кабатланган һәм өстәләсе сүз (сүзләр) язылган.

Татар кулъязмаларында өстәмәләрне билгеләү өчен күпчелек очракта латин алфавитындагы v хәрефенә охшаш һәм аның эченә нокта төртелгән билге кулланылган. Андый тамга гадәттә язу юлының өстендә, ә кайчакларда юл астында да куелган. Иске язма истәлекләрдән 1523 елгы хан ярлыгында һәм Адниш хафизның 1554 елгы җыентыгында төп текстка өстәмә өчен ноктасыз v рәвешендәге тамга кулланылган, XVII гасырдагы һәм аннан соңгы чорлардагы татар кулъязмаларында да шундый билге очрый.

Кулъязма текстларда җөмлә (фикер яки абзац) башын белдергәндә иң беренче сүзе өстенә «сад» хәрефенең сүз башындагы язылышына охшаш  рәвешле махсус билге куелган. Кеше исемнәре яки башка төр атамалар санап-тезеп язылган вакытларда да шундый билге кулланылган. Андый билге аерым очракларда төп текстган аермалы төстәге (кызыл, яшел, шәмәхә һ.б.) язу карасы белән белдерелгән. Мондый ысул кулъязмаларда еш очрый.

Гарәп хәрефләре белән язылган текстларда сүзләрнең юлдан-юлга күчешендә хәзерге орфографиядәге кебек иҗекләрне бүлеп, сызыкча кую гадәте булмаган. Укы-

мышлырак кешеләр, гадәттә, сүзләрне бүлеп юлдан-юлга күчермәгәннәр. Кәгазь читендәге сүз күп очракта тулысынча язылган. Язу юлларының ике як читләре тигез рәвештә тулып торсын өчен гарәп хәрефләренең сузынкы язылышка яраклы «би», «син», «сад» шәкелләрендәге, шулай ук «фа», «каф», «кәф», «нун» һәм «йа» хәрефләрен сузыбрак язу кулланылган. Сузынкы хәрефләр белән язуның күркәм үрнәкләрен Коръән китапларында күрергә мөмкин. Шулай ук сүзләр һәм иҗек араларын иркенрәк итеп калдыру ысулы да булган. Шигъри текстларда юл тулып торсын өчен еш кына аның ахырына чәчәксыман бизәкләр ясап яки гади генә өч нокта (икесен аста, берсен өстә итеп) куйганнар.

Белемнәре уртача яки түбән дәрәҗәдәге кешеләр исә сүзләрне гадәттә өзек хәрефтән соң икенче юлга күчереп дәвам иткәннәр. Мәсәлән, «әфәнде» сүзенең «ә» хәрефе юл ахырында теркәлеп, сүзнең дәвамы яңа юлда язылган. Шулай ук, «угылы» сүзенең «әлиф»е яки «әлиф» белән «уау» хәрефе юлның ахырында, ә дәвамы яңа юлда язылу кебек төрле очраклар күрергә мөмкин[60]. Моның аерым кагыйдәләре булмаган. XX гасыр башындагы татар матбугатында сүзләрнең бүленеп юлдан-юлга күчешләрендә сызыкча куела башлаган һәм шул үрнәк кульязма текстларга да тәэсир иткән.

Гарәп каллиграфиясенең тиз язылышлы төрләрендә текстлар шактый тыгыз итеп, юллар ахырындагы берничә сүз югарыга таба дәвам итеп язылган. Шул рәвешле, язу юлларының сул яклары ярымтүгәрәк кебек бер-берсенә тоташкан нәфис күренеш хасил иткән.

Кульязма нинди язу төренә (нәсех, нәстәгъликъ һ.б.) караган булса да, хәрефләрнең нокталарын куймыйча язу тәҗрибәсе дә кулланылган. Андый ысул гарәп телендәге кульязмаларда еш очрый. Зур белемгә ия укымышлы зат-

[60] Гомумән, андый күренеш гарәп язуын кулланган башка илләргә дә элек-электән хас булган.

лар бик ашыгыч язмаларын, хатларын яисә башка кешеләргә белдерергә теләмәгән мәгълүматларын теркәгәндә дә ноктасыз язуны үз иткәннәр. Мәсәлән, Зәйнулла ишан Рәсүлинең хатлары шундыйлардан[61]. Аерым бер текстта еш кабатланган сүз-гыйбарәләрне, айларны һәм атнаның көн атамаларын, кеше исемнәрен дә ноктасыз язганнар. Аңлаешлы һәм төгәл язылышы таләп ителгән метрика язуларында да ноктасыз хәрефләр белән теркәлгән мисалларны күргәнебез булды. Мәсәлән, Вятка губернасының Әгерҗе авылы (хәзерге Әгерҗе шәһәре) имамы, ахун Әбүбәкер Җәгъфәр улы тарафыннан 1830–1840 нчы елларда теркәлгән метрика язмалары шундый. XX гасыр башында татарларда исем һәм фамилияләрдә хәрефләрнең нокталарын куймыйча язу киң таралган. Рәссам һәм скульптор, хаттат Бакый Урманче 1960–1970 нче еллардагы көндәлекләрендә дә аерым исемнәрне һәм гыйбарәләрне нокталар куймыйча язу ысулын кулланган[62].

Билгеле булганча, татар кулъязмаларында гасырлар дәвамында тыныш билгеләре куелмаган. Алар бары тик XIX гасыр ахыры кулъязма текстларында гына күренә башлаган һәм XX гасыр башында инде берникадәр тәртипкә салынып, 1920 нче елларда кагыйдәләре шактый камилләшкән.

Кулъязма текстларны күчерүчеләр протографларының битләре җуелган булуы сәбәпле билгесез калган яки тексты зарарланганлыктан танылмаган урыннарын буш калдырганнар. Күрәсең, күчерелгән әсәрнең бүтән нөсхәсеннән яңадан шул урынын ачыклап, тулыландыру күздә тотылгандыр. Менә шундый күренешкә бәйле рәвештә кулъязма китапларда берничәшәр яки ярты бит, аерым җөмләләр яисә берничә сүз язылмыйча, буш калдырылган урыннар күрергә мөмкин.

---

[61] Бер кулъязмасының факсимилесе «Татар археографиясе» сериясенең «Алдым каләм, яздым сәлам...» (2018) китабында 8 нче биттә бирелде. Ул хатның санаулы сүзләрендәге хәрефләрнең генә нокталары куелган.

[62] Бакый Урманче көндәлекләре: 1965–1976 еллар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2020. – Б. 10.

Аерым бер яисә берничә сүз урыны гына язылмыйча калдырылган очракларда, күчергән кеше протографтагы сүзләрне танымаган булуы да ихтимал.

## Тышлыклар

Кулъязма китап тышлыклары, гадәттә, катыргыдан яисә юка тактадан ясалып, тулаем күн белән тарттырып капланган. Еш кына күнне тышлыкның төп ягында, читләрендә һәм почмакларында гына кулланганнар. Фәкыйрьрәк шәкертләр исә тышлык өчен иске китап яки кирәкмәгән



*Кулъязма китап тышлыгы. XVIII гасыр*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*



*Кулъязма китап тышлыгы. 1840 ел*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

кәгазьләрне (еш кына хатларны һәм документларны) бер-берсенә ябыштырып, үзенә күрә катыргы хасил итеп, аның өстенә тукыма тарттырып куйганнар. Татар кулъязма китаплары бәрхет, ефәк, атлас, киҗе-мамык, алача һәм башка тукымалар белән тышланган. Коръән һәм башка затлы китапларны, төп тышлыгы нинди булуына карамастан, тагын бер кат тукыма белән тышлау гадәте хөкем сөргән. Андый тукымаларга алтын-көмеш җепләр белән бизәкләр дә чигелгән. Еш кына чигүле тастымал яки нәфис бизәкле яулыклар кулланылган. Күн тышлыкларга батырып төрле бизәк-орнаментлар төшергәннәр. Татар осталары тарафын-



*Мөхәммәдгали Болгарый тарафыннан эшләнгән кулъязма китап тышлыгы. XIX гасыр (Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты)*

нан Урта Азиядә ясалган тышлыкларда, шундагы китап традициясе үрнәгендә медальонсыман бизәкле рәсем эчендә китап тышлаучының (суххәф) исеме дә язылган. Урта Азия тышлыклары үз нәүбәтендә фарсы мәдәнияте йогынтысын кичергән. Бохара һәм Сәмәрканд якларында язылган татар кулъязмалары андагы китапларга охшаш булса, Төркиядә яисә Дагыстанда белем алган татар шәкертләре күчереп язган һәм төпләгән китаплар шул төбәктәгеләр үрнәгендә эшләнгән. Мондый табигый күренеш күп мисаллар белән раслана. Татар шәкертләре һәм муллаларының төп ватаннарыннан читтә вакытларында һәм илгә кайткач күчергән китап текстларында күрсәтелгән «Болгарый», «Казаный» һәм

бүтән шундый нисбәләре генә татар кешесе тарафыннан эшләнгән китап икәнлеген белдерә. XIX гасыр татар кульязмалары тышлыкларында теркәлгән «сухһәф Мөхәммәдгали Болгарый» исеме – хәзергәчә күп сакланганнарның берсе.

Татарларда кулланылган төрле кульязма китап тышлыклары фоторәсемнәрен милли сәнгатькә, китап тарихына багышланган альбомнарда һәм хезмәтләрдә күрергә мөмкин.

Тышлыклар өчен кулланылган, гамәлдән чыккан иске язу-кәгазьләр татар археографиясе өчен аерым бер әһәмияткә ия. Андый кәгазьләр, гадәттә, иске кульязма китап калдыклары, документлар һәм хатлардан тора. Кайбер китапларның шундый тышлыклары еллар узу белән таушалып, кәгазьләре аерылып төшү дәрәҗәсенә җиткән була. Күренгән хәтле язулары кызыксыну уятырлык булганнарын археографлар суда махсус җебетеп, хат яки документ битләрен бер-берсеннән аерып чистарталар. Мәсәлән, бер иске кульязма китапның тышлыгында XIX гасыр уртасына нисбәтле 33 кәгазьдә бер үк адресатка бәйле дистәләгән хатка юлыкканыбызны язган идек[63]. Ә Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең 2023 елда Арча районы авылларына оештырылган археографик экспедициясендә табылган 1779–1781 нче еллардагы хосусый актлар Пугачёв күтәрелешендә полковник дәрәҗәсендә катнашкан шәхескә бәйле булуы ягыннан да кызыклы. Алар да иске бер кульязма китап тышлыгы өчен файдаланылганнар[64].

Гомумән, шундый ысул белән эшләнгән иске тышлыкларны йөзләрчә данәдә суда җебетеп, кәгазьләрен берәмләп аерып, кызыклы табышларга тап булганлыгыбызны да искәртик. Иң беренче тәҗрибәм 1984 елда – үз авы-

---

[63] Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 38; Алдым каләм, яздым сәлам..., 2018. – Б. 9.

[64] Бу документларның дүртесенең текстлары басылды: Килешү-хокук язмалары (XVIII–XX гасыр башы) / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2023. – Б. 65–70.

лыбыздагы археографик табышларга бәйле иде. Ул вакытта бер иске кулъязма китапның үзеннән дә әүвәлгерәк язма битләрдән ябыштырып эшләнгән тышлыгын суга чылатып, җай белән генә аергалаган идем. Анда исә 1812 елгы рус-француз сугышы чорына бәйле татарча язылган тарихи документлар – Бөгелмә һәм Богырыслан төбәкләрендәге авыллардан сугышка җибәрелгән атлар, фураж һ.б. мәсьәләләргә бәйле язмалар булуы аңлашылды. (Аларны университеттагы укытучыбыз, гарәп язулы татар документаль чыганакларын өйрәнүче Фәһимә апа Хисамовага биргән идем). Аннан соң тышлыклардан аерылган ялгыз битләрне университет китапханәсенә – археограф Альберт Фәтхигә тапшырдым[65]. Милли китапханәдә эшләгәндә бик күп кулъязма тышлыкларыннан әһәмиятле истәлекләр – «Кыйссаи Йосыф»ның XVII гасыр күчермәсеннән фрагментлар, Габдерәхим Утыз Имәни һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләре, бәетләр, шактый күләмдә документлар һәм хатлар табылды.

## Авторлар һәм кулъязма күчерүчеләр

Иске язмалар гаять күп һәм төрле дәрәҗәдәге әсәрләрнең текстларын тәшкил итә. Ләкин шактыеның авторлары билгеле түгел. Әсәр текстлары тулы килеш хәзергәчә ирешкән булса да, кем тарафыннан иҗат ителгәнлекләре күрсәтелмәгән диярлек. Гадәттә, әүвәлге әсәрләрнең авторлары үзләрен белдерүне бик кирәксенмәгәннәр. Бу уңайдан, А.Фәтхинең XVI–XVIII гасырлардагы татар авторларына карата әйткән «Аларга әсәрнең язучысы кем булуыннан бигрәк, әсәрнең үзе, фикере, мәгънәсе кыйммәтлерәк булган»[66] дигән сүзләрен искә алыйк.

[65] Алар Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «8066т–8085т, 8087т–8100т» шифрлары белән саклана.

[66] Кулъязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш..., 1968. – Б. 8.

Иске кулъязмалардагы шигъри әсәрләрнең күплегенә һәм төрлелегенә караганда, каләм тибрәтүчеләрнең әүвәл байтак булганлыгы аңлашыла. XVIII гасырда татарлар яшәгән төбәкләрдәге мәгърифәт үзәкләрендә – мәдрәсәләрдә Шәрыкның классик әдәбияты өйрәнелгәнен исәпкә алганда, шигърияткә тартылган шәкертләр күп булганын чамаларга мөмкин. Әдәби мирасны тулырак күзаллар өчен, әлбәттә, авторлары билгесез булган шигырьләрнең дә тәфсилләп өйрәнелүе зарур. Әдәбият галиме Гали Рәхим XVIII–XIX гасырлардагы татар шагыйрьләре турында «тарихта исемнәре вә әсәрләре сакланганнарының саннары 30–40-лап булса, онытылганнары, әсәрләре тәләф булып, югалып, янып беткәннәре ... ихтимал ки, йөзләп саналырга тиештер»[67], – дигән. Г.Рәхим аларны, мәхәллә имамы, мөдәррис кебек вазифаларыннан соң гына шагыйрь булып саналганнар, әмма араларында виртуозлык дәрәҗәсенә килеп җиткән муллалар да булган, дип бәяләгән[68].

Борынгы әдәбият тарихындагы әсәрләрнең авторларын ачыклау һәм тәгаенләү буенча галимнәребез эзләнә һәм уңышлы нәтиҗәләргә дә ирешәләр. Шуның белән берлектә, хаталанулар һәм тупас ялгышулар да булгалый.

Татар әдәбияты тарихы белгечләре тарафыннан хәзерге вакытка XVIII гасырда иҗат иткән берничә дистә татар шагыйре ачыкланган дип санала[69].

Татар дәүләтләре бәйсез гомер кичергән дәверләрдә кулъязма китап күчерү эше белән махсус белгечләр, нәфис язу осталары – хаттатлар, мулла-хафизлар шөгыльләнгән.

---

[67] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек: 17, 18 һәм 19 нчы гасырларда иске әдәбият. – Казан: Татарстан Җөмһүриятенең дәүләт нәшр., 1922. – Б. 137. *Тәләф* – әрәм булу, юкка чыгу.

[68] Шунда ук. – Б. 138.

[69] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2: XV–XVIII гасырлар / төз. Р.Рахмани. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б. 310.

Ә ханлыклар яулап алынганнан соң бу эшне тулаем диярлек татар шәкертләре башкарган, аерым хаттат-каллиграфлар, муллалар һәм укымышлы затлар да берникадәр китаплар күчереп язганнар.

XVI гасырда китап күчергән затлардан исемнәре мәгълүм ике кешене атарга мөмкин. Шулардан берсенең – Аднлиш хафиз ибне Мөхәммәдаднаш хафизның Мәскәүгә илче булып баргач, тоткынлыкта чагында 1554 елның җөмадиел-ахир (май) ае уртасында язып төгәлләгән җыйнак кына җыентыгы мәгълүм. Ул хәзергәчә Мәскәүдә – Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклана. Әлеге җыентыкта «Сиражел-колүб» һәм «Шәраигыль-әхкям» исемнәрендәге ике чәчмә әсәр, шулай ук Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани шигырь-хикмәтләре теркәлгән. «Сиражел-колүб» әсәренең асылы гарәп телендә булып, аның фарсычага тәрҗемәсе нигезендә Аднлиш хафиз татар теленә ирекле тәрҗемә иткән дип санала һәм бу әсәр Казан ханлыгы чорының әдәби ядкәре булып исәпләнә.

1581 елда Хаҗи Бәйрәм бине Хаҗи Булат тарафыннан язылган гарәпчә-татарча сүзлек – уналтынчы гасырга нисбәтле кыйммәтле кулъязма ядкәрләрнең икенчесе. Ул хәзерге вакытта Казан университетының Фәнни китапханәсендә саклана.

XVII–XIX гасырларда китап күчерү белән шөгыльләнгән шактый хаттатларның исемнәре билгеле. Мәсәлән, Иванай бине Урсай, Юныс бине Иванай, Габдрахман бине Туймөхәммәт, Илми Үтәмеш улы, Сәйфелмөлек Зәйнетдин улы, Габдеррәшит бине Мортаза, Җәгъфәр бине Ягъкуб, Сөбхан бине Габделкәрим, Ибраһим бине Ядкәр, Морадым бине Ибраһим, Нияз бине Хәйдәр, Фәхретдин бине Ибраһим, Сәгыйть бине Хәмит, Таҗетдин Ялчыгол, Хәсән бине Вәлит, Җәгъфәр бине Әднакол, Колмөхәммәт Солтанбәк улы, Минуш бине Мостай, Сәгъдетдин бине Габделҗәлил, Мозаффар бине Габделгаффар, Габдерәхим Утыз Имәни, Габделхәмит

бине Динмөхәммәт, Гобәйдулла бине Кәлимулла, Газизҗан бине Мөхәммәтҗан, Хәйрулла бине Габделхәбир, Гайса бине Туктаргали, Рәхмәтулла Әмирхани, Шиһабетдин Мәрҗани, Камалетдин бине Җамалетдин, Лотфулла Әлмәти, Каюм Насыйри, Мостафа Чутайи һәм башка исемнәрне атарга була. Аларның күбесе гомерләре буе китап күчерү шөгыленнән аерылмаганнар. Татар тарихында 20 яшеннән башлап 95 яше тулганчы барлыгы 223 китап күчереп язган Габденнасыйр бине Сабит, берничә йөз данә Коръән китабы күчергән Хөсәен Әлмөхәммәт улы, 70 яше тулганнан соң да китаплар күчергән Таҗетдин бине Хәсән, 90 яшенә хәтле бу эш белән шөгыльләнгән Сәйфулла бине Йөртекәй кебек фидакяр шәхесләрнең исемнәре билгеле. Шуны искәртергә кирәк, китап күчерү белем, тырышлык, сабырлык белән бергә, бик күп вакыт та таләп иткән. Мәсәлән, Коръәнне һәм бүтән калын китапларны күчереп язу өчен 2–3 ай өзлексез вакыт таләп ителгән.

Күркәм язулы һәм тиешенчә яхшылап төпләнгән кульязма китаплар шактый кыйммәт бәягә сатылган. Мәсәлән, Бөгелмә өязе Әлкәй авылында күчереп язылган Коръән тәфсиренең бер томы 1841 елда 200 сумга сатылу факты һәм ул чорда бер ат бәясе 20 сум торганлыгы турында тарихчылар язып калдырган.

Каурый яки камыш каләм белән кулдан язылган һәм күчерелеп тиражланган кульязма китаплар традициясе XIX гасырның икенче яртысына хәтле тотрыклы рәвештә һәм аннан соң да берникадәр дәвам иткән.

Кульязма китапларның тулы, һичъюгы бетем өлешләре сакланганнарының ахырларында «Тәммәтил-китаби бигауни Аллаһи әл-Мәлики әл-Ваһһаби» дигән традицион сүзләр язылган була. Теләсә нинди эчтәлектәге (дини, тарихи, әдәби, географик һ.б.) кульязма китап һәм әсәр ахырында язылып килгән әлеге җөмләнең гарәп теленнән тәрҗемәсе: «Бар нәрсәләрнең хуҗасы һәм юмарт Аллаһның ярдәме

белән бу китап тәмам булды» дигәнне белдерә. Бу гыйбарә мөселман халыкларының (гарәп, фарсы, татар, төрек һ.б.) китап традициясендә киң билгеле. «Әл-Мәлик» һәм «Әл-Ваһһаб» – Аллаһның күркәм исемнәреннән. Әл-Мәлик – хөкемдар (кыямәт көненең хуҗасы), Әл-Ваһһаб – бөтен нәрсәләрне бүләк итүче, юмарт дигәнне белдерә. Иске кульъязма истәлекләр белән эш итүче галимнәр бу сүзләрнең мәгънәсе белән таныш. Шулай ук тарих һәм әдәбият белән кызыксынган яисә гарәп теленнән һәм Ислам дине турында азмы-күпме мәгълүматы булган студентлар, шәкертләр һ.б. бу сүзләрнең мәгънәсен чамалый. Әдәби, тарихи һәм бүтән төр кульъязма истәлекләргә багышланган фәнни хезмәтләрдә, шулай ук кульъязмаларның тасвирламалары буларак нәшер ителгән белешмә китаплардагы өземтәләрдә әлеге гыйбарә бик еш китерелә. Чөнки кульъязма китап традициясе буенча текстларның колофон дип аталган бетем өлешендә нәкъ шушы гыйбарә язылган.

Элек-электән кульъязма китапчылыкта килгән бу үзенчәлек гарәп язуындагы басма китапларда да дәвам иткән. Кайбер галимнәр борынгы әдәби әсәрләрне тикшергәндә «Тәммәтил-китаби...» гыйбарәсендәге сүзләрне ялгыш аңлаткан очраклар булганлыкны искә алып, тагын бер кабатларга тиешбез. Мәсәлән, галимә Ялкын Әхмәтгалиева «Кисекбаш китабы»н өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтендә бу әсәр кульъязмаларының тасвирламасын бирә һәм аларның берсен әл-Малик әл-Ваһаб күчергән дип яза[70]. Әдәбият тарихына караган бер монографиядә «Пәнднамә» әсәренең тәрҗемәсе турында сүз барганда әл-Малик әл-Ваһһабны – кеше исеме дип кабул итеп, аны шулай ук кульъязма

[70] Төгәллек өчен авторның үз текстыннан өземтә китерәбез: «...В нескольких местах рукописи указано имя переписчика: Аль-Мелик-аль-Вахаб» // Ахметгалеева Я.С. Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». – М.: Наука, 1979. – С. 13.

күчерүче булгандыр дип фаразлаулар[71], Я.Әхмәтгалиева фикерен кабатлап, мәсьәләне тирәнтенрәк ачарга омтылулар булды[72]. Борынгы әдәбият галиме Фәрит Яхин «Кыйссаи Сәйфелмөлек» әсәренең кулъязма күчермәләре турында язганда болай ди: «Темников кулъязмасының тагын да бер үзенчәлеге бар. Анда, шушы тәмамлаудан соң тагын да ике бәетле бер бүлек урнаштырылган һәм аңа «Тәммәтел-китаби бәгувен Аллаһи Әл-Мәликел-Ваһһаб» («Аллаһының ярдәме белән китапны Әл-Мәликел-Ваһһабның тәмамлавы») дип исем бирелгән. Әл-Мәликел-Ваһһаб исемле кешенең татар кулъязмалар күчерүчесе икәнлеге «Кисекбаш китабы» белән бәйле инде искәртелгән иде»[73]. Шулай итеп, галим кулъязмадагы ике бәйтне «Әл-Мәликел-Ваһһабныкы» дип белдерә һәм «Әл-Мәликел-Ваһһап ул – кулъязмалар төзүче шәхес. XVIII йөздә яшәгән...»[74] дип, аның кайсы чорда яшәгәнлеген дә «ачыклый». Бу гына түгел, галимнәребездән берсе хәтта «Тәммәтил-китаби бигауни...» дигәндәге بعونی (бигауни) сүзен Багуни дип ялгыш укып, имеш, Багуни – Малик Ваһһабның нисбәсе (ягъни, ул Багун дигән топонимга нисбәтле кеше дип) «фәнни ачыш» ясаган иде. Башка галимнәребезнең хезмәтләрендә дә «...күчереп язучы әл-Ваһаб»[75] гыйбарәсен очратырга мөмкин.

Бүтәнчәрәк ялгыш фаразлар да күренгәли. Мәсәлән, Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1997 елда дөнья күргән басма-

---

[71] «...В традиционном заключении упоминаются имена «Аль-Малик Аль-Ваһаб» и «Факри» (Факири?). Первый, – по всей вероятности, переписчик списка...» // Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика: вопросы взаимосвязей и поэтики. – Казань: изд-во ун-та, 1993. – С. 165.

[72] Яхин Ф. Урта гасырлар татар әдәбияты: татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: «Раннур» нәшр., 2003. – Б. 163, 236.

[73] Шунда ук. – Б. 290.

[74] Шунда ук. – Б. 356.

[75] Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе: соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кулъязмаларның тасвирламалары (1972–2012 еллар). Бишенче кисәк. – Казан, 2016. – Б. 31.

сында (89 нчы биттә) «Төхфәи мәрдан» әсәренең тексты ахырында «Хәтме китаб фит-тарих бигәүн әл-мәлик әл-хитаб» дип бирелгән җөмләнең хәзерге телгә күчермәсендә «Китапның тәмамлану тарихы...» рәвешендәге, төгәл булмаган аңлатмасы басылган. Шуңа карата китапның 167 битендәге искәрмәсендә текстны басмага әзерләүче тарафыннан болай диелгән: «КДУ («Б») кулъязмасында әсәрнең тәмамлануы турында бүлекчәнең исеме язылган булса да, сүзләренең ялгыш, хаталы һәм урынсыз килүләре, җөмләнең зәгыйфьлеге мәгънәгә төшенүне кыенлаштыра. Сүз сөрешенә караганда, анда мәликкә ягымлы карашның булмавы сизелә. Шагыйрь моны заманында шелтәгә дучар булган мәлик (хан, хөкемдар) рәвешендә белдерергә тырыша. Әмма бу әле ачыкланып бетмәгәнлектән, исемнең баштагы сүзләрен генә алам».

Әгәр дә «...бигауни Аллаһи әл-Мәлики әл-Ваһһаби» гыйбарәсе кулъязма китаплар күчергән кешене белдерә дип, юри генә гөманласак, ай-һай, гаҗәеп бер әүлия булыр иде ул. Чөнки төрле гасырларда һәм төрле ил-дәүләтләрдәге мондый сүзләр язылган йөз меңнәрчә кулъязмаларны бер үзе башкарган – титаник хезмәт куючы булып чыгар иде. Ләкин төрле фантазияләргә урын юк, хакыйкать бер генә һәм ул билгеле. Малик белән Ваһһаб сүзләре кеше исемен белдергән булса, китапларда язганда алар арасында «угылы» яки «бине» дигән сүз булыр яисә Малик Ваһһаби дигән сурәттә язылыр иде. Әлеге сүзләрнең һәр очракта да «әл» дигән алкушымча (артикль) белән язылуын исәпкә алганда, әл-Малик белән әл-Ваһһаб – билгеле бер затның (бу очракта Аллаһы Тәгаләнең) күздә тотылуын белдерә.

Кулъязма ядкярләрне күчергән кешеләрне кайбер галимнәр автор дип билгеләгән очраклар да бар. Бигрәк тә, элекке чыганакларда «язучы» сүзенең «китап күчерүче» мәгънәсендә кулланылган булуын төшенеп җитмәү зур ялгышлыкка китерә. Ягъни, «моны яздым мин», «бу китап-

ны язучы» (борынгырак текстларда «битедем, «битүче») кебек татарча яисә гарәп телендәге «кятиб», «кәтәбәһә» һ.б. гыйбәрәләрне хәрефкә хәреф кабул итеп, авторы дип аңлаучылар бар. Мәшһүр галим Ризаэтдин Фәхретдиннең үз хезмәтләрендә һәм мәкаләләрендә кульязма әсәрләрне (шул исәптән, Коръәнне) күчергән кешеләргә нисбәттә «язучы» гыйбарәсен кулланган булуына карап, ул затларны автор дип хаталанган фән әһелләребез дә булды. Әүвәлге текстларда (XX гасыр башына кадәр) әсәрнең авторы мәгънәсендә «язучы» сүзе түгел, ә «мөәллиф», «мөхәррир», «мосанниф», «сахиб» кебек гарәп сүзләре кулланылган.

Кульязма әсәрләрнең авторларын бүтән мәшһүр әдипләргә нисбәт итү күренеше булганлыгын да истә тотарга кирәк. Мәсәлән, мәшһүр фикер иясе Җәлалетдин Руминың «Мәснәви» әсәренә охшаш булганга Гашыйк пашаның 1330 елда язылган «Гарибнамә» поэмасын татарлар һәм башка төрки халыклар Румига нисбәт иткәннәр. Суфичылык әдәбиятында киң кулланылган илаһи гашыйклык белән әсәр авторының исемен буташтырып, «Гарибнамә»не «Гашыйк Руми» дигән исем белән дә йөрткәннәр. «Гарибнамә»нең 1735–1744 елларда эшләнгән кәгазьгә күчерелгән тексты[76] колофонында «Ошбу Гайшы корумны мулла Ягъкуб яздым» дигән сүзләр шуның ачык дәлиле. (Дөрес, бу очракта әсәрнең исеме бозык рәвештә теркәлгән).

«Сираҗел-колүб» әсәрен 1554 елда күчергән Аднишь хафизны автор итеп тәгаенләүнең һич тә ачык дәлиле юклыгын да искәртик. Галимнәр бу әсәрнең кульязма күчермәләре табылып торуын һәм XIX гасыр уртасыннан алып XX гасыр башына кадәр дистәгә якын басмасы дөнья күргәнлеген әйтеп, «Авторлык фәкать Мәскәүдә саклана торган автографлы кульязмада гына бар. Казан басмаларында да

[76] Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. – 10 фонд, 6 тасвир, 53 саклану берәмлеге.

язучының исеме куелмаган»[77], – диләр. Менә бу уңайдан, шушы әсәрне Адниш хафиз 1554 елда иҗат иткән булса, ул татар халкы арасында ничек итеп башка күчермәләрдә таралыш алган икән соң дигән сорау туа. Чөнки Адниш кульязмасы Мәскәү архивында XX гасыр уртасында гына табылган бит! (Бу мәсьәләгә китапның соңгы бүлегендә дә тукталдык).

XVIII гасыр татар тарихында билгеле шәхес – мулла Морад – күтәрелешенә багышланган шигъри әсәрнең текстында ук авторы «Бикмәт угылы Нияз» дип ачык күрсәтелгән булса да, аны башка кеше иҗат иткән дигән ялгыш караш яшәп килә. Ягъни, әсәрне күчергән кешеләрнең берсе – текст ахырына өстәп язылган «Үзем үлсәм китап калыр ядкяр, ушбуны язучы Мостафа Нәзир углы дәйү беләсездер» дигән юлларга нигезләнеп, Мостафа Нәзир улы автор буларак китаптан-китапка күчә килде. Гәрчә аның «язучы» дигән сүзе «күчерүче» мәгънәсендә кулланылган. Болар турында ачык итеп аңлатып язган булсак та[78], әдәбият тарихы китабының 2022 елда чыккан икенче томында да (288 биттә) һаман шул ук ялгыш мәгълүмат басылган.

Кульязмалардагы иске текстларның авторын тәгаенләп булмаганда, әсәрләрнең кайсы төбәккә яки җирлеккә нисбәтле икәнлеген билгеләргә омтылу галимнәрне аеруча мавыктыра. Андый очракларда еш кына тел үзенчәлекләренә (лексик составка, саңгырау һәм яңгырау тартык авазларны белдергән хәрефләрнең – мәсәлән, *дип/тип* – кулланылуына, кушымчаларга) игътибар юнәлтелә. Ләкин мондый ысулга нигезләнеп нәтиҗәләр ясау һәрвакытта да дөрес түгел. Бер үк әсәр текстының төрле күчермәләрендә дә аермалар барлыгы ту-

---

77 Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / төз. һәм фәнни мөх. Г.Дәүләтшин. – Яңарт. 2 нче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 2022. – Б. 170.

78 Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 136.

рында язган идек. Мәсәлән, «Кыз хикәяте» текстының XVIII гасырга караган ике күчермәсенең берсендә «д»лаштыру шактый көчле (*егет, әйт, ут, ришвәт, илтә* кебек сүзләр *егед, әйд, уд, ришвәд, илдә* дип язылган) һәм андагы *дөшде, деләрсә, деләрсән, дүрт, йатдылар* сүзләренең икенче күчермәдә *төшде, теләсә, теләрсән, түрт, йаттылар* дип теркәлгәнлеген искәрткән идек[79]. Димәк, элекке әсәрләрне күчереп язган кешеләр тарафыннан автор текстына һәм имлясына үзгәрешләр кертелгәнлеге исәпкә алынырга тиеш. Мондый очракларда, чынлап та, әсәр текстының берничә кулъязмасы нигезендә генә автор үзе ничек язган булуын ачыклау шактый читен. Кулъязма истәлекләрнең тел-имля үзгәрешләренә карата Гали Рәхим болай дигән: «Һәрбер күчерүче, үзе дә сизмичә, күчергән китапларының теленә азмы-күпме үзгәрешләр керткән. Мондый күчерүчеләр бик күп булып, ничә гасырлар буена килгәнгә, бу үзгәрешләр җыела-җыела, кайбер күбрәк укыла торган китапларның телен асыл нөсхәдән әллә никадәр ераклаштырганнар. Күчерүчеләр татар булганга, чыгытайчаның татарлашуы бер дә гаҗәп түгел. Чыгытайча сүзләрнең госманлыча белән алыштырылуы да татар күчерүчесе өчен бик мөмкин эш. Чөнки безнең татарның борынгы «китапча», ягъни әдәби теле шул чыгытайча, госманлыча һәм татарчадан оешкан бер тел булган»[80].

Язма тел белән җирле сөйләм теле зур аермага ия булганлыгын да истә тотарга кирәк. Шунлыктан, татар кулъязма истәлекләренең кайсы төбәккә караганлыгын билгеләү шактый читен һәм ялгышлыкларга китерергә мөмкин.

Миркасыйм Госманов кулъязмалар турында сүз йөрткәндә берәрсен күчергән кеше турында «кулы ныгып җитмәгән шәкерт» дигән сыйфатламаны кабатларга яратты. Шундый

---

[79] Кыз хикәяте / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2012. – Б. 36–37.

[80] Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: Борынгы дәвер. Икенче бүлек..., [1923]. – Б. 111.

гыйбарәне Мәүла Колый поэмалары турында язган минем мәкаләмә дә ул өстәткән иде[81]. Гәрчә Мәүла Колый поэмалары теркәлгән 1754 елгы кульязма җыентыкның иясе һәм күчергән кешесе палеографик үзенчәлекләре буенча һич тә шәкерт диярлек түгел. Ә, киресенчә, аның үз заманына күрә шактый белемле, шома итеп язуны үзләштергән, тәҗрибәле булганлыгы күренеп тора. Моның шулай икәнлегенә төшенү өчен кульязманың факсимилесенә күз төшерү дә җитә[82]. Язуы буенча кемнеңдер шәкертме, түгелме икәнлеген якынча билгеләү мөмкин булса да, нәкъ шушы Мәүла Колый поэмалары очрагын «шәкерт кулы» дию дөреслеккә туры килми.

Безнең тарафтан тексты бастырылган «Түләк китабы» дастанының кульязмасы[83], беренче карашка, тотрыклы язарга өйрәнеп җитә алмаган шәкерт тарафыннан күчерелгән кебек тоелырга мөмкин. Ләкин, бу дастанны күчергәндә Сибгатулла Багдановның (1820–1875) яше 20 чамасында булган[84]. Шунлыктан, аны да әйтелгән категориягә кертү мөмкин түгел. (Ул соңрак Уфада Мәхкәмәи шәргыядә – Дини Нәзарәтендә казый булган кеше).

Патша заманындагы кайбер имамнарның, мулла икәнлеген белмәгән очракта, метрикалардагы язулары буенча фикер йөрткәндә, чынлап та «кулы ныгып җитмәгән шәкерт» дияргә (һәм ялгышырга) мөмкин булыр иде. Хәер, язу-почерк мәсьәләсе хәзерге заманның галимнәре һәм әдипләренеке дә гаять күп төрле һәм тотрыксыз, хәтта кайберләренеке гомерләре буена, гүя, «кулы ныгып җитмәгәндәй», ямьсез һәм хаталырак икәнлеген дә онытмыйк.

[81] Мәрданов Р. Гасый җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар... // Казан утлары. – 1996. – №10. – Б. 162.
[82] Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты»..., 2008. – Б. 58–79.
[83] Түләк китабы: дастан / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2008. – Б. 42–62.
[84] Шунда ук. – Б. 10.

## Элекке кулъязмаларның вакытын ачыклау

Татар кулъязмаларының күбесендә еллары күрсәтелмәгән. Күп кенә очракта кулъязмаларның бетем өлешендә елы язылмыйча, күчереп тәгәлләнгән вакыты «рәҗәбнең бишендә, җомга көн, өйлә намазыннан соң» кебек язмалар белән генә белдерелгән. Тексты тулы сакланмаган кулъязмаларның вакытларын якынча тәгаенләү читен.

Палеографиядә датаны билгеләү өчен кәгазь төп күрсәткеч булып тора. Фәндә кәгазьнең эшләнгән елыннан алып файдаланылганга кадәрге (ягъни, фабрикадан чыккан продукциянең кулланучыга килеп ирешкәнче) вакыты XVI–XVII гасырлар өчен уртача 5–7 ел узган дип карала, ә XVIII–XIX гасырлар өчен якынча 2–3 ел дип санала. Әгәр дә бер үк кулъязманың текстында төрле елларда җитештерелгән кәгазьләр кулланылган булса – андыйларның датасын соңгысы буенча билгеләү кабул ителгән.

Кулъязма китапның, текстның күчерелгән вакытын билгеләү өчен төрле факторларга мөрәҗәгать итәргә туры килә. Алар түбәндәгеләр:

1. Иң башта кәгазьнең су билгесе – филигране булу-булмавы тикшерелә. Булган очракта, махсус альбомнардан охшашын эзләп, кәгазьнең эшләнгән вакыты тәгаенләнә[85]. Урта Азия кәгазьләрендә су билгеләре булмаганлыктан, мәсьәлә катлаулырак. Россиядә җитештерелгән кәгазьләргә XIX гасырда төшерелә башлаган штемпельләр дә датаны билгеләү өчен бер күрсәткеч булып тора.

2. Текст язылган кәгазь форматының да кайвакытта ачыклык кертергә ярдәме була. Мәсәлән, XVII–XVIII гасырлардагы Һолландия яки башка Европа иленең кәгазьләре

[85] Кайбер кәгазь фабрикаларында озак еллар дәвамында кулланылган бер төрле үк филиграньнәр датаны билгеләү өчен нигез була алмый. Андый очракта башка күрсәткечләргә игътибар итү зарур.

кечерәк форматлы. Шулай ук кәгазьнең сыйфаты да аермалы – европаныкылар югарак һәм яхшырак сыйфатлы, Россия кәгазьләре калын һәм тупасрак.

3. Кулъязманың вакытын-чорын билгеләү өчен күрсәткечләрнең берсе – язу карасы. Мәсәлән, язу юллары кәгазен зарарлаган булса, ядкярне гадәттә XVII гасыр һәм XVIII гасырның беренче яртысына нисбәт итү ихтималы зур. Ә текст шәмәхә яки башка төстәге химик кара белән язылган икән, ул XIX гасырның соңгы чирегеннән дә элеккерәк түгел дигән сүз.

4. Кулъязмадагы текстның эчтәлеге буенча кайчан иҗат ителгән әсәр икәнлеге ачыкланса, күчермәнең вакытын тәгаенләүдә ул да ярдәм итәргә мөмкин.

5. Кулъязманың язылыш рәвешенә һәм текстның имлясына, палеографик үзенчәлекләренә әһәмият бирү зарур. Күчерелгән вакытын билгеләү өчен алар да файда итә.

Гомумән, кулъязманың датасын ачыклау читенлек тудырганда, әйтелгән үзенчәлекләрнең бөтенесенә дә комплекслы нигезләнеп, вакыты якынча билгеләнә. Фәндә кулъязма истәлекләрнең датасын якынча тәгаенләүдә ихтималлык чикләре чирек гасырдан алып бер гасырга кадәрге ара белән билгеләнә.

Һәрхәлдә, татар кулъязма истәлекләренең даталарын билгеләгәндә, югарыда күрсәтелгән үзенчәлекләрне исәпкә алу белән беррәттән, белгечнең тәҗрибәсе дә зур әһәмияткә ия.

Бер үк кулъязма китап яки җыентыктагы су билгеләрендә, гадәттә, аерым бер ел яисә рәттән ике елныкы (мәсәлән, 1825 һәм 1826) төшерелгән була. Шулай ук, кайбер очракларда берничә елга аермалы (мәсәлән, 1791 һәм 1795), хәтта егерме яки күбрәк елны эченә алган кулъязмалар да була (мәсәлән, 1805 һәм 1825)[86]. Кайчакларда кәгазьләр эшләп

[86] «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар..., 2009. – Б. 20, 47, 50.

чыгарылган вакытларыннан шактый соң кулланылган. Мәсәлән, чыгарылган елын белдергән «1783» филиграненә ия кәгазьгә өч дистә еллап соңрак – 1814–1817 елларда Салих Йосыф улының язмалары теркәлгән[87]. Ә 1850–1860 нчы елларда «Әнмүзәҗ», тыйб һәм тәҗвид текстлары язылган бер җыентыкның[88] филигране «1785» елны белдерә, ягъни әлеге очракта кәгазь 70 еллап соңрак кулланылган. Мондый зур аермалы фактлар татар кульязмаларында күп очрамаса да, андыйларның булганлыгы истә тотылырга тиешле.

Әйтелгән үзенчәлекләрдән тыш, кульязмаларда даталары күрсәтелеп тә, алар ялгыш мәгълүмат бирергә мөмкин. Кульязмалардагы даталар ике төрле: текст теркәлгән вакытны элеккерәк яисә соңгырак чорныкы итеп белдерүләре ихтимал. Текстны элеккерәк (борынгырак) итеп күрсәтү, гадәттә, кульязманы күчергән кешенең үзе файдаланган протограф-күчергечтәге датаны автоматик рәвештә язып куйганлыгына бәйле. Андый мисаллар бар. Мәсәлән, Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Төхфәи мәрдан» поэмасының 1962 елда табылган кульязмасында датасы 1600 ел диелгән[89]. Чынлыкта, соңрак күчергән кеше нәкъ менә протографтагы датаны язып куйган. Әлеге кульязманың күчерелгән вакыты XVII гасыр ахырына нисбәтле[90].

Мөхәммәдьярның икенче күләмле әсәре – «Нуры содур» поэмасының текстында шулай ук күчерелгән елына бәйле катлаулы мәсьәлә бар. Автор тарафыннан иҗат ителгән вакыты һиҗри 948 ел (ягъни, милади 1541 ел) дип тәгаен күрсәтелгән. Шулай булса да, аның соңгырак – 1079

---

[87] Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. – 10 фонд, 7 тасвир, 116 саклану берәмлеге.
[88] Шунда ук. – 10 фонд, 6 тасвир, 13 саклану берәмлеге.
[89] Юзиев Н., Фәтхи А. Уралда саклванган әдәби хәзинәләр // Совет әдәбияты. – 1963. – №12. – Б.120.
[90] Кадыров Р. Источники по истории старотатарской письменности..., 1999. – С. 120–121.

елда (миладича 1668 елда) күчерелгән датасы, әсәрнең ахыргы шигъри юлларына бәйләп, гүяки, әсәр шул вакытта язып тәмамланган кебек мәгънәдә теркәлгән[91]. Әлеге – 1668 елны белдергән кулъязма чынлыкта XVIII гасыр ахырында күчерелгән. Ягъни, протографтагы 1668 нче ел бер гасырдан соңгырак күчермә нөсхәдә кабатланган. Димәк, кулъязма истәлекләрдәге мондый төр даталарга аеруча әһәмият бирелүе зарур.

Кайбер кулъязмаларның төшкән битләрен төп текстның күчерелгән вакытыннан соңрак реставрацияләп, тулыландырып язган кеше еш кына үз исемен һәм эшен башкарган датаны колофонда теркәп куйган була. Андый дата, якынча, 40–100 ел соңгырак вакытны белдерә.

Иске кулъязмаларны тузганнан соң яңадан төпләгәндә һәм тышлаганда төп тексттан соңрак өстәлгән кәгазьләрдә төгәл ел күрсәтелгән очраклар да була. Мәсәлән, археографик сериядә басылган «Дастане җайә» кулъязмасының ахырына соңрак өстәлгән кәгазендә 1769 ел белдерелгән. Менә шундый даталар төп текстның төгәлрәк вакытын билгеләгән чагында ялгыш нәтиҗәгә дә китерергә мөмкин. Мәсәлән, шул ук кулъязманың дастан теркәлгән өлешендәге кәгазе 1655–1671 елларга нисбәтле. Ә кулъязма җыентыкта күрсәтелгән бердәнбер дата (1769) бер гасырга соңгырак.

Татар кулъязмалары арасында бергә төпләнгән һәм тышланган, төрле заманга караган текстлар да еш очрый. Андыйлар, гадәттә, этисенең шәкерт вакытындагы кулъязмасы белән улының мәдрәсәдә укыган чорыныкы булырга мөмкин. Уртак тематикага караган берничә әсәрнең бергә төпләнгәннәре дә бар. Конволют җыентыкларның берсендә генә датасы күрсәтелгән очракта, бөтенесен шул елга нисбәт итү дөрес булмый. Мәсәлән, җыентыкта датасы билгеле

[91] Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь. – Казан: Татар. китап нәшр., 1997. – Б. 228, 307–308.

текст 1880 елгы дип күрсәтелгән һәм шул ук төптә яшкелт-зәңгәрсу кәгазьле бүтән текст та теркәлгән булырга мөмкин. Соңгысының исә кәгазе XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башына нисбәтле. Димәк, конволют җыентыкларның даталарын тәгаенләү мәсьәләсендә аеруча игътибарлы булу зарур.

Татар кульязма китапларының башларында һәм ахырларында буш-чиста кәгазьләр өстәп төпләгәннәр дип әйтеп үткән идек. Менә шундый битләрдә һәм китапның кәгазь читләрендә төп текстан соңрак теркәлгән төрле даталар күрсәтелгән язмалар шактый була. Алар китапны сату-алу турындагы, туучылар һәм вафат булучылар, хуҗалык-көнкүреш һәм сәүдә эшләренә бәйле яисә бүтән төрле мәгълүматлардан тора. Кульязманың төп текстында күчерелү датасы булмаган очракта соңгырак чорда өстәп язылган датаның кайсын да булса берсен күрсәтү дөрес булмый. Андый өстәмәләрнең бары тик иң элекке елны белдергән датасы гына төп текстның шуннан искерәк икәнлегенә ишарә итәргә мөмкин.

Кульязма текстта әгәр дә елы-вакыты билгеле булмаса, анда язылган административ берәмлек атамалары (өяз, округ, волость һ.б.) ниндидер чорны билгеләүгә ярдәм итүе ихтимал кебек. Ләкин алар да ялгыш нәтиҗә тудыра ала. Мәсәлән, Минһаҗетдин Җәбәли 1878 елда язган тарихи хезмәтендә шуннан бер гасыр элегрәк гамәлдән чыккан административ берәмлекләрне (Алат, Арча, Җөри һ.б. юлларны – даругаларны) телгә алган[92]. Шулай ук, 1820 нче еллардагы алыш-биреш язмаларында ярты гасыр чамасы әүвәлгерәк административ берәмлек атамалары кулланылган[93]. Казан университеты китапханәсендә Аллаһыяр Суфи әсәре «Сөбател-гаҗизин»нең 1841 елгы язма нөсхәсе ахырында

[92] Җәбәли Минһаҗетдин. Тәварихы Болгарийә вә татарийә / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2023. – Б. 32.

[93] Килешү-хокук язмалары..., 2023. – Б. 11–12, 86, 91–98.

аның Уфа вилайәте Казан юлында күчерелгәнлеге турындагы мәгълүматы бар. Бу очракта кульязманың күчерелгән урыны – иске протографыннан алынган мисалларның берсе. Чөнки 1841 елга хәтле андый административ бүленеш атамалары гамәлдән чыкканга инде 70 еллап вакыт узган булган.

Тарихтан билгеле булганча, болгар-татарларда һиҗри (мөселманча) календарь куллану 922 елда Идел буе Болгар дәүләте Ислам динен рәсми төстә кабул иткән вакыттан башланган. Ә рус календарь системасы татарларда XVIII гасырда гына киң кулланылышка кергән[94].

Борынгы Русьта 988 елда христиан дине белән бергә Византиядәге дөнья яратылышыннан алып исәпләнеп килгән календарь кабул ителеп, аны гасырлар дәвамында кулланганнар. Шундый исәп буенча 7208 елда Россия патшасы Пётр Беренче календарьны үзгәртү турында әмер чыгарган. Пётр патшаның әлеге реформасы нигезендә, 7208 елның 31 декабреннән соң яңача рус календаре – Христосның туу көне (раштуа) – 1 гыйнвардан алып 1700 нче ел дип исәпләнә башлаган[95].

[94] Бу күренешне XIX гасырга нисбәт иткән фикерләр булса да, XVIII гасырга караган татар язма чыганакларында милади ел исәбе күп теркәлгәнлеге күренә (Воззвание и переписка вожаков пугачевского движения в Поволжье и Приуралье..., 1988. – С. 203–379; Килешү-хокук язмалары..., 2023. – Б. 39). Татар телендәге хосусый акт язмаларында елларның һиҗри һәм милади календарь исәпләре белән язылу үзенчәлекләренә тукталган идек (Килешү-хокук язмалары..., 2023. – Б. 38–39).

[95] Рус календаренең яңача исәпләнә башлаган вакыты турында Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтендә дә язылган (Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде / төз. Ә.Хәйруллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – Б. 204); Пронштейн А.П., Кияшко В.Я. Вспомогательные исторические дисциплины: учебное пособие для студентов исторических факультетов педагогических институтов. – М: Просвещение, 1973. – С. 29; Ермолаев И.П. Историческая хронология: методическое пособие для студентов исторического отделения Казанского университета. – Казань: изд-во ун-та, 1978. – С. 23, 26–27.

Кулъязма ядкярләрнең күрсәтелгән төгәл вакытларын фән әһелләре һиҗри ел исәбеннән миладига күчергәндә төгәлсезлекләр җибәргән очраклар бар. Шулай ук рус хронологиясендә 1700 елга кадәр кулланылган календарьне белеп җиткермәү дә ялгыш нәтиҗәләр ясарга сәбәп була.

Ялгыш нәтиҗәләргә мисал итеп түбәндәге хаталануны искә төшерик. «Сөембикә бәете»нең текстында «Мең дә биш йөз унбиштә» дип язылган датага карап, фольклорчы галимнәр әлеге әсәрне XVI гасырга нисбәт итеп шактый хаталандылар. Өстәвенә, бу бәет 1912 елда Габделгалләм Рәшиди тарафыннан иҗат ителгән һәм халык арасында бик тиз зур популярлык казанган. Бәетнең датасын билгеләүдәге ялгышлык турында тәфсилләп язган идек[96]. Ләкин дәлилләп язганнарыбыз галимнәргә тәэсир итми – «Татар әдәбияты тарихы» китабының яңартылган 2022 елгы II томында «Сөембикә бәете» Казан ханлыгы чорына нисбәтле итеп тасвирланган[97].

Кулъязма текстларда рус сүзләре булуы шулай ук датаны ачыклау өчен ярдәм итә. Мәсәлән, Казан ханы Сахибгәрәй исеменнән 1523 елда бирелгән тарханлык ярлыгына бәйле шәҗәрә текстына мөрәҗәгать итик. Уфада саклана торган иске шәҗәрә язмасының читендәге «Сахибгәрәй ханнан бирелгән грамота Шәехәхмәд Мөхәммәд угылына йите кешеләр илән, йите кешеләре илән тархан диб исемләнеб» дигән мәгълүмат үзе үк рус чыганагыннан алынганга ишарә итә. Әгәр дә ул элекке татарча язмадан күчерелгән булса, рус сүзе – «грамота» урынына «ярлык» дип яисә бүтәнчә аталган булыр иде. Шушы ук ыруның Ык буе авылларында сакланган башка бер шәҗәрә язмасындагы исемнәрнең һәм хәтта елының да рус документындагы 7151 (1643) ел грамо-

[96] «Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2013. – Б. 8–34.
[97] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т..., 2022. – Б. 72, 77, 80, 81.

тасыннан алынган булуын язган идек[98]. 7151 рәвешендәге дата бары тик рус хронологиясенә генә хас булган.

Кулъязма истәлекләрнең заманын билгеләү өчен аларда теркәлгән текстларның тел үзенчәлекләре һәм аерым лексик берәмлекләре дә азмы-күпме файда итәргә мөмкин. Мәсәлән, тарихи вакыйгаларга бәйле мәсьәләләр, патшахакимнең исеме, рус теленнән кергән берәр сүз теркәлгән булуы һ.б.

Даталарны тәгаенләү турында сүз баргач, Европача ел исәпләренең юлиан һәм григориан календарьлары белән эш иткәндәге төгәлсезлекләр белән очрашырга туры килүен дә искә алырга кирәк. Календарь системаларының юлиан төрен григорианчага тәңгәлләштергәндә кайсы гасыр өчен ничә көн кушылырга тиешлеге турында махсус белешмә ярдәмлекләр булса да, галимнәребез илтифатсызлык күрсәтә. Мәсәлән, мәшһүр татар рәссамы һәм скульптор Бакый Урманченың туган көне (шул исәптән, энциклопедиядә) төрлечә бирелгәнлеге турында язган идек[99].

## Текстологиягә бәйле кайбер мәсьәләләр

Иске кулъязмалардагы текстларны бастырган вакытта әсәрнең билгеле булган күчермәләренең һәммәсен (фрагментларын да) тәфсилләп чагыштырып чыгу зарур. Чөнки басмага хәзерләнә торган төп текст никадәрле тулы-бөтен кебек тоелса да, кайбер сүзләре һәм җөмләләре ялгыш язылган яки бөтенләй төшеп калган булуы ихтимал. Текстның башка күчермәләренә мөрәҗәгать итү хаталарны ачыкларга һәм кимчелекләрне төзәтергә ярдәм итә. Мәсәлән, «Татар археографиясе» сериясендә нәшер ителгән «Кыйссаи Мансур», «Кыз хикәяте», «Дастане җәйә», «Чыңгызнамә»

[98] Мәрданов Р. Без – Бәзәкә нәселе. – Казан, 2018. – Б. 35.
[99] Бакый Урманче көндәлекләре..., 2020. – Б. 27–28 б.

һ.б. китапларны басмага хәзерләгәндә үткәрелгән чагыштырулар нәтиҗәсендә күп нәрсәләр ачыкланды. Әгәр дә шул ук әсәрнең нәшер ителгән текстлары булса, аларны шулай ук чагыштырырга кирәк. Чөнки кульязма истәлекнең һәрберсендә өстәмә һәм төгәллек кертердәй урыннары булуы мөмкин, шулай ук аңлаешсыз кайбер гыйбарәләрне тәгаенләү өчен текстларны чагыштырып тикшерүнең файдасы зур.

Чагыштырулар нәтиҗәсендә текстка ачыклык кергән кайбер мисалларны искә алыйк. «Түләк китабы» текстында булган башка галимнәр тарафыннан аңлатылган сүзләрдән «суна» дигәннең мәгънәсе тәгаенләнде[100]. Дастандагы «билән салып суна алган» гыйбарәсе суга (күлгә) сал төшереп үрдәк аулауны белдергәнлеге ачыкланды. (Сунар – аучы сүзе дә нәкъ менә шул тамырдан). Дастанның элегрәк басылган вариантларында «Алтын киезгә ултырган» һәм «Алтын тезегә ултырган» рәвешле бирелгән (соңгысында «тезегә» сүзенең «тәхеткә» булуы ихтимал дип аңлатылган) гыйбарә дә бар. Аны җентекләп тикшергәч, «тез» (тәз) сүзе борынгы төрки телдә «ияр» мәгънәсен белдергәнлеге, гомумән аның атка бәйле булганлыгы ачыкланды. Димәк, «алтын тез» дигәндә «алтын ияр» күздә тотылган. Шул ук Түләк дастанындагы «ай көзге» сүзтезмәсенә карата галимнәрдә төрле фикерләр булган иде. М.Госманов аның дөресе «ал» (алтын) дип аңлатты. Ләкин «ай» (дөресе – айа) сүзе борынгы төрки телдә «кул учы, уч» дигәнне белдергән. Иске әдәбиятка багышланган хезмәтләрдә «айа» сүзе нәкъ шулай – «уч» (ладонь) дип күрсәтелгән[101]. Төрки телләрдән хакасчада «айа» сүзе «уч» мәгънәсендә хәзер

[100] Түләк китабы..., 2008. – Б. 14–16.

[101] Фазылов Э. Хорезмийские памятники XIV века. Т. 1. – Ташкент: изд-во «Фан», 1966. – С. 34; Наджип Э. Историко-сравнительный словарь тюркских языков XIV века. На материале «Хосрау и Ширин» Кутба. Кн. I. – М.: Гл. ред. Вост. лит-ры, 1979. – С. 388.



*«Түләк китабы»ның XIX гасыр күчермәсе*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

дә кулланыла икән. Татар теленең кайбер сөйләшләрендә (мәсәлән, Әгерҗе сөйләшендә) «кул аявы хәтле» (уч хәтле) яки «кул аявы кадәрле» дигән гыйбарәләрне әле дә ишетергә мөмкин. Гадәттә, бу сүзтезмә нәрсәне дә булса үлчәп, якынча күләмен белдергәндә кулланыла. Шулай итеп, дастандагы «ай көзге»нең «кул көзгесе» икәнлеге беленде. Безнең тарафтан хәзерләп чыгарылган «Түләк китабы»ндагы кайбер башка сүзләрнең дөрес вариантлары шул басмада бирелгән чагыштырма таблицада да теркәлгән[102].

[102] Түләк китабы..., 2008. – Б. 67–70.

Галим Марсель Әхмәтҗанов без чыгарган текстта «хата» табып, аны бик зур кимчелек рәвешендә язганлыгын да искә алыйк. Ул фаш иткән «хата» дастан текстындагы «убал» сүзе турында иде. Мәкалә авторы болай дип язды: «...факсимилендәге «абал» («апал», «опал») сүзе нилектәндер «убал» диеп укылган»[103]. Иске татар дастанында ничек итеп рус телендәге «опал» сүзе булырга мөмкин соң? Юк, әлбәттә. Чөнки «убал» – гарәпчә «вәбал» (гөнаһ, гаеп, язык) сүзеннән үзгәребрәк борынгы төрки телгә инде күптән кергән. Бу турыда А.Тимергалин сүзлегендә язылган һәм анда мисалга «Идегәй» дастанындагы «Убалын кая куярсың?» дигән өзек тә бирелгән. Әлеге сүз кайбер төрки телләрдә (мәсәлән, кыргызчада) шул ук мәгънәсендә хәзер дә кулланыла.

Тагын бер мисалга игътибар итик – «Кыз хикәяте» текстында «йөк» (йек) дигән архаик сүз очрый. Аның мәгънәсе «йон, мамык, каурый» дигәнне белдерә. Бу сүз хәзерге татар телендәге «җегерләү» сүзенең килеп чыгышын ачыкларга да ярдәм итә. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «җегерләү» – «эрләү»[104] дип билгеләнгән. «Кыз хикәяте» әсәрен өйрәнеп бастыру дәвамында ачыклануынча, «җегерләү» сүзе әүвәл «җек (йөк, йек) эрләү» булганлыгы һәм кайвакытта «йон-җек» дигән парлы сүз буларак кулланылып, «йон җегерләү» рәвешендә сакланган икән. Димәк, элекке әсәрләрнең текстлары хәзерге татар телендәге кайбер сүзләрнең этимологияләренә ачыклык кертү өчен дә ярдәм итә.

«Татар археографиясе» сериясе басмаларында дөнья күргән тезмә әсәрләрнең хәзерге язуда бирелү үзенчәлекләреннән берсе турында искәртеп һәм аңлатып язган

---

[103] Әхмәтҗанов М. «Түләк китабы»ның яңа кульязмасы // Мәгариф. – 2011. – №1. – Б. 77.

[104] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. – Тулыл. һәм төзәт. 2 нче басма. 2 т.: Г–Й хәрефләре – Казан: Татар. китап нәшр., 2020. – Б. 325.

идек[105]. Аны бу урында да кабатлау урынлы булыр. Билгеле булганча, «ы» һәм «е» авазлары гарәп язулы иске текстларда бер үк – «йа» хәрефе белән теркәлгән. Элек-электән көйләп укылган «Кыйссаи Йосыф», «Бәдәвам», «Бакырган китабы», «Кисекбаш» һ.б. әсәрләрне, шулай ук күпсанлы мөнәҗәтләрне укучылар юл ахырларындагы «булды, барды, күрде, килде» кебек рифмадаш сүзләрне «булди, барди, күрди, килди» дип әйтүләре буыннан-буынга күчеп килгән. Шунлыктан, үзара рифмалашкан сүзләрдәге соңгы иҗекләренең «ы» һәм «е» хәрефләрен хәзерге бсмаларда «и» дип бирү мәгъкуль. Мондый күренеш татар текстологиясендә яңалык түгел, әлбәттә. Габдулла Тукайның «Су анасы» текстындагы «И, пычагым кергери» гыйбарәсен искә алу да җитә.

Элекке кульязмалар белән эш иткәндәге бер алымны монда искәртеп китсәк, бәлки яшь белгечләргә файдасы булыр. Катлаулы кульязма текстларны хәзерге хәрефләргә күчергәндә үзем мондый ысул кулланам. Башта зур форматлы (хәзергечә әйтсәк, А4 күләмендәге) кәгазьне иңе белән куеп, шуның уң як тарафына кульязма текстын аңлаешлы рәвештәге гарәп хәрефләре белән (хаталарын үзгәртмичә), иркенрәк юл аралары калдырып күчерү башкарыла. Аннан соң кәгазьнең сул ягында – һәр юлның каршысында текст хәзерге татар хәрефләре белән языла. Иске текстлар белән эшләүнең мондый ысулын студент вакытыбызда галим Хатип ага Госман күрсәткән иде. Борынгырак, таушалган һәм начар танылла торган кульязма чыганакларны өйрәнгәндә һәм аларны бастырырга хәзерләгәндә әлеге ысул бик уңайлы.

Безнең галимнәр (филология белгечләре – фән докторлары һәм кандидатлары да) «транскрипция» һәм «транслитерация» терминнарының мәгънәләрен аңламыйча эш итүе – ике каен арасында адашып йөрүгә тиң, хроник «баш бәласе»нә әйләнеп беткәнлеген тагын бер искәртеп үтәбез.

[105] Нигъмәтулла Солтанбәков әсәрләре..., 2024. – Б. 41.



*«Кыз хикәяте»нең XVIII гасыр күчермәсе*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

Гарәп язуыннан гамәлдәге татарчага күчерелгән текст бездә чыгып килә торган китапларда нихәтле генә «транскрипция» дип бирелсә дә, ул, чынлыкта, һичничек «транскрипция» була алмый. Бу төшенчәләрнең ялгыш кулланылуын үзебез егерме еллап элек үк белдереп үткән идек[106]. Шунлыктан, текст белән эш итәргә алынучы һәркем яхшы белергә тиешле, элементар һәм принципиаль нәрсәләрне кабатлап-аңлатып тору ихтыяҗы юк та кебек. Ләкин искә төшерергә мәҗбүрбез: транскрипция нииндидер тел яки

[106] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Җыен» нәшр., 2006. – Б. 17.

диалекттагы авазларны шартлы билгеләр белән белдерүне аңлата. Гарәп язулы текстларны хәзерге алфавитка күчерү очракларында «транслитерация» терминын куллану дөресрәк. Чөнки транслитерация – бер язу системасы хәрефләрен икенче язу системасы хәрефләре белән алмаштыруны (мәсәлән, гарәп алфавитындагы текстны кирилл хәрефләре белән бирүне) белдерә.

1990 нчы еллардан соң чыккан китапларда, шулай ук журналларда да гарәп язуыннан хәзерге язуга күчерелгән текстларның аерым сүзләре бирелешендә татар орфографик кагыйдәләренә туры килми торган, чынлап та, транскрипция элементлары кулланылды. Ягъни, гарәп хәрефле тексттагы ноктасыз «гайн»не һәм «һәмзә» билгеләрен хәзерге язуда биргәндә апостроф тамгасы белән белдереп, мөгез чыгарулар күзәтелде.

Телебез кагыйдәләрен тупас бозуның тагын бер төрен искә алырга тиешбез. Ул – фәнни текстологиядә дини гыйбарәләрне, бигрәк тә Коръән сүзләрен дөрес укуны таләп иткән махсус орфоэпик кагыйдәләр (тәҗвид) куллану белән кирәгеннән артык мавыгу. Кайбер белгечләрнең китапларында гарәп сүзләре берничәшәр (2–4) сузык аваз белән язылганын күрәбез. Мәсәлән, «әәмиин», «әл-әхыйлләәәәү», «дүнйәә», «каалэллааһү Тәбәәракә вә Тәгааләә», «ләә йәмүүтү», «сәәгатүн», «шәәәәъ» һ.б.[107] Хәлбуки, татар теленең орфографиясенә багышланган бер генә фәнни хезмәттә дә мондый рәвештәге язылыш кагыйдәләре юк. Гарәп телендәге дини язмаларны дөрес итеп укуны һәм дөрес артикуляцияне таләп иткән тәҗвид – хәзерге татар телендә басыла торган текстларның тиешле-тиешсез өстәмәләр һәм грамматик үзгәрешләр белән чуарлануын таләп итми.

[107] Мондый мисалларга тукталган идек: Һадиев И., Мәрданов Р. Татар теле – фән теле: тарихи чыганакларга багышланган татарча фәнни хезмәтләрне нәшер итү культурасы турында. – Казан, 2021. – Б. 39.

Теләсә кайсы фәнни хезмәт авторының, үзбелдеклеләнеп, кабул ителгән орфографиягә үз кагыйдәләрен көчләп тагарга һич кенә дә хокукы юк. Билгеле булганча, гарәп язулы текстлар белән эшләүче галимнәр моңарчы К.З.Хәмзин, М.И.Мәхмүтов, Г.Ш.Сәйфуллин авторлыгында (беренче басмасы 1965 елда) чыккан «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге (татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре)» хезмәтенә таянды. Анда гарәп теленең танылган һәм тәҗрибәле белгече М.Мәхмүтов тарафыннан эшләнгән төгәл кагыйдәләр бар һәм галимнәр алардан тайпылмаска тырышты. Мәсәлән, «гарәп теленнән алынган сүзләрдәге озын һәм кыска сузык авазлар (фонемалар) татар телендә озынлык-кыскалык белән аерылмый» дигән принцип-кагыйдә сакланып килде. Фәнни оешмалар тарафыннан нәшер ителгән басмалар нәкъ менә фәнни кагыйдәләр кысасыннан чыкмаска тиеш. Һәрхәлдә, татар теленең рәсми кабул ителгән язу кагыйдәләре белән санлашырга, аларны үтәргә һәм сакларга бурычлыбыз!

Татарлар яшәгән төрле төбәкләргә 1980–2000 нче елларда оештырылган археографик экспедицияләр вакытында гарәп хәрефле иске язмалар арасында очраган хикмәтләрнең берсен искә алып китү дә кирәк. Ул да булса 1970 нче елларда искеләрен фотога төшерү ысулы белән күбәйтелгән дини китаплар – бигрәк тә дин нигезләре һәм догалыклар, шәмаил һәм җавапнамә («Мөһер шәриф»). Менә шундыйларны татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә сатып, кәсеп итүчеләр була иде. Аларның денсезләре исә шәмаил һәм җавапнамәләрнең бөтенләй ялган вариантын – гарәп язуына охшатыбрак сызгаланган имитацияләрен сатудан да тайчанмады. Әлеге «изге сүз»ләрдә «әлиф»тән башка аерып танырлык һичбер хәреф әсәре дә юк иде диярлек. Гарәп язуын белүчеләр аз калган 1970–1980 нче елларда шундый төр «дини әдәбият» белән кесә калынайтучылар булганлыгы да – безнең язмачылык тарихындагы ямьсез сәхифәләрнең берсе.

## Татар кульязмаларын өйрәнүчеләр

Татар кульязма истәлекләрен өйрәнгән археографларның беренчесе буларак Ибраһим Хәлфин исәпләнсә, XIX гасырда Казан университетында эшләгән галимнәрдән Христиан Френ, Карл Фукс, Александр Казимбәк, Илья Березин, Иосиф Готвальд кебекләр дә татар язма чыганакларын өйрәнүгә игътибар биргәннәр һәм үз өлешләрен керткәннәр. Болардан тыш, XIX гасырда халкыбызның тарихи һәм әдәби язмаларын тикшерүгә татар галимнәре Габдерәхим Утыз Имәни, Хөсәен Әмирханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов һәм Каюм Насыйри күп көч куйганнар. Аларның эшен мәшһүр шәхесләр Галимҗан Баруди, Ризаэтдин Фәхретдин, Габдулла Апанаевлар дәвам иткән. Татар кульязмаларын туплап өйрәнү белән Николай Катанов та шөгыльләнгән.

Татар кульязма китаплары белән фәнни кызыксыну XIX гасырның беренче дистә елларында башланган. Казан университетының татар теле укытучысы Ибраһим Хәлфин татар тарихи кульязма чыганагының текстын өйрәнеп, аны «Әхвали Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исеме астында 1822 елда Казан университеты матбагасында бастырып чыгарган. Татар шагыйре Габдерәхим Утыз Имәни гасырлар буе кульязмалар хәлендә күпләп таралган һәм укылган борынгы әдәбият җәүһәре «Кыйссаи Йосыф» әсәренең төрле күчермәләре нигезендә тәнкыйди текстын хәзерләгән, аның беренче басмасы 1839 елда нәшер ителгән. Төрки-татар әдәби ядкәрләреннән «Кисекбаш», «Ахырзаман», «Бәдәвам», «Мәликә китабы» кебек мәшһүр әсәрләр татар наширләре тарафыннан 1840–1850 нче елларда чыгарылган һәм шул вакыттан башлап 60–70 ел эчендә дистәләгән басмаларда дөнья күргән. Халык арасында кульязмалардан укып йөртелгән бүтән иске кыйссалар һәм дастаннар, шигъри әсәрләр дә XIX

гасырда бастырып чыгарылган. Шул рәвешчә, алар бөтенләй онытылу һәм югалудан саклап калынган.

Ризаэтдин Фәхретдин XX гасырның башында һәм беренче чирегендә дә татар археографик истәлекләрен туплау һәм тикшерүне дәвам иткән һәм бу өлкәдә Сабир Алимов, Сәед Вахиди, Нәүширван Яушев, Фазыл Туйкин, Гали Рәхим, Вәли Зәбиров, Габделхәй Хәбибуллин, Әбүкәрам Шакиров тырышып хезмәт куйганнар. 1921–1930 нчы елларда Татарстан Мәгариф халык комиссариаты карамагында эшләгән Гыйльми үзәк (Академүзәк) тарафыннан кульязма истәлекләрне барлау, туплау һәм өйрәнүгә зур игътибар бирелгән. Тик, XX гасырның дәһшәтле утызынчы елларында татар кульязма ядкярләрен өйрәнүчеләрнең репрессияләнүе сәбәпле, фәнни оешмаларда археографик эзләнүләр шактый кимегән. 1940 нчы елларда татар кульязма истәлекләрен чикләнгән күләмдә барлау һәм өйрәнү белән мөгаллим һәм рәссам Сәлах Камал, танылган педагог Шәриф Сайкин, әдип һәм фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт кебек аерым фидакяр затлар гына шөгыльләнгән.

1950 нче еллардан алып татар кульязма мирасын өйрәнгән галимнәрдән Гаяз Ишмөхәммәтов, Зәйнәп Максудова, Әмир Нәҗип, Габдрахман Таһирҗанов, Мостафа Ногман, Шакир Абилов, Җәвад Алмаз, Фазыл Фәсиев исемнәрен атарга кирәк.

1959–1992 елларда Казан дәүләт университеты Фәнни китапханәсенең Шәрык кульязмалары секторы мөдире булып эшләгән галим Альберт Фәтхи – татар кульязма чыганакларын җыю һәм өйрәнү эшенә иң зур өлеш керткән белгечләрнең берсе.

Казан дәүләт университетының фәнни-археографик экспедицияләрен оештырган һәм 1963–1987 елларда җитәкләгән галим Миркасыйм Госманов татар археографиясендә тирән эз калдырды.

Археограф Марсель Әхмәтҗанов 1972 елдан алып та-

тар кулъязма чыганакларын туплауда һәм өйрәнүдә армый-талмый хезмәт куйды. Ул Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Мирасханәсе»нең мөдире булып эшләде, меңләгән кулъязма истәлекләрне өйрәнде һәм матбугатта чыгарды. Аның эшен хәзер шәкертләре дәвам итә.

Татар халкының археографик мирасын өйрәнүгә һәм пропагандалауга әдәбиятчы һәм текстолог галимнәрдән Хәй Хисмәтуллин, Якуб Агишев, Хатыйп Госман, Нил Юзиев, Мәсгуть Гайнетдин, Марсель Бакиров, Хатыйп Миңнегулов, Камил Дәүләтшин, Рафис Әхмәтов, Әнвәр Шәрипов, Әнвәр Хәйри, Сәлим Гыйлаҗетдинов, Нәҗип Исмәгыйлев, Заһир Шәйхелисламов кебекләр үз өлешләрен керттеләр. Тарихчы һәм археограф Дамир Гарифуллин татар кулъязмаларын туплаучы һәм пропагандалаучы буларак танылды. Өлкән буын галимнәргә алмашка 1980–1990 нчы елларда Җәүдәт Миңнуллин, Искәндәр Гыйләҗев, Фәрит Яхин, Раиф Мәрданов, Ильяс Мөстәкыймов, Айрат Заһидуллин һ.б. килделәр.

Тарихчы Җәүдәт Миңнуллин 1991 елда Казан дәүләт университетының археографик экспедициясе һәм 1992–2012 елларда университет белән Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең берләштерелгән экспедициясе җитәкчесе булды. Айрат Заһидуллин, Татарстан Милли китапханәсенең хезмәткәре, кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире буларак, археографик эзләнүләр белән утыз ел дәвамында фидакярләрчә шөгыльләнә, 2015 елдан алып хәзерге вакытка хәтле һәр елда республикабыз районнарына археографик экспедицияләр оештыра һәм катнашып килә[108].

Соңгы ике гасыр дәвамында татар кулъязма истәлек-

[108] Болар хакында тәфсилләп язылды: Милли китапханәнең археографик экспедицияләре..., 2022. – 250 б.

ләрен өйрәнгән археограф галимнәр, әдәбиятчы-текстологлар тырышлыгы нәтиҗәсендә дистә меңнәрчә тарихи ядкәрләр сакланып калды, бик күп язма чыганаклар өйрәнелде һәм фәнни әйләнешкә кертелде. Гомумтөрки язма истәлекләр белән берлектә, Идел буе татар әдәбияты һәм тарихы җәүһәрләреннән Өмми Камал, Мөхәммәтәмин, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, Кадыйргали бәк, Мәүла Колый, Габди, Габдессәлам, Батырша, Габдеррәхим Утыз Имәни, Колмөхәммәд Ушмыви, Әбелмәних Каргалый, Габделҗәббар Кандалый, Акмулла һәм башка күп авторларның әсәрләре, «Түләк», «Чыңгызнамә», «Аксак Тимер», «Таһир белән Зөһрә» кебек мәшһүр дастаннар, «Кисекбаш», «Авык» һәм бүтән кыйссалар, тарихи елъязмалар һәм сәяхәтнамәләр, җыр-бәетләр кебек бай фольклор әсәрләре, шулай ук татар халкының иҗади-рухи хәзинәсенең башка мәрҗәннәре халыкка кайтарылды.

Татар кульязмаларының һәм кульязма китабының күп гасырлардан килгән гаҗәеп бай һәм киңкырлы тарихы бар. Кульязма китапларга, аларны өйрәнүгә багышланган хезмәтләр дөнья күргән булса да, нәкъ менә татар кульязма китабын әтрафлап тасвирлаган гыйльми һәм популяр китап хәзергәчә юк әле. Моннан чирек гасыр элек «Татар кульязма китабы» (2000) дигән исем белән аталган китап нәшер ителгән иде, тик аның исеме җисеменә тәңгәл килеп бетми, һәрхәлдә, анда китапчылык тарихы төрле яклап тасвирланмаган. «Татар китабы» (2013) дигән альбомда да әлеге мәсьәлә өлешчә һәм чикләнгән рәвештә генә яктыртылды.

***

Кульязмаларны өйрәнү турында сүз барганда Казан шәһәрендә махсус Кульязмалар институты оештыруга ихтыяҗ барлыгы вакыт-вакыт күтәрелеп торуын да искәртергә кирәк. Бу мәсьәләгә җитди итеп әдәбият галиме Нил Юзиев (1931–1996) тукталган иде. Аерым алганда аның мондый

фикере булды: «Язма ядкярләрне җыйнау, саклау, фәнни эшкәртү буенча Татарстанда гыйльми үзәкнең – фәнни-тикшеренү институтының булмавы үзен нык сиздерә. Үз мәдәниятләренә хөрмәт белән караган дәүләтләрдә һәм халыкларда мондый үзәкләр күптәннән эшләп килә. Әрмәнстанда, Грузиядә, Үзбәкстанда, Азәрбәйҗанда бу эш белән махсус институтлар шөгыльләнә. Татарстанда да шундый институтны – Кулъязмалар институтын – академия системасында булдыру көн тәртибенә баса»[109]. Галимнең бу фикерләре иске татар язуына багышланган хезмәттә дә кабатланды[110].

Соңгы елларда Казан шәһәрендә татар һәм көнчыгыш телләрендәге кулъязма истәлекләрне бөтенесен бер урынга җыярга дигән (дөресе – берникадәр шомландыргыч) хәбәрләр дә ишетелде. Аның төп шомы-хәвефе шунда ки – сакланышлары болай да бик үк яхшы булмаган кыйммәтле ядкярләрне күчереп йөртү вакытында тагын да зарарланулары куркыта.

Кулъязмаларны өйрәнү институты турында фикерләр һәм проектлар төзелеп, ул киңәшү-тикшерү дәрәҗәсенә иреште. Ниятләнгән институт өчен махсус бина тәгаенләнүе һәм анда бер йөзгә якын хезмәткәр булачагы күздә тотылды. (Гәрчә элекке галимнәр күзаллаганча, академия системасына бәйлелеге белдерелмәде). Әлеге проект хыялларда бик матур күренсә дә, хәзерге вакытта төрле оешмаларда тупланган һәм саклана торган кыйммәтле язма истәлекләрне бер урынга җыю белән мавыгу – кирәксез гамәл. Бигрәк тә, электрон мөмкинлекләр заманында тузга язмаган гигантчылык омтылышларының нәтиҗәсе уңай булачагы шикле. Аерым оешмаларда саклансалар да, кулъязма истәлекләрнең

---

[109] Юзиев Н. Әдәбият чыганаклары белеме (әдәби мирасны җыйнауның, өйрәнүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре). – Казан: Фикер, 1998. – Б. 17.
[110] Миңнуллин Җ., Сәлахова Э. Иске татар язуы..., 2014. – Б. 101.

уртак һәм бердәм белешмәсен булдырырга мөмкин бит. Иң аянычы тагын шул – гарәп хәрефләрендәге язма ядкярләр белән эшләрлек белгечләр санаулы гына. Беренче нәүбәттә, төп игътибарның максатчан рәвештә белгечләр хәзерләүгә юнәлтелүе фарыз. Кадрлар җитешмәве, гомумән, элек тә иң төп мәсьәләләрнең берсе иде һәм ул хәзер дә актуаль булып кала бирә[111].

## Метрика язмалары

Мәшһүр тарихчы һәм дин галиме, әдип Ризаэтдин Фәхретдин мөселман метрика язмаларының әһәмиятен моннан бер йөз еллап элек үк тәфсилләп аңлаткан һәм аларның тарихи чыганак буларак аеруча мөһим икәнлеген белдергән. Уфадагы Диния Нәзарәте архивының метрикалар тупламын ул «хәзинә» һәм «оҗмах ачкычлары» дип, бик югары бәяләгән[112].

Мөселман татар метрика дәфтәрләре – татар язма чыганакларының иң күп сакланган һәм кыйммәтле өлеше, үз хасиятләренә ия кульязма документларның бер төре. Метрикаларның төп вазифасы – туучылар, үлүчеләр, никахлар һәм аерылулар турындагы мәгълүматларны теркәү булганлыктан, аларның лексик составлары чикләнгән даирәне тәшкил итә. Бу төр чыганакларның башка кульязмалардан төп аермалары менә шунда. Метрика дәфтәрләре мөселман руханилары (ягъни, яхшы белемле кешеләр) тарафыннан язылганга күрә, текстларында хаталары азрак, язу-почерклары да аңлаешлырак. Мөселман татар метрикаларын өйрәнүче белгечләр археограф дип тәгаенләнсәләр дә, бу сыйфатламаның киң һәм тулы мәгънәсенә туры ки-

[111] Бу турыда без дә утыз елдан артык искәртеп киләбез (Китапка хитап = Слово о книге. – Казан: Татар. китап нәшр., 1994. – Б. 64–65; Милли китапханәнең археографик экспедицияләре..., 2022. – Б. 11).
[112] Фәхреддинев Р. Болгар вә Казан төрекләре..., 1993. – Б. 252.

леп бетмиләр. Чөнки, мөселман метрика язмалары 1828 нче елдан башлап, бер гасырлык вакыт белән һәм текстлары да, әйтеп үткәнебезчә, аерым бер специфика белән чикләнә. Ә гомуми татар археографиясенә килгәндә, аның вакыт ягыннан, эчтәлек һәм башка җәһәтләрдән дә даирәсе бик-бик киң. Өстәвенә, һәр чорның-гасырның палеографик үзенчәлекләре дә гаять күп.

Сүз уңаеннан, метрикаларның документаль чыганак буларак кыйммәтләрен таныган хәлдә, алар һәр очракта да төгәл чынбарлыкны белдереп җиткермәгәнлеген онытмаска кирәк. Мәсәлән, Россиядә яшәгән татар-мөселманнарга метрика дәфтәрләре язып бару тәртибе кертелгән чорда мөфти вазифасын үтәгән Габдессәлам хәзрәтнең 1840 елның гыйнварында вафат булу вакыйгасы метрикага бөтенләй теркәлмичә калган. Шунлыктан, аның вафат елы 1839 дип тә язылып йөртелгән[113]. Мөфти дәрәҗәсендәге иң югары руханиның метрикага язылмыйча калганлыгы гади мөселманнарның мәгълүматлары тулы, төгәл һәм дөрес булуына шик тудыра. Шулай ук, метрикаларны теркәп баруга җаваплы имамнарның төрле сәбәпләрдән хәтта үз балаларын да төгәл итеп язмаганлыклары билгеле. Мәсәлән, иске календарь буенча 1858 ел ахырында (31 декабрьдә) дөньяга килгән Ризаэтдин Фәхретдин 1859 елның 4 гыйнварында туды дип теркәлгән[114]. Менә мондый фактларны исәпкә алганда, метрикалардагы мәгълүматларга артык мөкиббән китмичә, аларга да башка төр язма чыганакларга карата булырга тиешле тәнкыйди мөнәсәбәт зарур.

Татар кульъязма китапларының һәм дәфтәрләренең буш урыннарына, аерым битләргә һәм кәгазь кисәкләренә

[113] Фәхреддин Р. Асар. 1 том / төз.: Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Казан: «Рухият» нәшр., 2006. – Б. 154.

[114] Ризаэтдин Фәхретдин: фәнни-биографик җыентык / Ризаэтдин Фахретдинов: научно-биографический сборник / төз.: Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Казан: «Рухият» нәшр., 1999. – Б. 9.

теркәлгән метрика мәгълүматлары бик күп очравының сәбәбе – шактый муллаларның төрлечә рәвештә язгалап барып, метрикаларны тапшырыр алдыннан гына җыеп язуларына бәйле. Алар метрика дәфтәрләрен тутыруны еш кына үзләренең шәкерт угылларына кушып та эшләткәннәр.

## Эпиграфик истәлекләр

Эпиграфик ядкярләр – халыкның мәдәнилеген күрсәтә торган төп дәлилләрнең берсе. Идел-Урал буйларында гарәп хәрефләре белән язылган, XIII гасырдан алып XX гасыр урталарына[115] кадәрге дистә меңнәрчә мөселман-татар ташъязма истәлекләре сакланган.

Татар җирлегендәге эпиграфик истәлекләр, алыштыргысыз тарихи чыганак булулары белән бергә, лингвистика һәм сәнгать ягыннан да әһәмиятле. Аларның эшләнешләре, бизәлешләре һәм калыплары, текстларының үзенчәлеге, график яктан бирелешләре, каллиграфик башкарылулары гаять күп төрле.

Тарихи яктан караганда, Алтын Урданың бер өлеше булган Болгар олысы заманындагы, Казан һәм башка ханлыклар чорындагы ташъязмалар камиллек-нәфасәтләре җәһәтеннән аеруча үзенчәлекле. Тарихчы Рәшит Кадыйров язганча, татар эпиграфик истәлекләре XVI гасырның беренче яртысында иң югары үсешкә ирешкән. Аларның язулары һәм калыплары ягыннан камиллеге, элекке Болгар традицияләренә нигезләнүе белән бергә, замана таләпләрен дә чагылдырган – ягъни, ул чорда каллиграфик моданың төп

[115] Элекке традицияләрне саклаган татар кабер ташлары 1930–1940 нчы елларга хәтле дәвам иткән. 1950 нче еллардан алып 1960, 1970 нче елларда гарәп хәрефләре белән уелган яңачарак төр ташъязмалар шактый һәм алар да күп гасырлык татар эпиграфикасының дәвамы булып исәпләнергә лаек.

үзәге булган Госманлы дәүләте үрнәгенә ияргән[116]. Шул чор татар кабер ташларындагы каллиграфик сөлес һәм нәсех язулары кайбер хезмәтләрдә «госманлыча» дип аталган[117] булуы да Кадыйров фикерен куәтли.

XVII гасырдагы татар эпиграфик истәлекләре аерым хосусиятләргә ия берничә төркемне тәшкил итә. XVIII гасыр – татар-мөселман тарихында авыр чор булганлыктан, шактый төбәкләрдә ташъязма истәлекләр санаулы гына. Ә шул ук гасырда иҗтимагый-сәяси яшәеш мөмкинлекләре чагыштырмача иркенрәк булган Оренбург тарафларында татар кабер ташлары шактый куелган һәм хәзерге вакыткача сакланып калган. XIX гасырда һәм XX гасырның беренче чирегендә ташъязма истәлекләр халкыбыз яшәгән бөтен төбәкләрдә дә бик күп куелган.

Алтын Урда чорыннан (XIII гасырдан) башлап XX гасырга кадәрге мөселман татар кабер ташлары XIX гасыр галимнәре Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, Н.Ф.Катанов, Н.И.Ашмариннардан алып, XX гасыр башында һәм совет чорында Ризаэтдин Фәхретдин, Гали Рәхим, Н.И.Воробьёв, Н.Ф.Калинин, Һарун Йосыпов, Әхмәт Булатов, Марсель Әхмәтҗанов, Фәрит Хәкимҗанов, Җәмил Мөхәммәтшин, 1990 нчы еллардан хәзергәчә шул ук М.Әхмәтҗанов, Ирек Һадиев, Раиф Мәрданов, Нурулла Гариф, Венер Усманов, Айдар Гайнетдинов һ.б. белгечләр тарафыннан шактый өйрәнелгән. Аларның күпсанлы хезмәтләрендә татар эпиграфик ядкярләренең текстологик һәм палеографик хасиятләре турында төрле микъдарда мәгълүматлар язылган. Тарихчы Рәшит Кадыйров XIII–XVIII гасырлардагы татар язма истәлекләренең палеографик үзенчәлекләрен

[116] Кадыров Р. Источники по истории старотатарской письменности..., 1999. – С. 165.
[117] Җәбәли Минһаҗетдин. Тәварихы Болгарийә вә татарийә..., 2023. – Б. 75.

фәнни нигездә өйрәнгән хезмәтендә эпиграфик истәлекләрне дә тикшергән.

Татар-мөселман кабер ташларының текстларында палеографик үзенчәлекләр аз түгел. Аларның бер өлеше кульязмаларныкы белән уртак, тик эпиграфикага гына хас булганнары да бар. Гарәп язулы кабер ташларының палеографик үзенчәлекләренә бу китапта аерым тукталмыйбыз дип кереш мәкаләдә искәрткән идек.

# II БҮЛЕК: ЯЗЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ[1]

## Гарәп язуының төп төрләре

Гарәп язуындагы каллиграфик төрләрнең татар палеографиясенә йогынтысы, һичшиксез, зур булган. Иске татар кулъязмаларын уку-төшенү өчен каллиграфик үзенчәлекләрне белү зарур. Шунлыктан, гарәп каллиграфиясенең төп классик алты төрен искә алып үтәргә тиешбез. Алар: куфи, нәсех, сөлес, дивани, нәстәгъликъ, рокъга исемнәре белән билгеле. Әлеге язу төрләренең үз эчләрендәге тармаклары да бар, алары ихтыяҗга күрә генә телгә алыначак. Тотрыклы язылыш кагыйдәләре күп гасырлар элек үк эшләнгән каллиграфик алты төрнең һәрберсе үзенчәлекле нәфислеккә ия. Бер язу төренә хас булган үзенчәлекне башкалары белән бутау – кагыйдә-тәртипләрне бозуга китерә һәм аларны теләсә ничек аралаштыру, гомумән, дөрес түгел.

Болардан иң борынгыларының берсе – VII–VIII гасырларда таралыш алган «куфи» төрендә гарәп хәрефләре геометрик фигураларга (почмаклы, түгәрәк, сынык һ.б.) охшаш итеп һәм ноктаtotal ларсыз язылышы белән үзенчәлекле булган. Ул гарәпләрдә ислам диненә хәтле үк барлыкка килгән, XII гасырга хәтле төп язу төре булган һәм Коръән текстларын күчергәндә киң кулланылган. Куфи һәм нәсех

---

[1] II һәм III бүлекләрдәге сылтамалар, еш кабатланулары сәбәпле, китап ахырында урнаштырылган гомуми исемлектәге чыганакка ясалды. Әлеге ике бүлек текстларында «Файдаланылган китаплар һәм мәкаләләр» исемлегендә теркәлгән хезмәтнең тәртип саны белән бит саннары квадрат җәяләр эчендә күрсәтелде. Җәяләр эчендәге беренче сан – хезмәтнең тәртип саны, аннары өтердән соң бирелгән саннар – шул хезмәтнең битләрен белдерә.

төрләре иң борынгылардан буларак, башка каллиграфик язу төрләренең нигезен тәшкил иткәннәр. Куфи төре Идел-Урал буйларында XIII–XIV гасырлардагы, хәзергәчә сакланган кабер ташларында киң кулланылган[2]. Ул татар кулъязмаларында очрамый диярлек. Бары тик кайбер дини һәм әдәби әсәрләрнең бүлек башларын белдергән сүзләр (баб, фасыл, китап) «куфи»га охшаш итеп язылганлыгын күрергә мөмкин. XIX гасырда Мисырда белем алган татар шәкертенең гарәп телендәге әсәрләрне «куфи»ның бер тармагы булган «мәгърибм» төрендә күчергән һәм үзе белән алып кайткан текстларын күргәнебез булды. («Мәгъриби» – Төньяк Африкада IX гасырда кулланылышка кергән).

Татар җирлегендә куфи язуы, әйткәнебезчә, зур текстлар өчен кулланылмаган. Матбагачылыкта кайбер китап исемнәренең бирелешендә XIX гасырда һәм XX гасырның беренче чирегендә исә ешрак кулланылган. Типографияләр эшенең камилләшүе белән бергә, татар басмаларында төрле шрифтлар куллануга бәйле рәвештә, куфи язуына охшаш хәрефләрне киңрәк файдалану омтылышлары булган, ләкин зур уңышка ирешмәгән. XX гасыр башындагы татар матбугатында кайбер очракларда куфича хәрефләр, бигрәк тә журнал атамаларында (мәсәлән, «Шура» һәм «Әд-дин вәл-әдәб») кулланылган. 1920 нче елларда исә, «Безнең юл» журналының тышлыгындагы исеме дә куфи хәрефләре белән басылган.

***

Нәсех – куфи белән бер чорда барлыкка килгән[3]. Нәсех язулы истәлекләр VII гасырда ук теркәлгән. Бу төр уку өчен

[2] Рәшит Кадыйров Болгар кабер ташларының өчтән ике өлеше куфи төрендә язылган һәм аларның иң әүвәлгесе 1281 елга карый дип язды. Ул шулай ук С.М.Шпилевский хезмәтендә телгә алынган 1173 елгы ташъязманың да куфи белән язылган булуын искәрткән [36, 44].

[3] Кайбер хезмәтләрдә (мәсәлән, [56, 52–53]) сөлес язуының I–II һәм нәсехнең

иң аңлаешлысы һәм язу өчен дә кулайрагы. Шул сәбәптән, нәсех – иң күп кулланылган һәм XI–XIII гасырларда зур популярлыкка ирешеп, дөньяда иң күп таралыш алган язу төре. Мөселманнарның изге Коръән китабы күп гасырлар буена нәкъ менә нәсех төрендә күчереп язылган һәм типографик басмаларының да күпчелеге шул ук нәсех белән нәшер ителгән һәм хәзер дә ителә. Безнең татар җирлегендә нәсех язуы XIII–XIV гасырлардагы кабер ташларында ук кулланылган, Коръән китаплары да нәсех язуында күчерелгән. Башка төр дини, фәнни һәм әдәби әсәрләр дә еш кына шул язу белән теркәлгән. Матбагаларда татар китапларын нәшер итү башланганнан алып, 1920 нче еллар ахырына кадәрге бөтен басмалар да, шулай ук газеталар һәм журналлар нәсех язуы нигезендә дөнья күргәннәр. Гомумән, нәсех – татарларда иң күп кулланылган язуларның берсе.

Безнең җирлектәге кульязма истәлекләрдә нәсехкә башка язу төрләренең элементлары (бигрәк тә, нәстәгъликъныкы) кушылган.

Идел буе Болгар дәүләте һәм татар ханлыклары чорыннан ук кулланылган гарәп язуының нәсех төре укымышлылар арасында өзлексез дәвам итеп килгәнлеге аңлашыла. XVII–XIX гасырларда татар шәкертләренең Дагыстанга (гомумән, Кавказга) барып белем алулары нәсех язуы төренең безнең җирлектә тагын да киңрәк таралышына тәэсир иткән дип фаразларга мөмкин. XVII гасырга караган татар кульязмаларының (ихтимал, күбрәк өлешенең) нәсех төрендә теркәлгән булуы – Дагыстан мәдрәсәләренең йогынтысына бәйле булгандыр. Галимнәр билгеләвенчә, Дагыстанның көньяк төбәкләрендә нәсехнең нәстәгъликъ элементлары катышкан варианты өстенлек иткән һәм,

---

III гасырда барлыкка килүе турында әйтелгән сүзләр дөреслеккә туры килмәвен искәртергә тиешбез. Күрсәтелгән ялгыш мәгълүмат, ихтимал, һиҗри гасырларны күздә тотып язылган башка чыганактан алынгандыр.


تلف اولنمقلرندن نى بونلر خصوصلرنده بزلره هر
نچوك بر تواريخ وتحفه يازوب قالدرودوقلرى بو آنه
ديك هيچ فايده وهيچ بر يرده مسموع ومشاهده
اولنمادوقلرندن اوتورو بعض اهل اسلام تواريخ
كزيده لرندن اخذ واجمالا ابعد آيدوب واخرنده كه
قزان
شهر خصوصنده اعتبار اوروس تواريخلرينه
ضرورى مراجعت وانلردن امكانم قدر ترجمه
وبونه ترتيبلريچه بر برجمع ايلمكمله بوكتابى تحفة
الجديد فى تواريخ قديمى قزان ديو تسميه ايلمشم
التماس ايدرم كه طپولرنكزده بوكيچكچه خدمتم
حسن ظن ايدلوب سهولرى عفو اولنه ايردى
فى سنه هجرى ١٢٤٣ وفى سنه ميلاد ١٨٢٧ ابو
كتابه شروع اولندى وبالله توفيق

*Ибраһим Хәлфиннең 1827 елгы кулъязмасы*
*(Казан федераль университеты Фәнни китапханәсе)*

безнең күзәтүләргә күрә, андый үзенчәлек татар кулъязмаларына да хас. Үзе шунда белем алып кайткан татар шәкерте, ватанындагы мәдрәсәдә укытырлык мөдәррис-остаз булып җитешкәч шәкертләрен дә үзе кулланган язу төренә өйрәткән, мәдрәсәдә файдаланыла торган китапларның да бер өлешен нәсех язуында күчерү традициясе урнашкан булса кирәк. Аерым татар мәдрәсәләрендә, гомумән, остаздан шәкерткә күчү гадәте белән өйрәнелгән язу өслүбе буыннан-буынга дәвам итеп килгәнлеге табигый күренеш.

XIX гасыр ахырында татар җәдит мәктәпләрендә матур язуны өйрәтүгә зур әһәмият бирелгән һәм аның өчен нәсех төре кулланылган. Шунлыктан, XIX гасыр ахырыннан алып

1920 нче елларга кадәрге сабак һәм шәкерт дәфтәрләре, белем алуга бәйле текстлар, нигездә, нәсех төрендә язылган. Мәктәптә уку чорыннан ук язуның әлеге төренә күнеккән кешеләр гомерләре буена шулай язганнар. Дөрес, татар кулъязмаларында нәсех язуының бөтен кагыйдәләре дә төгәл үтәлеп җитмәгән.

Татар галимнәрен һәм әдипләрен искә алсак, Ибраһим Хәлфиннең, Хөсәен Фәезхановның тарихи хезмәтләре, Ризаэтдин Фәхретдин, Габдулла Бубый, Габдулла Тукай, Фатих Әмирханның кул язулары нәсех төрендә булганын әйтергә мөмкин.

Нәсех язуы турында сүз барганда дөнья тарихында татар кешесенең исеме белән бәйле бер вакыйганы да искә төшерергә кирәк. Полиграфия эшендә гарәп-төрки шрифтларын унификацияләүне XX гасыр башында Мөхәммәт Идрисов (1882–1948) башкарган. Нәтиҗәдә, китаплар бастырганда текстны җыю җиңелрәк һәм тизрәк эшләнә, шул сәбәпле басмаларның үзкыйммәте дә арзаная.

Бөтен гомерен милли китапчылыкка һәм полиграфия өлкәсенә багышлаган сирәк осталарның берсе – Мөхәммәт Идрисов 1917 елдан соң Мәскәүдәге типографияләрдә рәссам-шрифтчы һәм гравёр булып эшләгән, педагогик хезмәт белән шөгыльләнгән. Шрифтларны үзгәртеп, басма өчен җайлаштыруда аның ачышлары үз чорында югары технологик казанышлар белән тиң булган. М.Идрисов типографияләр өчен шрифтлар хәзерләүдән тыш, матбагалар өчен төрле бизәкләр дә ясаган. Аның бизәкләре үз вакытында Казандагы бөтен басмаханәләрдә кулланылган. Алар соңрак Татполиграфка алынып, 1930 нчы елларга хәтле күпләп һәм 1940 нчы елларга кадәр өлешчә кулланылганнар. Идрисов әзерләгән рәсемнәр буенча коелган гарәп-төрки шрифтлары Урта Азия, Казакъстан һәм Кавказ типографияләренә дә җибәрелгән. СССРдагы гарәп-төрки хәрефләре белән уңнан-сулга таба бастыра торган беренче язу машинкалары



*Хөсәен Фәезханов кульязмасы. 1860–1863 нче еллар (Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

да М.Идрисов ачышлары нигезендә барлыкка килгән. Илдә гарәп хәрефләре белән язу машинкалары эшләп чыгарыла башлагач, гарәп язуын кулланган егермедән артык халык шулардан файдаланган.

Идрисов шрифтлары һәм полиграфиядәге яңалыклары XX гасырның икенче яртысында Советлар Союзыннан алдырылып, Шәрык илләренең күбесендә кулланылган. Һиндстан, Әфганстан, Мисыр һәм Сүрия шундый илләрнең эреләреннән булган. Гарәп язуын куллана торган илләр өчен СССРда эшләнгән линотип машиналарына «Нәсхи

Мөхәммәт Идриси» дигән сыйфатлама язуы беркетелгән. Ягъни, гарәп язуының полиграфия өчен унификацияләнгән төренә аның исеме бирелгән [37, 274–275; 65, 41–44, 87–89, 93].

***

Гарәп каллиграфиясенең X гасырда барлыкка килгән «сөлес» язуы төре аеруча бормалы һәм чолгаулы, хәрефләрнең һәм сүзләрнең үзара үрелеш белән башкарылу хасиятенә ия. Уку өчен ул нәсехтән читенрәк. «Сөлес» дигән сүз гарәп телендә «өчтән бер» дигәнне белдерә, ягъни бу язу төрендә һәр хәрефнең өчтән бер өлеше бөгелгән, ә өчтән ике өлешенең туры булуы күздә тотылган. Үзе үк зиннәтле бизәк рәвешендәге әлеге язу төре Коръән китабында сүрә исемнәрен язганда, мәчетләрнең һәм бүтән биналарның монументаль бизәлешләрендә, шәмаилләрдә һ.б. кулланылган һәм хәзер дә кулланыла. Күләмле текстлар өчен китапларда, шулай ук гадәти һәм көндәлек язмаларда сөлес язуын файдаланмаганнар.

Безнең җирлектә сөлес язуын XIII гасыр кабер ташларында күрергә мөмкин[4]. Бу язу төре татар эпиграфикасында XX гасыр башына кадәр кулланылган. Китапчылык тарихында, алда әйтелгәнчә, Коръән сүрәләрен язганда, шулай ук башка гыйбарәләрдә, басма китапларда исә әсәрнең исемендә, XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында газета һәм журналларның исемнәрендә (мәсәлән, Җаек шәһәрендә 1906–1907 елларда нәшер ителгән «Әлгасрел-җәдид» журналы, Казанда 1907–1909 елларда чыккан «Әл-Ислах» газетасы атамаларында) кулланылган.

[4] Тарихчы Гайнетдин Әхмәрев Ямбакты авылындагы һижри 641 (милади 1244) елгы кабер ташын сөлес белән язылган дип искәрткән [19, 73]. Ул таш хәзергәчә сакланмаган.

***

Гарәп язуының «дивани» дип аталган, тиз язу төре, исеменнән үк күренгәнчә, нигездә, дәүләт-хөкүмәтнең рәсми кәгазь эшләрендә файдаланылган. Аны шулай ук эпиграфик истәлекләрдә, мәчет-мәдрәсәләрне һ.б. биналарны бизәгәндә кулланганнар. Аеруча зиннәтле һәм тантаналы, бизәкле һәм ифрат дәрәҗәдә чорналышлы дивани язуы уку өчен читен. Бу язу төре үз эчендә ике төрлегә бүленә: «рикъга дивани» (бизәкләрсез) һәм «җәлий дивани» (бизәкле, зиннәтле). Дивани төрендә хәрефләр сул якка авыш итеп язылган һәм аларның ялганышлары гадәти түгел, шулай ук бизәкле элементлар күп кулланылган.

Дивани язуы X–XI гасырларда иҗат ителгән, соңрак төрекләр тарафыннан камилләштерелгән. Татар җирлегендә бу төргә караган язмалар XIII–XIV гасырлардагы эпиграфик истәлекләрдә бар.

Алтын Урда чорында – җучилар дәүләтенең канцеляриясе оешкан вакытыннан башлап анда гарәп язуы кулланылган. Ул заманнан сакланып калган рәсми язма документларның күпчелеге (өчтән ике өлеше) дивани, беразы (өчтән бер өлеше) – сөлес язуында башкарылган [82, 115–124; 1, 130].

Казан ханлыгы чорыннан калган бердәнбер язма документ – Сахибгәрәй хан исеменнән 1523 елда бирелгән тарханлык ярлыгы классик «дивани»дан бик ерак булса да, шул төргә нисбәтле дип яза Р.Кадыйров. Ул – нәстәгъликъ элементлары кушылган гадиләштерелгән дивани белән теркәлгән, ди [36, 101, 104].

Татар кульязмаларында диванины бик сирәк кенә, аерым гыйбарәләрнең язылышында очратырга мөмкин. Әсәр текстлары, гомумән, дивани белән теркәлмәгән. Матбагалар эшчәнлегендә китап-әсәр исемнәренең бирелешләрендә, газета-журналларның атамаларында һәм бүлек-рубрика исемнәрендә бераз кулланылган.

***

Персиядә XIV гасыр ахырында иҗат ителгән һәм фарсы каллиграфиясендә үзәк урынны биләгән нәстәгъликъ тиз язу өчен кулай төрләрнең берсе. Электән билгеле булган нәсех һәм XII гасырда фарсылар тарафыннан гамәлгә куелган тәгъликъ язулары нигезендә нәфис һәм күркәм нәстәгъликъ төре барлыкка килгән. Ул, гомумән, XIV гасыр ахырыннан Персия, Азәрбәйҗан, Урта Азия хаттатларында төп язу ысулы буларак өстенлеккә ирешкән. Нәстәгъликъ XV гасырда зур таралыш алган, Госманлы империясендә һәм башка мөселман илләрендә дә киң файдаланылган. Гарәпләр, төрекләр һәм татарлар нәстәгъликъны «фарсы язуы» дип тә йөрткәннәр. Чөнки электән үк Иран-фарсы мәдәнияте йогынтысын кичергән ил-дәүләтләрдә нәстәгъликъ – төп язу төре булган һәм хәзер дә шулай булып кала бирә.

Шикәстә – нәстәгъликъның тагын да тизрәк язылышлы төре буларак XVII гасырда барлыкка килгән. Ләкин ул уку өчен кыен. Серле язылышлары шактый булганлыктан, суфичылык тарафдарлары шикәстә язуын аеруча үз иткәннәр.

XVII гасыр ахырыннан татар язма чыганакларын гомуми рәвештә «бераз сөлес элементлары кушылган нәстәгъликъ» дип тәгаенли Р.Кадыйров. Мәсәлән, «ра» хәрефенең сөлестәге кебек «ра-и мокаувәс» (бөгелгән «ра») белән язылышы. XVII гасыр татар кабер ташларында электән килгән тартмалап (ярусле) язу да кулланылган, ди галим [36, 97].

«Тартмалап» язу[5] тексттагы сүзләрне һәм аларның өлешләрен берсе өстенә икенчесен, тартмаларны авышлап өйгән кебек тыгызлап язуны белдерә. Бу исә аз мәйданга күбрәк текст сыйдыруы белән үзенчәлекле. Сүзләрнең язылышы ярымвертикаль авыш итеп урнаштырылган, мәсәлән: 

[5] Каллиграфиягә хас «тартмалап язу» дигән гыйбарәне университеттагы гарәп теле укытучыбыз Җәмил Зәйнуллин әйткән иде. Ул исә аны танылган хаттат, рәссам һәм скульптор Бакый ага Урманчедан һ.б. өлкән буын шәхесләреннән ишеткән.

Мондый язу алымы гарәп каллиграфиясенең нәстәгъликъ һәм шикәстә төрләренә аеруча хас. Гомумән, бер төрле үк текст нәсех ысулы белән теркәлгәнгә караганда, нәстәгъликъ белән язганда кимрәк мәйдан биләгән. Ә шул ук текст шикәстә төрендә язылганда аннан да азрак урын алган. Мәсәлән,

| | |
|---|---|
| нәсех |  |
| нәстәгъликъ |  |
| шикәстә |  |

Безнең җирлектә нәстәгъликъ язуы төре татар ханлыклары дәвереннән алып XX гасыр башына хәтле кулланылган һәм ул татар кульъязмачылыгында иң күп файдаланылган язу төрләренең икенчесе. (Андыйларның берсе «нәсех» дип әйтеп үткән идек). Тарихчылар язуынча, Болгар дәүләте белән Урта Азиянең икътисади һәм мәдәни бәйләнешләре электән тыгыз булган. XV–XVI гасырларда элемтәләр зәгыйфьләнсә дә, XVII һәм бигрәк тә XVIII гасыр белән XIX гасыр башында аралашу көчәйгән. Татар шәкертләре XVII гасырның икенче яртысыннан Урта Азиядә: Бохара, Сәмәрканд һ.б. калалардагы, Әфганстандагы мәшһүр мәдрәсәләрдә укый башлагач, Идел-Урал төбәгендә тәгъликъ һәм аның төрдәше нәстәгъликъ язуларын куллану аеруча киң таралыш алган. Остаздан-шәкерткә күчә-күчә, бу язу төрләре XIX гасырның беренче яртысында, гомумән, Россиядә яшәгән татарлар иң үз иткән төп язу рәвешләрен алганнар диярлек. Р.Кадыйров язуынча, XV–XIX гасырларда Урта Азиядәге бөтен кульъязмалар нәстәгъликъ төрендә башкарылганлыгы сәбәпле, аның тәэсире Идел-Урал буе татарларына көчле булган. XVII гасырда нәстәгъликъка шикәстә элементлары керә башлаганнан соң нәстәгъликъ-шикәстә ысулы барлыкка килгән.

Рәшит Кадыйров билгеләвенчә, XVII–XVIII гасырлардагы татар кульязмаларының төп почерклары – нәстәгъликъка шикәстә элементлары кушылган төр (нәстәгъликъ-шикәстә) һәм нәсех (бераз нәстәгъликъ элементлары белән). Шулай ук ул: «Шактый кульязмаларның язу төрен тәгаенләп булмый» дип белдергән иде. Пугачёв күтәрелеше чорындагы документлар да нәстәгъликъ-шикәстә төрендә язылган дип карала. Ул чор язуларындагы хәрефләр уң якка авыш итеп теркәлгән. XIX гасырның икенче яртысында әлеге язу рәвеше күп кулланылса да, инде кими башлаган.

Кайбер хәрефләрнең язылышларында һәм ялганышларында классик нәстәгъликъ язуының эчке кагыйдәләренә туры килеп бетмәгән, әүвәлгерәк тәгъликъ элементлары кулланылуына карап, фәндә «татар тәгъликы» дигән атама да урын алган. Мәсәлән, Альберт Фәтхи тасвирламаларының беренче һәм икенче бүлекләрендә (1960, 1962) «тәгъликъ» дип тәгаенләнгән язу төрләре күпчелекне тәшкил итә, өченче кисәктә (1986) исә «тәгъликъ» дип аталганы юк, «нәстәгъликъ» дигәне – бер, ә «татар тәгъликы» дип билгеләнгәннәре бик күп (дистәләрчә) икәнлеген күрәбез.

«Кыйссаи Йосыф» тасвирламаларына багышланган мәкаләдә шул әсәр күчермәләренең нәстәгъликъ, тәгъликъ һәм нәсех төрләре белән билгеләнгәннәре белән бергә, «татар нәстәгъликы», «нәстәгъликъ рәвешендәге татар почеркы», «татар нәсехе» [39, 432–484] дигән сыйфатламалар да күрергә мөмкин. Арада ике күчермә «куфи һәм тәгъликъка якын», «куфи һәм нәсех кушылмасы» дип билгеләнгән булуы да кызыклы [39, 466, 478].

Күренекле татар галимнәреннән үзләре хаттат-каллиграф булган Мөхәммәдгали Мәхмүдов һәм Хөсәен Фәезханов кульязмаларының кайберләре нәстәгъликъ төрендә башкарылган. Габдеррәхим Утыз Имәни, Шиһабетдин Мәрҗани дә нәстәгъликъ белән язганнар.

Гарәп язуының каллиграфик нәстәгъликъ төре безнең




*Габдерәхим Утыз Имәнинең 1804 елгы кулъязмасы*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

татар җирлегендә XIX һәм XX гасырлардагы фәнни хезмәтләрдә «тәгъликъ» дип йөртелгән булуын истә тотарга кирәк. Тарихчы Рәшит Кадыйров бу мәсьәләгә махсус тукталып, татарлардагы ялгыш аталуның хикмәте төрекләр йогынтысы белән булганлыгын ачыклап язган [36, 114]. Чөнки элекке заманда ук нәстәгъликъ язуы төрекләрдә «тәгъликъ» исеме белән аталган. XIX гасырда Казан университетында студентларга гарәп каллиграфиясен укыткан Мөхәммәтгали Мәхмүдов та «тәгъликъ» язуы төрен (дөресе – нәстәгъликъны) өйрәткән дип күрсәтелгән. Төркиядә каллиграфия (хөсне хат) үрнәкләре җыентыкларында да «нәстәгъликъ» язуы шулай ук «тәгъликъ» дип бирелгән. XX гасыр башында татар җәдит мәктәпләрендә матур язуны өйрәтү өчен төрле автор-хаттатлар хәзерләгән махсус ярдәмлекләрдә дә, төрек басмаларына ияреп, нәстәгъликъ язуы төре «тәгъликъ» дип тәгаенләнгән. Казан галимнәре Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Сәед Вахиди, П.М.Дульский, урнашкан гадәтне дәвам итеп, 1920 нче елларда нәстәгъликъны тәгъликъ дип язганнар. Әлеге язу төренең ялгыш аталуына карата Р.Кадыйров «Хаттатлар өчен профессиональ жаргон сыйфатында кулланылган булса да, фәнни-тикшеренү хезмәтләре өчен төгәл билгеләмә бирелүе шарт. Чөнки тәгъликъ белән нәстәгъликъ – язылышлары һәм кулланылу даирәләре буенча төрле почерклар. XVII–XVIII (хәтта XX) гасырлардагы кулъязмаларда күп кулланылган язу төрен «тәгъликъ» дип атау дөрес түгел, ул шулай ук фәннилек һәм объективлык таләпләренә дә туры килми», – дип язган [36, 114–115 (татарчага тәрҗемә безнеке – Р.М.)].

Гасырлар дәвамында урнашкан мондый күренешне бөтенләй үк зур ялгыш дип булмыйдыр, күрәсең. Тарихта аңа охшаш – кайбер терминнарның төгәл мәгънәсендә кулланылмавына яисә башкага алыштырылуына – мисаллар бар бит. Мәсәлән, чынбарлыкта һиндлылар тарафыннан уйлап табылган саннар бөтен дөньяга «гарәп

саннары» буларак танылган. Америка кыйтгаларында яшәүче төп халыкларның «һиндлылар» дигән атамага ия булу очрагын искә алу да урынлы булыр. Югыйсә, алар «һиндлылар» түгел дип хәзер дәгъва белдерү урынсыз. Мондый тарихи «ялгышлар» исәбенә нәстәгъликъның төрекләрдә һәм татарларда (шулай ук гарәп язуына тарихи мөнәсәбәте булган башка халыкларда) тәгъликъ дип аталганлыгын фәнни хезмәтләрдә искәртеп-аңлатып китү кулайрак булыр кебек.

XX гасырда һәм хәзерге чорда да гарәп каллиграфиясенә багышланган Төркия басмаларында чынлыкта нәстәгъликъ төрендәге язуларның «тәгъликъ» дип тәгаенләнгән булуын күрәбез. Мәсәлән, гарәп матур язу сәнгатенә багышланган бик мәртәбәле төрек альбомында фарсы телендәге бер үк эчтәлектәге текст өзегенең төрле хаттатлар тарафыннан бер төрле үк рәвештә – нәстәгъликъ ысулында (!) язылган өч данә күчермәсенең берсе «нәстәгъликъ» дип күрсәтелгән, ә икесе «тәгъликъ» дип белдерелгән [34, 206–207]. Димәк, каллиграфия сәнгатенең искиткеч бай тарихына ия булган төрек белгечләрен хәзер дә чын фәннилек һәм объективлык эзенә төшеп бетмәгәннәр дип дәгъва белдерү урынсыз булыр. Бары тик төрекләрдә гасырлар дәвамында «тәгъликъ» һәм «нәстәгъликъ» атамаларының бер үк мәгънәгә ия синоним рәвешендә куллану гадәте барлыгын һәм шул ук күренешнең татарларда да күптән урнашканын таныырга мәҗбүрбез.

Шушы фонда исә, асылдагы «нәстәгъликъ» дигән исеменнән татар җирлегендә аермалырак «тәгъликъ» дип үзләшкән һәм шулай дәвам итеп килгән ялгышлыкны таныган хәлдә, аны әүвәлге галимнәр һәм белгечләр дөрес язмаган дип белдерүнең дә инде кирәге-ихтыяҗы юк. Ә менә әлеге четерекле мәсьәләдә Р.Кадыйров тәгъликъ һәм нәстәгъликъны аерым язу төрләре дип белдерүе белән бергә, аларның төп аермалары нәрсәдә икәнлеген һичьюгы кыска-

ча гына аңлатып язса, хәзерге һәм киләчәк буыннар өчен файдасы бик тигән булыр иде.

Нәстәгъликъ һәм тәгъликъ язуларының аермалы булганына Рәшит Кадыйров үзе дә әлеге мәсьәләне тирәнтен өйрәнгәндә – диссертация хезмәтен язган вакытында төшенгәнлеген күрәбез. Чөнки Җ.Зәйнуллинның берничә китабындагы гарәп язуы төрләренең үрнәкләре арасында нәкъ менә Р.Кадыйров кулы белән язылган нәстәгъликъ хәрефләре бирелгән һәм алар «Тәгълыйкъ (фарсы) язуы үрнәге» дип исемләнгән [24, 29; 33, 55]. Гәрчә әлеге китаплар чыкканчы инде Р.Кадыйровның каллиграфик тәҗрибәсе шактый – ул язган текстлар матбугатта дистә елдан артык басылып килгән иде.

Сүз уңаеннан шуны да искәртик, XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башындагы төрек, татар авторлары тарафыннан хәзерләп бастырылган каллиграфия китапларында «нәстәгъликъ» язуының «тәгъликъ» дип аталган булуына ияреп, нәстәгъликъ төрендә булган язу үрнәкләрен без фәкыйрегез дә археографиягә һәм палеографиягә багышланган хезмәтләребездә «тәгъликъ» дип белдереп килдек.

Нәстәгъликъ төренең берникадәр нигезен тәшкил иткән тәгъликъ язуы тизрәк язылышлы һәм анда хәрефләр мөмкин кадәр ураулырак итеп бер-берсенә үрелгән. Тәгъликъның шикәстә язуы белән уртаклыклары һәм охшашлыклары күбрәк. Үзләреннән соң килгән хәрефләргә ялганмый торган «өзек» хәрефләр дә тәгъликъ язуында, гадәттә, тоташтырылган. Шулай ук «әлиф» һәм «ләм»дә бер-берсенә ялгану очраклары күренә. Сүз ахырларындагы «ләм», «нун», «йа» хәрефләре шактый сузынкы итеп языла һәм, гомумән, тәгъликъ башка үзенчәлекләргә дә ия. XVIII–XIX гасырлардагы татар кульязмаларында (бигрәк тә, хатларда, татарча документларда һәм көндәлек язмаларда) тәгъликъ язуы һәм аның үзенчәлекләре катышкан нәстәгъликъ төре шактый кулланылган. Димәк, башка галимнәрнең хезмәтләрендә та-

тар кулъязмаларының бер өлешен тәгъликъ төренә нисбәт итүдә хаклык бар.

***

«Рокъга» дип аталган язу төре диваниның гадиләштерелгән (көндәлек язылыш) варианты буларак, XVIII гасырда барлыкка килгән[6]. Әлеге төр тиз язу өчен җайланган рәвештә. Ул госманлы төрекләрендә аеруча киң кулланылган. Россиядәге татарларга да рокъга язуы төрекләрдән кергән. XIX гасырда Төркиягә белем алырга барган татар яшьләре рокъга язуын үзләштереп, ватанга кайткач та шуны кулланганнар. Төркиядә укыган татарлар тәэсирендә башкалар да аны өйрәнгәннәр. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар мәдрәсәләрендә (мәсәлән, Иж-Бубыйда) рокъга язуы киң кулланылган. XIX гасырның икенче яртысындагы һәм XX гасыр башындагы татар кулъязмалары арасында рокъга төре белән теркәлгәннәре дә очрый. Мәдрәсә шәкертләренең дәрес конспектлары да шуңа дәлил булып тора. XX гасыр башындагы татар басмаханәләрендә чыккан китапларның һәм газета-журналларның исемнәре, татар вакытлы матбугатындагы кайбер рубрика атамалары рокъга язуында бирелгән. Россиядә совет хакимлеге урнашкач, татар теленең кулланылыш даирәсе киңәйгәннән соң, рокъга язуы рәсми документлар һәм канцелярия-кәгазь эшләрендә төп язу төре буларак файдаланылган. 1920 нче елларда татар әдипләренең әсәрләре, галимнәрнең хезмәтләре, шулай ук бихисап архив документлары рокъга язуында теркәлгән.

---

[6] Гарәп язуының «рокъга» атамасына якын «рикъга» дигән төре дә бар. Анысы бүтәнчә рәвешле, ләкин исемнәренең охшашлыгы еш кына буталуларга сәбәп булып тора. Рикъга – нәсех һәм сөлес язулары нигезендә тиз язылышлы буларак XVIII гасырда барлыкка килгән, госманлы дәүләтенең дипломатиясендә, кайчакларда кулъязма китапларның колофоннарында кулланылган.

Совет чорында иҗат иткән татар әдипләреннән Һади Такташ, Кәрим Тинчурин, Гадел Кутуй һәм башка күпләрнең кульязмалары рокъга төрендә.

Шул рәвешчә, гарәп язуының кыскача тасвирлап үтелгән төп алты төренең татар кульязмаларында гасырлар дәвамында иң күп гамәлдә булганнары – нәсех һәм нәстәгъликъ. Татар кульязмаларындагы язу төрен билгеләү өчен шартлы күрсәткечләрнең берсе итеп «әлиф» хәрефенең кайсы якка авышлыгын әйтергә мөмкин. Әгәр тексттагы «әлиф»ләр сул тарафка авышрак икән – гадәттә, ул нәсех төрендә, ә уң якка авышрак булсалар – язуның нәстәгъликъ төрендә булу ихтималы зур.

XVII–XVIII гасырлардагы татар кульязмаларында, берни-чә каллиграфик төр үзенчәлекләре кушылуы белән бергә, күчерүчеләрнең үз фантазияләре тудырган язылышлар да очрый [36, 112, 136]. Татар язмачылыгында XVI гасыр уртасында килеп чыккан каллиграфик торгынлык XIX гасыр уртасыннан гына үзгәрә башлый. Милли үзаң белән бергә, рухи мәдәният тә камиллеккә омтыла һәм татарларда каллиграфия җанлану – яңарыш чоры кичерә.

Югарыда тасвирланганнардан күренгәнчә, гарәп каллиграфиясенең язу төрләре татар язма истәлекләрендә киң кулланылган. Әйтелгәннәрдән тыш, төп каллиграфик төрләрнең башка тармаклары да татар язмачылыгында урын алган. Мәсәлән, сөлес язуының XI гасырда иҗат ителгән бер варианты булган нәфис «мөхаккак» төрендәге ядкярләр XIV һәм XV гасыр татар кабер ташларында сакланган [89, 16]. Мөхаккак язуы, гомумән, мөселман дөньясында XVI гасырдан соң бик сирәк кулланылган.

Татар кульязмаларын өйрәнүчеләргә гарәп каллиграфиясенең төп үзенчәлекләрен күзаллау зарур. Чөнки, әйтеп үткәнебезчә, иске текстлардагы, беренче карашка, табышмак кебегрәк тоелган язылышларның күпчелеге каллиграфик төрләрнең стиль хасиятләрен чагылдырган. Димәк,

кулъязма (гомумән, язма) чыганаклар белән эш итү махсус хәзерлек һәм тәҗрибә таләп итә. Әлбәттә, татар телен камил дәрәҗәдә белү, шулай ук төрки телләрдән, гарәп һәм фарсы телләреннән берникадәр дәрәҗәдә мәгълүматка ия булу да тиешле. Шуңа күрә, хәзерге чорда чит илләрдә укып кайткан, зур белемгә ия дин әһелләребезнең кайберләре иске кулъязма текстларны таный алмавы – сәер хәл һәм кимчелек түгел. Гарәп теле белгечләренең татарча иске басма текстларны укыганда кыенлыклар кичерүе шулай ук табигый. Гарәп хәрефләрендәге татар язуының үзенчәлекләрен белмәгәнлектән андыйлар اوغلى (угылы) дигән сүзне «әү Гали» дип танулары гаҗәп түгел. Шулай ук Коръәнне яхшылап укырга өйрәнгән милләттәшләребезнең татарча басма текстларны да «хәрәкәләрсез ничек укырга соң моны?» дип аптырауларын еш ишетергә туры килә.

## Имля тотрыксызлыгы

Галим Х.Курбатов татарлар кулланган гарәп алфавитының имля тотрыксызлыгы турында тәфсилләп язган дип әйтеп үткән идек. Аерым алганда, ул татар текстларын язу өчен гарәп алфавитында тартык авазларның һәрберсенә аерым хәрефләр булган хәлдә, сузыкларның берничәсе өчен берәр генә хәреф кулланылганын һәм еш кына тар әйтелешле сузыкларның бөтенләй язылмавын искәрткән [40, 32].

Галимнәр билгеләвенчә, татарларда гарәп язуының «иске имля» чоры XIX гасыр ахырына кадәр дәвам иткән.

XX гасыр башында татар матбугатында бер үк сүзнең әллә ничә төрле язылышта бирелүе – бердәм орфография булмавының күрсәткече. Имля мәсьәләсенең төзәтелергә һәм аерым кагыйдәләргә нигезләнергә тиешлеге турында XIX гасыр ахырында башлап җитди фикер йөртүче дип, Х.Курбатов Каюм Насыйрины атаган. Шулай ук Шакирҗан Таһири, Әхмәтһади Максуди һәм бүтән галимнәрнең, мат-

бугат һәм каләм әһелләренең бу юнәлештәге тырышлыкларын, бәхәсләре белән нәтиҗәләрен яхшылап тасвирлаган, «иске имля», «урта имля» һәм «яңа имля» үзенчәлекләрен аңлаткан. Татар орфографиясенең камилләштерелгән варианты Татарстан хөкүмәте тарафыннан 1920 елның 19 декабрендә законлаштырылганы турында язган [40, 34–65].

Татарча язуның кагыйдәләргә нигезләнергә тиешлеген зарур күргән мөгаллимнәрнең XX гасыр башында бастырган китапларында кызыклы фикерләр күп. Мәсәлән, Фатих Садыйков язу кагыйдәләре һәм тәртипләре эшләнмәгәнгә күрә «беребезнең язуын икенчебез укый алмый» кебек, газеталарга хатлар юллаучыларның язуларын да танып булмаганлыгы турында мисаллар китергән [68, 3], «бу заманга кадәр тәртипсез-кагыйдәсез язып килдек, моннан соң да шулай үтәр әле» дип уйлау – ахыр дәрәҗәдә наданлык, дип бәяләгән.

Элекке татар мәктәпләрендә язарга өйрәтү хәлфә-укытучының ихтыярына һәм теләгенә бәйле булган. Беренче нәүбәттә балаларны укырга өйрәтү максаты куелган, ә язуны белдерү мәҗбүри булмаганлыктан, аның белән аз, чикләнгән микъдарда гына шөгыльләнгәннәр. Язарга өйрәтү укытучының сәләтенә һәм осталыгына кайтып калган. Гарәп хәрефләрен танытканда да, аларның аерым язылыш рәвешләрен ятлап үзләштерү ысулы кулланылган. (Кадими татар мәдрәсәләрендәге әлифба дәреслеге «Иман шарты» китабыннан да бу ачык күренә). Иҗтиһадлы һәм язуга күңел куйган хәлфә, әлбәттә, шәкертләрен дә өйрәтергә тырышкан. Кайбер мәдрәсәләрдә исә язуга аеруча зур әһәмият бирелгән, хаттатлык осталыгы өйрәтелгән, китаплар күчереп язылган. Ә хәлфә битараф булган очракта сәләтләре һәм теләкләре булган укучылар язу серләрен өлкәнрәк һәм ул мәсьәләдә тәҗрибәле шәкертләрдән үзләштергәннәр. Ризаэтдин Фәхретдин бер мәкаләсендә мәдрәсәләрдәге

шәкертләрнең бер өлеше хат язарлык дәрәҗәдә дә язу белмәгәнлекләрен искәрткән. «Мәдрәсәләрдә 21 еллап торып та, яза белмәүчеләре бар» дигән ул һәм мондый күренешнең бөтен мөселман дөньясында шулай икәнлеген Җәмалетдин Әфгани хәзрәтләреннән ишетүен белдергән [84, 560–561].

Кыз балаларны исә язуга өйрәтү бөтенләй гамәлдә булмаган диярлек. Укымышлы затларның, кайбер муллаларның кызлары үзлекләреннән язарга өйрәнгәннәр. Татар хатын-кызлары тарафыннан күчерелгән-язылган, XIX гасырга нисбәтле кулъязмалар (дини текстлар, мөнәҗәтләр, хатлар һ.б.), сирәк булса да, бар.

Татар кулъязмаларындагы имля тотрыксызлыгының төп сәбәпләреннән берсе – язуга өйрәтүнең гомуми кагыйдә рәвешендә гамәлдә кулланылмавыннан да килгән.

XIX гасыр ахырында татарларда җәдит мәктәп-мәдрәсәләре эшли башлагач һәр шәкертне (шулай ук кызларны да) дөрес һәм матур итеп язарга өйрәтү бурычы куелган.

Төрле гасырлардагы татар кулъязмаларында, нинди текст булуларына карамастан, имля (орфография) тотрыксызлыгы – иң күп очрый торган үзенчәлекләрнең зурысы. Имля төрлелеге, беренчедән, географик чикләр белән бүленмәгән бай язма китап традициясе йогынтысыннан һәм, икенчедән, татар теле өчен орфографик кагыйдәләрнең тәгаен эшләнмәгән булуыннан килә. «Татар археографиясе» сериясендә басылган китапларда бирелгән текстлардагы андый очракларны даими күрсәтә бардык. Кайберләрен монда да искәртеп үтәбез.

Еш очрый торган орфографик төрлелекнең берсе *ч/җ* хәрефләре. Күп очракта иске текстларда «ч» хәрефе урынына «җ» язылган. Шулай ук, киресенчә – «җ» урынына «ч» теркәлгән кулъязмалар да бар. Шунлыктан, иске текстларны – гарәп хәрефләре белән язылган әдәби һәм тарихи мирасны – гамәлдәге татар әлифбасына күчереп бастырганда турыдан-туры транслитерация ясау һәрвакытта да үзен акла-

мый. Кайчакта андый ысул буталчык һәм гаять мәгънәсез нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, «Кыйссаи Мансур»да һәм бүтән әсәрләрдә күп очрый торган, борынгы төрки телдә Аллаһ мәгънәсен белдергән «Чәләб» сүзе текстларда бары тик «җ» хәрефе белән (جلب рәвешендә) язылган. Менә бу сүз транслитерациядә «җәләб» дип языла иде. Ә «җәләб» – фарсы телендә «җиңел холыклы хатын-кыз» дигән мәгънәгә ия. Иске әсәрләрдәге ул сүз хәзерге тестларда «җ» белән бирелсә, илаһи затка нинди көфер сүз белән эндәшү килеп чыга![7] Бу мисал, гарәби текстларның хәрефләрен автоматик рәвештә генә кириллицага алыштыруның дөрес булмавын ачык күрсәтә[8].

Хәрефләрне киресенчә алмаштырып язу күренеше татар кульязмаларында шулай ук аз түгел. Мәсәлән, «Кыйссаи Мансур» күчермәләрендә «иҗад» сүзен «ичад» дип, «вөҗүд»не – «вөчүд», «җәвәлян»не – «чәвәлян», «чабек» сүзен «чапек» дип язулар бар [62, 27]. Менә болар орфографик тотрыксызлык нәтиҗәсе.

Борынгы чор кульязмаларына хас булган күп кенә үзенчәлекләр «Кыз хикәяте» текстында да бар. Ягъни, «ч» һәм «җ», «т» һәм «д», «б» һәм «п» хәрефләрен үзара бутап язулар очрый. Мәсәлән,«анча» сүзе урынына انجا (анҗа) дип, «чаһ» сүзе урынына جاه (җаһ), «пәнҗәрә» урынына پنچره (пәнчәрә), «чабар» урынына چپر (чапар), «беңʼ» урынына «пең» [41, 33], «чөн» сүзе урынына «җөн», «бөрҗ» урынына «бөрч», «һәп» урынына «һәб», «капу» урынына

---

[7] Кызганыч ки, әдәбият тарихына багышланган фәнни китаплар арасында кириллица алфавиты белән нәкъ шулай бозык басылганнары бар. «Татар әдәбияты тарихы»ның соңгы басмасында да (2 том, 2022) Алла мәгънәсендәге «Чәләб» сүзе «җәлеб Кадыйр» дип бирелеп (170 биттә), «җәлеб» сүзенең бу очракта нәрсәне белдергәнлеге искәртелмәгән.

[8] Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтенең гарәп хәрефләрендәге иске басмасында «ч» урынына «җ» язылганга күрә, соңгы чорда рус теленә тәрҗемә ителгән текстларында Мәчкәрә дигән авыл исеменең «Маджкара» рәвешендә бозылып бирелүе дә дөрес түгел.

«кабу», «тапусына» урынына «табусына», «ошбу» урынына «ошпу» рәвешләрендә язылган сүзләрне әйтергә була. Әмма тексттагы мондый бутап язулар тотрыксыз: дөрес язылган сүзләр белән янәшәдә үк диярлек ялгыш язылганнары да бар. Болар нинди дә булса кагыйдә һәм имля үзенчәлеген белдерми.

Бер үк кулъязмада бер үк сүзнең төрлечә язылган булуы иске текстларга хас күренеш. Мәсәлән, 1581 елгы сүзлектә бер үк сүз төрлечә – *т/д, ч/җ* хәрефләренең алмашуы рәвешендә теркәлгән. Мәсәлән, *дүтен/түтүн, сач/саҗ, күгәрчен/күгәрҗен, балчык/балҗык, агач/агаҗ* [2, 345–346] һ.б.

Элеккерәк әсәрләрнең кулъязмаларындагы имля төрлелеге сүз башындагы «э» һәм «и» хәрефләренең язылышында да күзәтелә. Мәсәлән, «эш» сүзе ике төрле اش һәм ایش дип, «имди» сүзе امدی һәм ایمدی рәвешләрендә, «кыл» (кыйл) сүзе قل һәм قیل, ә «эчрә» сүзе اچرا ایچرا ایچره булырак, төрлечә язылган.

Янәшә килгән ике сүзне кушып язу күренешен «Кыйссаи Мансур» әсәре күчермәләре мисалында әйтергә мөмкин. Мәсәлән «ул дәм» – اولدم, «сән дәхи» – سندخی, «имди тиз» – ایمدیتز рәвешендәге һ.б. язылышлар шундыйлардан [62, 26].

Гомумән, татар язма чыганакларында кулланылган гарәп әлифбасы хәрефләрен тиешенчә укый белү зарур. Текстологиядә гарәп язулы сүзләрнең хәрефләрен генә автоматик тәртиптә кириллицага алмаштыру дөрес булмый.

Гарәп язуындагы текстларда хәрефләр (бигрәк тә сүз ахырларында), аларның нокталары һәм аерым элементларының төшеп калган булуы киң таралган. Кайбер сүзләрнең гомуми кабул ителгән язылышын бөтәнчәрәк теркәү күренешләре дә аз түгел.

Хатларның һәм документларның язулары еш кына ашыгыч рәвештә һәм бозыграк итеп теркәлгән. Бу – аларның кыска вакытлы кулланылышына да бәйле булган. Ә китап-

лар озак файдалану өчен күчерелгәнлектән, аларны матуррак итеп язарга тырышканнар.

Гарәп хәрефләренә нигезләнгән иске татар язуында «кәф» хәрефенең төп шәкеле кебек «ң» һәм йомшак «г» хәрефләре электән үк булган. Ләкин орфографиянең катгый кагыйдәләре эшләнмәгәнлектән, «ң» һәм «г» урынына еш кына «кәф» хәрефе язылган. Шулай ук «г» урынына «ң» язу күренеше дә киң таралган. Мәсәлән بیلکی (билге), کُل (гөл) һ.б.

Иске текстлардагы архаиклашкан сүзләрне кулъязма күчерүчеләр җиңелрәк һәм үз чорына аңлаешлы синонимнары белән алыштырган очраклар шактый.

Ә искергән һәм лексик мәгънәсе төшенелмәгән архаик сүзләрне күчерүчеләр үзләре аңлаганча, язылышы буенча охшаш, ләкин бөтенләй бүтән мәгънәдәге гыйбарәләр язып кую күренешләре булган. Мәсәлән, «алысдан» сүзе «алдан» яки «асдан» дип, «ләшкәр» гыйбарәсе «шөкер» дип, «казгу» сүзе «кызы» рәвешендә үзгәртелгән [90, 91]. Шулай ук мәгънәләре аңлаешлы булса да, кайбер сүзләр (бәлки, протографында ук бозып язылгангадыр) үзгәреш кичергәннәр. Мәсәлән, «Иделнең» сүзен «Әүлинең», «үзүңезне» сүзен «рузуңызны», «йөрәкле» сүзен «йөргәле», «тамаша» сүзен «шәмаса», «кәрвансарай» сүзен «кәрвансәди» дип язылган очраклар бар [90, 145, 148, 149, 168, 172].

Текст күчерүчеләр тарафыннан архаик сүзләр танылмыйча, үзгәрешсез яки бозып язылган булуы да ихтимал. Кайбер очракларда, диалекталь яки аерым бер төбәкнең җирле сөйләменә генә хас сүзләрне күчерүчеләр төшенмәгәнлектән, үзгәртеп яки бозып, гомумән, төрлечә язганлыкларын күрергә мөмкин. Кулъязма күчерүчеләр тарафыннан кертелгән шундый текстологик «төзәтмәләр», һичшиксез, иске кулъязмаларны аңлауны һәм дөрес мәгънә вариантын ачыклауны читенләштерә.

Элекке кулъязма текстларда «тагын» мәгънәсендәге تقی (тәкый) сүзен, «такы» дип укылырга һәм язылырга тиеш,

диюче фән әһелләре бар. Әмма андый караш дөрес түгел дип исәплибез. Беренчедән, бу сүз, чынлап та «такы» дип әйтелгән булса, аның калын итеп – تاقى яки طقى рәвешләрендә язылган очраклары да сакланыр иде. Никадәрле кулъязмалар белән эшләп тә, үзебез андый язылышларны күргәнебез булмады. Икенчедән, татар теленең тирәннән-ерактан килгән тамырлары өзелеп-тукталып тормаган һәм, шунлыктан, бу сүз кулланылыштан (укылыштан) җуелмаган. Ягъни, хәзерге текстологларның аны ялгыш яисә бозып уку ихтималына нигез юк. Чөнки татар мәдрәсәләрендә электән алып XX гасыр башына кадәр дәреслек сыйфатында кулланылган һәм укучылар тарафыннан ятлап өйрәнелгән әсәрләрнең берсе – XII гасырда яшәп иҗат иткән Сөләйман Бакырганиның шигъри ядкяре – «Ахыр заман»ның һәр строфасы ахырында кабатланган «Андин артык тәкый гаҗәп хәлләре бар» рефрены аша «тәкый» сүзе хәзергәчә килеп ирешкән. «Ахыр заман» текстлары совет чорында да – бигрәк тә 1950–1970 нче елларда шактый күчерелгән. Бакырганиның бу әсәрен татарлар «Тәкый гаҗәп» дип атап йөрткән булуларыннан да әлеге сүзнең әйтелеше һәм язылышы ачык күренә. XX гасыр башы татар әдәбияты классикларының әсәрләрендә, шулай ук үзләре мәдрәсә белеме алган һәм совет чорындагы идеологик карашлар чорында әсәрләр иҗат иткән татар авторларының элекке дини гыйлеме турында язганда шул ук китап «Тәкый гаҗәп» дип искә алынган. Менә бу дәлилләр «тәкый» сүзенең татар телендә элек-электән нәкъ шул рәвештә әйтелгәнен һәм язылганын белдерә. Әлбәттә, татар халкы яшәгән аерым төбәкләрнең сөйләм үзенчәлекләренә күрә, «тәкый»не «такы» дип әйткән булулары мөмкин. Калын яңгырашлы сүзләрне йомшартып яки киресенчә – йомшак сүзне калынайтып әйтү күренешләре хәзер дә бар (мәсәлән, *әче – ачы, ачкыч – әчкеч, мәче – мачы* һ.б.)

XVIII–XIX гасырлардагы татар кулъязмаларында рус сүзләре сирәк булса да очрый. XX гасыр башында

алар инде күп санда. Андый сүзләр татарча әйтелешләре рәвешендә теркәлгән булалар һәм шул сәбәпле текстны йөгерек кенә укыган кеше дә, төртелеп, аптырап калуы мөмкин. Рус һәм Европа календарьларыннан татарларга кергән ай исемнәренең төрлечә һәм үзгәртебрәк язылган булуы да моңа ачык дәлил. Мәсәлән, فبرال فيۋرال (февраль), آغست آغوست (август), سنتاب سنتابر (сентябрь), اوكتب اوكتابر (октябрь) һ.б.

Гомумән, татар кульязмаларында рус сүзләрен кем ничек ишеткән – шул рәвештә, ягъни аерым бер кагыйдәсез генә, төрлечә язган. Бер үк сүз берничә төрле язылышта теркәлгән. Мәсәлән, Мәскәү атамасын مسكو مسكاو һ.б. рәвешләрдә очратырга мөмкин. «Старшина» сүзенең язылыш төрләре: اسطرشنه اسطارشنا ستارشينا һ.б.

«Татар археографиясе» сериясенең моннан алдагы басмаларыннан берсендә 1540 елгы татар кабер ташындагы «Мурам» (Муром шәһәре) атамасының ялгыш укылган булуын аңлатканда әлеге мәсьәләгә игътибар юнәлткән идек. Ягъни, «татар палеографиясенә хас бер күренешне искә алып китү дә урынлы булыр – гарәп хәрефләрендә язылган нинди дә булса иске текстта берәр рус яки Европа сүзе-атамасы очраганда, сирәк һәм гайре табигыйрак күренеш булганлыктан, тәҗрибәле археографлар да сагаеп кала» [31, 71] дип яздык. Шулай ук, хосусый актлар җыентыгында басылган кечкенә генә күләмле, 1755 елгы бер документта рус сүзләренең шактый булуын һәм татарча әйтелгән рәвешләрендәге вариантларын күрергә мөмкин [38, 52–53].

Хаталар белән язу һәр чорга һәм һәр халыкка да хас. Ул җәһәттән татар кульязмалары да калышмый, аларда хәреф-орфография хаталары җитәрлек күләмдә. Бөтенләй хатасыз диярлек яки берничә генә хаталы кульязмалар булган кебек, бихисап күп хаталар белән язылганнары да бар. Укымышлы һәм тирән белемле муллаларның да ашыгып язганда хаталары киткән [31, 207], әлбәттә. Кульязма китапларны,

бәет-шигырьләрне күчерүчеләр, хат авторлары бөтенесе дә зур гыйлем иясе булмаган бит. Шунлыктан, элекке гасырларда дөньяда яшәп, язма истәлекләрен калдырган каләм ияләреннән камиллек таләп итә алмыйбыз. Димәк, текстлардагы хаталар – котылгысыз күренеш буларак кабул ителергә тиеш.

Орфографик хаталар иске текстлар белән эш итүче белгечләргә, фән әһелләренә өстәмә мәшәкать һәм кайчагында катлаулы табышмаклар тудыруы ягыннан, әлбәттә, читен бер нәрсә. Археографик сериядә дөнья күргән текстларның төп чыганакларында хаталары шактый булган берничәсен искә төшерик. «Татар археографиясе» сериясенең «Чыңгызнамә» җыентыгында урын алган XVIII гасыр ахыры күчермәсендәге «Фәлдә ил», «Лчәй», «шуар ик», «халкы йәнә адашынла» сүзләре чынлыкта «Фидур атлы», «Аләкчәй», «шул ике», «халыкның арасында» дигәннән бозып язылган [90, 249].

Сериянең 14 нче китабындагы өлкән – 80 яшь тирәсендәге авыл агаеның дәфтәрендә ялгыш язылышлар шактый иде. Мәсәлән, «кадарым» (дөресе – карадым), «Менгендәгазиз» (Миңнегазиз), «Коталуг ш» һәм «Котылфаш» (Котлыгыш), «эруллитәсә» (революция), «карадләре» (кардәшләре), «сүрләрам» (сүзләрем), «кәрарым» (килограмм), «беркердилер» (бригадир), «бинә йүркә» (буена йөрдек) [22, 138]. Шул ук китап сериясенең 20 нче китабында нәшер ителгән татар матросының дәфтәрендә шактый сүзләрнең хәрефләре һәм хәреф элементлары, нокталары төшеп калган. Хәрефләрнең урыннары бутап, «гөнаһым» сүзе «ганһым», «шөбһә» сүзе «шәһбә» рәвешендә язылган кебек урыннары да бар. Сүзләрнең башында һәм урталарында *ы, э, е* хәрефләре маддәле әлиф белән теркәлгән. Автор кулъязмасындагы менә шундый хикмәтләрне төшенмичә, укырга һәм мәгънәләрен аңларга шактый читен. Чөнки автор язган *астанчы, төрәк, армизан, Ауымаскый* сүзләре *ыстанчы,*

*төрек, ырамазан*, *Омски* [43, 118] дип укылырга тиеш. Менә мондый орфографик кимчелекләр, дәфтәр язылган катлаулы шартларга күрә, зур ялгышлар дип исәпләнә алмый. Археография сериясендә 22 нче китап буларак 1904–1905 еллардагы рус-япон сугышы вакытында әсирлеккә төшкән татар солдатының дәфтәрендәге фольклор әсәрләре нәшер ителгән иде. Бу дәфтәрдәге текстлар да хаталар белән язылган. Аның иясе «р» хәрефен еш кына «әлиф» кебек, «б» һәм «т» хәрефләре урынына «н», ә «н» урынына «з» хәрефләре язу кебек үзенчәлекләре белән беррәттән, күп кенә сүзләрне һәм иҗекләрне төшереп калдырган. Дәфтәрдәге *авы, безкә, берәк, дакыт, изка, мек, рас, ятырту, яйу* кебек, гаять хаталы итеп язылган сүзләрнең дөреслектә *авылы, беләзек, җөрәк, тәкать, ризык, мескен, ранец, патрон, япон* икәнлеген төшенү бик читен [72, 17].

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, элекке язма текстлардагы хаталар кешенең белеменә генә бәйле булмаган. Чөнки укымышлы затларның, муллаларның яшьрәк вакытларындагы язулары төзегрәк, нәфисрәк һәм хатасыз булса да, олыгайган көннәрендәге язмалары бозыграк һәм хаталырак. Болар – кешенең яшь үзгәрешләренә бәйле табигый сәбәпләр. Шулай ук, иҗтимагый-сәяси шартлар да (бигрәк тә, сугыш халәте) язуның төзеклегенә тәэсир иткән. Сугыштан – фронттан язылган хатларда да хаталар күп очрый. Сугыш хатларының кайберләрен танып-төшенеп бетү тәҗрибәле археографлар өчен дә читен. Бөек Ватан сугышы чоры хатларында хаталарның күплеге, беренчедән, табигый хәл, чөнки «Ул елларда авыллардан армиягә (һәм сугышка) алынучыларның күпчелеге аңа кадәр үз районы эченнән ерак юлларга чыкмаган («дөнья күрмәгән»), русча юньләп сөйләшә һәм яза белмәгән, үз телендә дә грамоталыгы чамалы булган кешеләрдән (күбрәк яшьләрдән) тора иде (төп масса 4–7 еллык белемле, унъеллык белән бик сирәк, хәтта бөтенләй укый-яза белмәүчеләр дә булган). Шунлык-

тан, бу кимчелек кайбер хатларда ачык чагылган» [71, 4]. Икенчедән, сугышчылар үзләре үк хат язарга мөмкинлек һәм вакыт булмавын, эшелонда барганда яки караңгы урманда язганлыгын, шулай ук госпитальдә яралы хәлдәге җайсызлыкны еш искәрткәннәр [15, 37–38]. Гадәттә, төп сәбәпләрнең берсен ашыгычлык тәшкил иткәндер. Хатлардагы хаталарның өченче төп сәбәбе кешенең сугыш шартларындагы киеренке психологик-эмоциональ халәте белән турыдан-туры бәйле булган.

Окоплардагы сугышчылар үз туганнарына язып җибәргән бәетләрнең дә язу-почерклары гаять катлаулы һәм аерым очракларда бозык, аларда хәреф хаталары шулай ук күп була.

Хәер, хаталар мәсьәләсенә килгәндә, хәзерге чордашларыбыз да орфографияне саклап язмавы, шулай ук матбаганәшриятларда берничә хезмәткәр тикшергәннән соң да матбугат басмаларында хаталарның калуы һәркемгә билгеле һәм күпмедер дәрәҗәдә котылгысыз диярлек. Шунлыктан, XXI гасырдагы югары белемгә ия кешеләр даирәсендә хатасыз язу мәсьәләсе дәвам иткән хәлдә, әүвәлге – XVIII–XX гасырлардагы татар кулъязмаларындагы хаталарга һич тә гаҗәпләнерлек түгел.

Совет чорында гарәп хәрефләре нигезендәге татар орфографиясе үзгәреш-реформалар кичереп, яңа хәрефләр һәм аларга төрле билге-тамгалар өстәлгән булуын да искәртик. Әмма яңа имля гамәли яктан, иске имля язуына караганда, танып уку өчен катлаулырак. Чөнки тиз-тиз язган вакытта хәрефләрнең нокталары, һәмзә һәм өтерсыман билгеләре шактый буталчык тудырган.

Совет заманына (бигрәк тә, 1970–1980 нче елларга) караган, гарәп хәрефләрендәге кулъязма дәфтәрләрдә һәм хатларда имля тотрыксызлыгы, шулай ук хаталар аерым бер үзенчәлекле төркемне тәшкил итә дияргә мөмкин.

Иске кулъязма текстлар белән эш итүчеләр хаталарны

гайре табигый хәл дип кабул итмичә, кимчелекләрен ачыклап, дөреслəп укырга тырышырга тиеш.

## «Өзек» хәрефләрне тоташтырып язу

Гарәп орфографиясе буенча «өзек», ягъни үзеннән соң килгән хәрефкә ялганмый торган хәрефләрне татар кульязмаларында тоташтырып язу еш очрый. Мондый күренеш борынгы чорлардан килә. Андый очраклар сөлес язулы болгар ташларында да бар.

«Өзек» хәрефләрне искә төшерик, алар барлыгы тугыз:
ا د ذ ر ز ژ ه و ۋ

Мондый төр хәрефләрнең үзара ялганып язылулары гарәп каллиграфиясенең кайбер төрләренә (тәгъликъ, дивани, шикәстә, рокъга һ.б.) хас булган үзенчәлекләргә дә бәйле. «Уау» хәрефенең үзеннән соң килгән хәрефкә ялганып язылуы сөлес-иҗазәт төренә хас дип яза Р.Кадыйров [36, 158].

Татар палеографиясендә өзек хәрефләрне ялгап язу күренешләре, гомумән, киң таралган. Ул, гадәттә, тиз һәм ашыгыч язылган текстларда: хатларда һәм документларда күп очрый. Шулай ук кайбер кульязма күчерүчеләрнең андый алымны аеруча үз иткәнлеген дә искәртергә кирәк. Берничә өзек хәрефтән торган сүзләрдә аларның барысы да тоташкан яисә кайберләре генә ялгап язылган булырга мөмкин. Һәрхәлдә, андый төр язылышлар аерым бер кагыйдәгә нигезләнмәгән. Кульязма текстларда күп кулланылган яки еш очрый торган сүзләрдәге һәм сүзтезмәләрдәге өзек хәрефләр ялгап язылганнар. Андый мисалларны бик күп китерергә мөмкин. Кайберләрен күрсәтеп үтәбез.

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән*[9] | *кульязмалардагы вариантлары* | | |
|---|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* | *3* |
| илән | ایلان |  |  |  |
| берлән | برلان |  |  |  |
| сәлам | سلام |  |  | |
| әс-сәлам | السلام |  |  | |
| ирде | ایردی |  |  |  |
| дамелла | دملا |  |  | |
| дәрес | درس |  |  | |
| әфәнде | افندی |  |  | |
| кулым куйдым | قولوم قویدوم |  |  |  |
| тамга салдым | تمغه سالدوم |  |  | |
| хәбәрдар | خبردار |  |  | |
| мәгариф | معارف |  |  | |
| виреләдер | ویرلادور |  |  | |
| ахунд | آخوند |  |  | |
| хаҗи | حاجی |  |  | |
| улган | اولغان |  |  |  |
| Әхмәджан | احمدجان |  |  | |

[9] Монда һәм башка таблицаларда мисал итеп күрсәтелгән сүзләрнең кайберләре кульязма вариантларда төп чыганактагыча хаталы яки бозыбрак язылса да, басма гарәп хәрефләре белән бирелешләре дөресләп тәкъдим ителде.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Вәдүд | ودود |  |  | |
| мулла Таhир | ملا طاهر |  | | |
| мулла Галләмед-дин | ملا علاءالدين |  | | |
| гуаh | گواه |  |  | |
| -лардан | لاردن |  | | |
| сәяхәт | سياحت |  | | |
| булгучы | بولغوچی |  |  | |
| әхваләт | احوالات |  |  | |
| өчен | اوچون |  |  | |
| итеп | ایتوب |  |  |  |

Кулъязмаларда күп очрый торган «кулым куйдым» дигән сүзтезмәнең язылыш вариантлары да бихисап. Аның сүз ахырларындагы «мим» хәрефләрен чәчәксыман бизәк кебек төрлечә итеп боргалап та куйганнар. Мәсәлән, 1825 елгы хосусый акт язуы факсимилесенең соңгы юлында (сул якта) [38, 102] шундый очракны күрергә мөмкин.

## Хәреф нокталары

Гарәп хәрефләренең өсләрендәге һәм асларындагы нокталар диакритик билгеләр дип атала. Элек нокталарсыз булган гарәп хәрефләренә VII гасырда нокталар куела башлаган.

Татарлар тарафыннан кулланылган гарәп һәм фарсы әлифбаларындагы хәрефләрнең аерым өлешенең төп ни-

гезләре бер төрле үк язылган. Аларның аермалары исә ничә (бер, ике, өч) нокталары һәм аларның төп элементның астында яки өстендә язылган булуына карап аерылган.

Бер нокталы хәрефләр: ب ج خ ذ ز ض ظ غ ف ن

Ике нокталы хәрефләр: ت ق ي

Өч нокталы хәрефләр: پ ث چ ژ ش ڭ ۋ

Хәрефләрнең ике ноктасын вертикаль итеп тә теркәгәннәр. Аларны кульязмаларда еш кына сызыкча белән билдергәннәр. Ә өч нокта төрлечәрәк рәвешләрдә  язылган. «Сә» һәм «шин» хәрефләренең өчәр ноктаeasын, сирәк булса да, бер рәткә тезеп язу очрый.

Нокталарны язуда билдергәндә хәрефнең төп элементыннан кулны аермыйча гына язу киң кулланылган. Шулай ук кайбер каллиграфик төрләрнең (рокъга) үзенчәлекләренә бәйле рәвештә ноктaлы хәрефләр сүз ахырларында килгәндә төп элементтан аерылмыйча, хәрефнең дәвамы кебек тоташтырып язылган. Мәсәлән, «ти», «шин», «фа», «каф», «нун» – .

«Җим» һәм «ч» хәрефләренең аерым язылыш очракларында нокталарын татар кульязмаларында төп элемент астында язу күренеше дә киң таралган. Мәсәлән, .

Мисаллар:

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | | *искәрмә* |
|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | |
| таш | تاش |  |  | 2 нче вариантта «шин»нең нокталары хәреф ахырында билдерелгән |
| кадак | قاداق |  |  | |
| чат | چات |  |  | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| кач | قاچ | قاج | قاج | |
| син | سين | سين | سين | |
| сач | ساچ | سيج | ساج | |
| таҗ | تاج | تاج | تاج | |
| фаш | فاش | فاش | فاش | |
| сани | ثانى | ثانى | ثانى | |
| әс-сани | الثانى | التانى | الثانى | |
| бәйт | بيت | بيت | | «би»нең бер һәм «йа»ның ике нокталары берләштереп язылган |
| белгел | بيل كيل | بيل كيل | | |
| ишетте | ايشتتى | اشتى | يشتدى | |
| хәзрәт | حضرت | حضرت | حضرت | |
| ибне | ابن | ابن | ابن | |
| Сабит | ثابت | تابت | ثابت | |
| хуш | حوش | حوش | حوش | |
| авылында | آولنده | آولنده | | |
| ошбу | اوشبو | اوسبو | | |

Гарәп әлифбасындагы ноктасыз кайбер хәрефләрнең асларына нокталар кую очраклары да булган. Алар IX гасырдан ук билгеле дип яза Рәшит Кадыйров. Болгар чоры ташъязмаларында ط س ر د һ.б. кайбер хәрефләрнең асларына нокта кую күренеше элеккерәк чордагы Коръән язу традициясенә бәйле булса кирәк, ди ул [36, 67]. Гарәп

әлифбасында төп элементлары бер төрле үк язылышта булып, өсләрендә нокталар куела торган хәрефләрне ноктасызлары белән бутамас өчен шундый ысул гамәлгә кергән. Ягъни, өсләрендә нокта тәгаен булмавын белдерү максатында *дәл, ра, тый* хәрефләренең асларында берәр нокта ڊ ڔ طٜ һәм син хәрефенең астында өч нокта куелган: ڛ . Ноктасыз ح س ص ط ع م хәрефләре асларында шуларның ук кечерәк (1/3 зурлыгындагы) вариантлары язылган, *һә* (һаи рәсмия) хәрефенең үзеннән алдагыларга тоташкан сүз ахырындагы шәкеле өстендә кечкенә итеп *һә* хәрефенең сүз башындагы рәвеше теркәлгән: ۂ . Андый махсус билгеләр «мөһмәл» (ноктасыз хәреф ишарәте) дип аталган. Мөһмәлләрнең күбесе каллиграфик язуларга хас булса, хә белән гайн астындагылары ح ع татар кульязмаларында шактый күп кулланылган. Гайн астындагы шундый билге XVI–XVIII гасыр кульязмаларында кулланылганлыгы күренсә, *хә* хәрефенеке XIX гасырда да язылган. Менә шундый палеографик үзенчәлекләрне төшенеп җитмәгәнлектән, кайбер текстологлар хә хәрефе астындагы билгене «ч» хәрефенең өч ноктасы дип кабул итеп ялгышалар.

Хәреф асларында куела торган өч ноктаның икесе өстә, ә берсе түбәндә урнашырга тиешле булса да, киресенчә язылган очраклары да булган.

Мисаллар:

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмадагы вариант* | *искәрмә* |
|---|---|---|---|
| укыса | اوقسا | اوقپا | XVII гасырда |
| сәнең | سنك | ڛنك | |
| ирсә | ايرسه | ايرڛه | |
| сагъ | ساغ | ڛاغ | |

Хәреф асларына нокталар куеп һәм мөһмәлләр белән язылышларны Казан ханлыгы чорындагы эпиграфик истәлекләрдә һәм шулай ук XVI–XVII гасыр татар кулъязмаларында да еш күрергә мөмкин. Аннан соңгы чорда юк диярлек, бары тик «син» хәрефе астында өч нокта һәм «уау» хәрефенең өстендә өч нокта кую сакланган.

## Хәрефләр

Гарәп хәрефләренең татар кулъязмаларындагы орфографик һәм палеографик үзенчәлекләрен мисаллар ярдәмендә күздән кичерик. Алдан ук искәртик – татар кулъязма мирасы искиткеч бай һәм күптөрле. Бик нәфис, матур һәм дөрес язулы истәлекләр дә бар, шул ук вакытта бозык язулы, хаталылары да шактый. Гарәп хәрефләрендәге язылыш үзенчәлекләренең күпчелеге каллиграфик язу төрләреннән үк килгәнлеген әйткән идек инде. Әмма каләм тоткан һәркемнең үзенә хас ысулы-почеркы да булган, үзләренчә боргалап та язганнар. Шунлыктан, гарәп хәрефләренең язудагы пропорцияләре һәрвакытта да сакланмаган. Мәсәлән, «җим» һәм «гайн» шәкелләрендәге хәрефләрнең аерым (сүз ахырындагы) язылышлары еш кына башка хәрефләр белән бертигез биеклектә һәм кечерәк итеп теркәлгән. «Ти», «нун», «йа» кебек хәрефләрне исә сүз ахырларында гадәттән тыш зур итеп тә язганнар. Шулай ук бөгебрәк язылырга тиешле «ра» шәкелендәге хәрефләр еш кына вертикаль хәлдә, «әлиф» кебек үк диярлек биеклектә теркәлгәннәр. Мондый күренешләрнең кайберләре түбәндәге тасвирларда да искә алыначак.

Гарәп әлифбасының иң беренче – «әлиф» хәрефе «а», «ә», «и», «у», сүз башында шулай ук «э» һәм «ы» авазларын белдергән. Сүз башында «а» авазын белдергәндә күпчелек очракта «әлиф» өстенә дулкынсыман «маддә» билгесе куелган. Кайбер текстларда (борынгыракларында) исә ул билге

куелмаган. Димәк, аның язылышы тотрыксыз булган.

Кайбер алынма һәм төрки тамырлы сүзләрдә «әлиф» хәрефе бары тик «уау»ның озын аваз икәнлеген белдерү өчен генә язылган һәм үзе «а», «ә» яки башка аваз буларак укылмаган. Алтын Урда чорындагы текстларда озын «а» авазын белдерү өчен ике «әлиф» рәттән язылган очраклар да булган [66, 155].

Алда әйтеп үткәнебезчә, «әлиф» өзек хәреф булса да, аның кулъязмаларда үзеннән соң килгән бүтән хәрефләргә ялганган очраклары да күп. Андый мисаллар түбәндәге таблицада һәм башка хәрефләргә карата бирелгән мисалларда да күрсәтелде.

Сүзләрнең башында «әлиф» белән «йа» хәрефе язылганда икесе бергә «и» авазын белдергәннәр. Ә сүз башында «әлиф» һәм «уау» хәрефләре язылганда бергә *у, ү, ө, о* авазлары буларак укылган.

Тартык авазга башланган алынма сүзләргә сөйләм телендәгечә «ы» һәм «э» авазларын өстәп әйтү гадәте язма истәлекләрдә дә очрый. Бигрәк тә, хатларда, җыр-бәет текстларында һәм көнкүреш язмаларында аларны күрергә мөмкин. Мәсәлән, «эрәхмәт», «ыстансия» һ.б.

«Әлиф» хәрефе төрки-татар сүзләрендә XIX гасырның ахырына кадәр «а» авазын белдергән кебек үк, «ә»не белдерү өчен дә язылганлыгын истә тоту бик мөһим. Текстлардагы «әлиф»не бары тик «а» дип кенә укып ялгышулар күплеге китапның өченче бүлегендәге мисалларда ачык күренә. Әлиф хәрефе ы-ны белдергәндә дә ә дип укып хаталанулар еш очрый.

Мисаллар:

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кулъязмалардагы вариантлары* | | *искәрмә* |
|---|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* | |
| ат | آت | آت | آت | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| яшь | یاش | یاش | یاش | |
| өчен | اوچون | اوچون | اوچون | |
| хуҗа (хөөҗа) | خواجه | خواجه | خواجه | Соңгы өч очракта «әлиф» үзеннән алда килгән авазның озын әйтелешен белдерү өчен язылган |
| каму (камуу) | قموا | قموا | قموا | |
| көн (көөн) | کوان | کوان | کوان | |

Татар кулъязмаларының элеккерәкләрендә – XVII–XVIII гасырларда күчерелгәннәрендә, шулай ук XIX гасырдагы кайберләрендә озын «ө», «у» һәм «ү» авазларын белдерү өчен сүз ахырындагы «уау» хәрефеннән соң «әлиф» яки «йа» язылган очраклар бар. Мондый язылыш үзенчәлеге Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында, Казан ханлыгы чоры татар шагыйрьләреннән Мөхәммәтәмин һәм Мөхәммәдьяр әсәрләренең кулъязма күчермәләрендә һ.б. очрый. Шунысы игътибарга лаек, әлеге әсәрләрне XVIII–XIX гасырларда да аерым сүзләрнең язылышындагы элекке үзенчәлекләрне саклаган хәлдә күчереп килгәннәр. Борынгырак дәверләрдә иҗат ителгән әсәрләрдәге мондый имля хосусиятен хәтта XIX гасырдагы кайбер басма китапларда да күрергә мөмкин. Ягъни, кулъязмалардагы палеографик архаизмнар басмаларга да күчкән. «Татар археографиясе» сериясе басмаларында: XVIII гасырның соңгы чирегенә нисбәтле кулъязмада قموا (каму), عموا (гаму), اچروا (эчәрү), کروا (кирү), طموا (таму), «Чыңгызнамә»нең 1732 елгы күчермәсендә اوشبوا (ошбу), (каршы) һәм 1727 елгы текстта کونوا (Көнү), 1737–1739 еллардагы татарча документларда ایلوی (илү), 1819 елгы документта کندوا (кәндү), 1822 елгы алыш-биреш язмасы да

اوشبوا (ошбу), 1826 елгы килешүдә تیکروا (тигрү) дип язылган очракларга игътибар иткән идек [41, 33–34, 111; 90, 90; 38, 47, 50, 83, 85, 103]. «Кыз хикәятендә» بتوی (бөтү), ایلوی (илү), Мәүла Колый поэмасының 1754 елгы күчермәсендә سارۋی (сару) (41, 34; 53, 65) сүзенең язылышы да шундыйлар рәтендә. «Кыйссаи Мансур» әсәренең XVIII гасырның беренче чирегенә караган кульязмасында کتدوی (кәтде) [62, 122] рәвешендәге язылышы игътибарга лаек. Билгеле булганча, сүз ахырындагы «ы» һәм «е» (э) хәрефләрен төрки сүзләрнең ахырларында وی рәвешендә теркәү XIII–XIV гасырлардагы ташъязма истәлекләргә хас[10]. Аерым сүзләрдәге сузык авазны язуда белдергәндә еш кына берничә гарәп хәрефе кулланылганы һәм андый күренешнең уйгур язуы тәэсирендә булганлыгы турында Болгар чоры эпиграфикасын өйрәнгән галимнәр язган иделәр [64, 76–77].

Татар кульязмаларында мондый палеографик күренеш мәсьәләсендә Р.Кадыйров галимнәрнең төрле фикерләрен искә алган һәм аларны фонетик үзенчәлекләрне язуда төгәлрәк белдерү омтылышы белән бәйләп аңлаткан [36, 27].

«Чыңгызнамә» текстларындагы елъязма күчермәләрендә очрый торган «иркә чирүе» гыйбарәсенең дөрес түгеллегенә галимнәр Н.Катанов һәм Г.Рәхим игътибар итеп, аңлатканнар. Әлеге гыйбарәнең борынгырак текстларда очрый торган палеографик үзенчәлеккә ия булуын, «чирү» сүзенең ахырындагы озын «ү» авазын белдерү өчен «йа» хәрефен язудан чыккан буталчык дип, үзебездән өстәп язган идек [90, 88]. Ягъни, гарәп хәрефләре белән ایرکا چیروی дип язылган сүзләр «иргә чирү» дип укырга тиеш.

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең кайбер күчермәләрендә дә төрки сүзләрнең (*йүзлү, сүзлү, күрклү, шәфәгатлү* һ.б.)

---

[10] Иске ташъязма истәлекләрдәге сузык авазларны белдергән хәрефләрнең язылыш серләрен галим Г.Таһирҗанов яхшылап аңлаткан [78, 28–29].

ахырларындагы андый үзенчәлек «гарәп теле үрнәгендәге, укылмый торган әлиф» дип аталган [39, 441].

«Әлиф» үзеннән алдагы хәрефкә тоташып язылганда югарыга таба сызылырга тиешле. Ләкин, каурый һәм камыш каләмнәрнең югарыга юнәлгән хәрефләрне язганда кәгазь өслегенә төртелүчән булуы сәбәпле, үзенчәлекле алым кулланылган. Ягъни, алдагы хәрефнең төп элементын язгач, кулны кәгазьдән аерып, «әлиф»не өстән аска таба сызып куйганнар. «Тый»ның, «ләм»нең вертикаль өлешләре һәм «һа» хәрефенең сүз уртасындагы язылышында һ.б. кайбер очракларда шундый ук ысул кулланылган. «Ләм» хәрефенең тоташкан рәвештә сүз ахырындагы очрагында үзеннән алда язылган хәрефкә ялганып дәвам иткән килеш башта ярым түгәрәк түбәнге өлешен, аннары гына вертикаль сызыгын өстән-аска таба язганнар. Мондый палеографик үзенчәлек XVII–XIX гасырлардагы татар кульязмаларында бик күп күренә. Пугачёв чоры документларында тоташкан әлифнең өстән-аска таба язылу мисаллары бик күп дип язган Р.Кадыйров [36, 149]. Кайбер текстларда ашыгыч итеп язылган андый сүзләрне укырга-төшенергә читен, чөнки «әлиф» аерым язылган рәвешендәгечә кабул ителә.

Мисаллар:

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмадагы вариант* | *язылыш рәвеше* |
|---|---|---|---|
| хата | خطا | خطا |  |
| тавыш | طاوش | طاوش | |
| яки | یاکه | یاگه | |
| салып | سالیب | سالیب |  |
| солтан | سلطان | سولطان | |
| җиһан | جهان | جهان |  |

| | | | |
|---|---|---|---|
| миһербан | مهربان | مهربان | |
| Гатаулла | عطاءالله | عطاالله | |
| Хисаметдин | حسام‌الدين | حسام‌الدين | |
| Шаһимәрдан | شاه‌مردان | شاه‌مردان | |

Гарәп язуындагы «би», «пи», «ти», «си» хәрефләренең төп нигезләре язылышы бертөрле үк. Әлеге дүрт хәрефнең аермалары бары тик нокталарының санында (бер, ике, өч) һәм аларның төп элементның астында яки өстендә урнашуына бәйле. Мондый шәкелләрдәге хәрефләр үзләреннән соң «җим» шәкелендәге һәм «мим» хәрефләре алдыннан язылганда башкачарак рәвештә була.

«Ти» хәрефен төрки-татар сүзләренең ахырында кайбер очракларда «тә мәрбүтә» белән дә язганнар. Нокталарын шулай ук хәрефнең төп элементыннан кулны аермыйча да теркәгәннәр.

Мисаллар:

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| бат | بات | بات | بات |
| Ягъкуб | يعقوب | يعقوب | يعقوب |
| ошбу | اوشبو | اوشبو | اوشبو |
| тап | تاپ | تاب | تاپ |
| мисал | مثال | مثال | مثال |
| хәдис | حديث | حديث | حديث |
| хәзрәт | حضرت | حضرت | حضرت |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Бохара | بخارا | بخارا | بخارا |
| тәмам | تمام | تمام | تمام |
| дүрт | دورت | دورة | دورت |
| карт | قارت | قارت | قارت |
| сөт | سوت | سوت | سوة |
| солдат | صالدت | صالداة | صالداة |
| Биби | بى بى | بى بى | بى بى |
| Бибигазизә | بى بى عزيزه | بى بى عزيزه | بى بى عزيزه |
| Бибифатыйма | بى بى فاطمه | بى بى فاطمه | بى فاطمه |

«Җим», «ч», «ха» «хә» хәрефләренең дә төп өлешләре бер төрле үк булып, аермалары нокталарына (аларның санына һәм урыннарына) бәйле. Бу хәрефләрнең гарәп язуындагы үзенчәлекләренең берсе – үзләреннән соң килгән хәрефкә ялгану сызыгы кыска булганга бүтән хәрефнең өстендә урнашулары һәм үзләреннән алда килгән башка бер хәреф тә алар өстендә язылуында.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кулъязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| Мөхәммәд | محمد | محمد | محمد |
| ачкыч | آچقچ | آچقچ | آچقچ |

Татар кулъязмаларында «дәл» һәм «зәл» хәрефләренең язылышларындагы үзенчәлекләр каллиграфик нәстәгъликъ һәм шикәстә төрләренә якын булган. Өзек хәрефләр булса-

лар да, аларны башка хәрефләргә ялгап язу күренеше киң таралган.

«Дәл» хәрефеннән соң «ә» (һаи рәсмия) килгәндә, бигрәк тә «дә» кушымчасы язылганда, аерым бер лигатура кыяфәтен алган. Андый лигатура Казан матбагаларында басылган китапларда, газета һәм журналларда да киң кулланылган.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кулъязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| дәрес | درس | درس | درس |
| мөәзин | مؤذن | مؤذن | مؤذن |
| анда | آنده | آنده | آنده |
| йөздә | يوزده | يوزده | يوزده |
| анлардан | آنلاردان | آنلاردان | آنلاردان |
| Мөхәммәд | محمد | محمد | محمد |

«Ра», «за» һәм «ж» хәрефләренең төп элементлары бер төрле, аермалары фәкать нокталарындагына. Аларның язылышы, күбесенчә, гади сызык рәвешендә генә булган. Бу хәрефләрне дә башкаларына тоташтырып язганнар. Алардан соң «ә» (һаи рәсмия) хәрефе килгәндә кулъязмаларда кайчакларда кушып язу кулланылган булса да, андый үзенчәлек басмаларга хас түгел.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кулъязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| базар | بازار | بازار | بازار |
| мәгарә | مغاره | مغاره | مغاره |
| тәрәзә | تره زه | تره زه | تره زه |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Бәхтияр | بختيار |  |  |
| баржа | بارژا |  |  |
| сигез | سكز |  |  |
| сезләр | سزلار |  |  |
| булмаз | بولماز |  |  |

Төп шәкелләре бер төрле булган «син» һәм «шин» хәрефләренең дә язылышлары бер үк. Аларны тиз язу сәбәпле, күпчелек очракларда тешләрен ясап тормыйча, озын сызык рәвешендә генә язу кулланылган. «Син» хәрефенең астына өчәр нокта кую күренеше элекке чорлардан[11] алып XIX гасырга хәтле дәвам иткән. Кайбер кульязмаларда ялгышлык белән хәрефнең өстенә дә, астына да нокталар куелганын күрергә мөмкин. Ә аерым күчерүчеләр протографтагы «син» астындагы өч ноктаны ялгыш «шин» итеп тә кабул иткәннәр. Мәсәлән, «булмасдур» һәм «калмасун» сүзләрен «булмашдур» һәм «калмашун» дип күчергәннәр [90, 207].

Кульязма текстларда «син» белән «шин»не үзләреннән алдарак язылган хәрефләр өстенә язу гадәте киң таралган. Андый үзенчәлек бигрәк тә тартмалап язганда бер үк сүздә булганда да күзәтелә, янәшәдәге бүтән сүзнең хәрефләренә дә менгереп язылган.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| сез | سز |  |  |
| ирсә | ايرسه |  |  |

[11] Астына өч нокта куелган «син» хәрефе X гасырда күчерелгән Коръән китабында ук теркәлгән.

| | | | |
|---|---|---|---|
| ошбу | اوشبو | اوشبو | اوشبو |
| шәнбә (шимбә) | باش | باش | باش |
| сиһшәнбә (сишәмбе) | شنبه | شنبه | شنبه |
| шәһәр | سهشنبه | سهشنبه | سهشنبه |

«Сад» һәм «дад» хәрефләре – бер төрле үк шәкелдә, бары тик «дад»ның өстендә бер ноктасы бар. Әлеге хәреф гарәп телендә «дад» дип аталып, «д» авазын белдерсә дә, татарларда ул каты «з» авазы урынына кулланылган.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульъязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| Садыйк | صادق | صادق | صاص |
| баз | باض | باض | باص |

«Тый» һәм «зый» хәрефләре шулай ук охшаш рәвештә, бары тик икенчесенең өстендә бер ноктасы бар. Татар кульъязмаларында «зый» хәрефен еш кын «дад» хәрефе урынына кулланганнар. Хәтта Мортаза исеменең «дад» белән булырга тиешле дөрес язылышы урынына «зый» язылган очраклар шактый.

Мисал:

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульъязмадагы вариант* | *искәрмә* |
|---|---|---|---|
| Мортаза | مرطاظا | مرطاظ | дөресе مرتضى булырга тиеш |

Татар телендә каты «гъ» авазын белдергән ике «гайн» хәрефенең язылышлары да бер төрле үк, бары тик берсенең

өстендә нокта куелган. Татар кульязмаларында төрки-татар тамырлы сүзләрдә күпчелек очракта өстендә нокталы «гайн» кулланылган. Язма истәлекләрдә иң күп очрый торган «угылы» сүзе гадәттә өстендә нокталы «гайн» хәрефе белән теркәлгән. Ләкин ашыгыч язганда ноктасы куелмыйча калган очраклар шактый.

Бу хәрефләрнең сүз башындагы язылышлары еш кына бозыбрак һәм сүз уртасындагы шәкелләре дә түгәрәкләбрәк язылганга күрә, «фа» хәрефенә охшаган.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| агач | آغاج | آغاج | آغج |
| угылы | اوغلی | اوغلی | اوغلے |

«Фа» хәрефенең төп нигезе «би» һ.б. шундый хәрефләрнекенә охшаш – озынча итеп язылган. Әмма кульязмаларда аны «каф» һәм «нун» хәрефләренә охшатыбрак та язганнар.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| саф | صاف | صاف | صاف |
| нәфис | نفیس | نفیس | نفیس |
| Гариф | عارف | عارف | عارف |

Каты әйтелешле «къ» авазын белдергән «каф» хәрефенең түгәрәк өлеше «фа» хәрефенеке кебек үк. Ә төп шәкеле «дад» һәм «нун» хәрефләренеке шикелле түгәрәгрәк, «фа» кебек озынча түгел. Өстендәге ике ноктасын вертикаль итеп язу да киң кулланылган.

Мисаллар:

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | | *искәрмә* |
|---|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* | |
| кадак | قاداق |  |  | |
| аккош | آققوش |  |  | |
| Казан | قزان |  |  | бу исемдә, гадәттә, икенче «әлиф» хәрефе язылмаган |

Йомшак әйтелешле «к» авазын белдергән «кәф» хәрефенең язылыш рәвешләре үзенчәлекле һәм төрлечәрәк. Төрки-татар сүзләрендә кулланылган «ң» хәрефенең дә һәм күпчелек очракта фарсы сүзләрендәге йомшак «г» авазын белдергән хәреф тә (аны «гәф» дип тә йөрткәннәр) «кәф» хәрефе шәкелендә. «Кәф»нең өске кыйгач сызыгы янәшәсендә параллель сызыкча өстәлгәне «г» хәрефен белдергән. Ә «ң» хәрефе элегрәк «нун» белән «кәф»нең икесен бергә язу рәвешендә, соңрак (XIX гасырдан) «кәф» шәкеленә өч нокта өстәп язылган. Искерәк текстларда «кәф» хәрефенең өстенә бер нокта өстәп кенә белдерелгән варианты да булган. Гомумән, имля тотрыксызлыгы нәтиҗәсендә «ң» һәм «г» хәрефләре урынына еш кына «кәф» язганнар һәм «г» хәрефе урынына «ң» язып та йөртелгән. «Кәф» һәм «ң» хәрефләренең сүз ахырындагы рәвешләрендә һәмзәсыман элементын язганда кулны кәгазьдән аермыйча гына да теркәгәннәр. «Кәф» һәм «әлиф» хәрефләре янәшә килгәндә кулны кәгазьдән аермыйча тоташтырганда сигезле санына охшаш сурәт хасил булган. Татар кульязмаларында «-ның» кушымчасын «н+к» итеп язганда «кәф» хәрефе кайчагында үзенчәлекле кыяфәт алган.

«Кәф»нең өске кыйгач сызыгы урынына һәмзәгә охшаш ишарәсен язу элеккерәк чорга (XVII–XVIII гасырларга) хас булган. Ләкин аны кайчакта XIX гасырда да язганнар. Мәсәлән, 1851 елгы кульязма китап факсимилесендәге «китаб», «кем», «гражданин», «казанский» һ.б. сүзләрдә [92, 50] шундый очраклар күренә.

Шулай ук нәсех язулы текстларда «кәф» хәрефен сузып язу гадәте булган. Озынча итеп язылган «кәф» хәрефе каллиграфиядә «мөсәттах» (яткан) дип аталган.

Кульязмаларда «ң» авазы күпчелек очракта «кәф» (ک) хәрефе белән белдерелгән. Текстны транслитерация ясаган вакытта тел үзенчәлекләре исәпкә алынмаса, шактый буталчыклар туарга мөмкин. Әйтик, гарәп хәрефләре белән язылган сүз турыдан-туры кириллицага күчерелгәндә, «сәңа» сүзенең кульязмадагы ساکه язылышы «сакә» дип, «сәнгә» (سانکا) сүзе «санка» яки «сәнкә» дип, «бәңа» (باکه) сүзе «бакә» яисә «бәкә» дип, «аңа» (آکا) сүзе «ака» яки «әкә» дип бирелергә тиеш булыр иде.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасы күчермәләренең Фазыл Фәсиев тарафыннан хәзерләнгән тасвирларында «-ның» кушымчасының ننک рәвешендәге язылышы турындагы күзәтүенә игътибар итик. Әлеге кушымчаның кайбер кульязмаларда ике ноктасы да «кәф» хәрефе өстенә язылган очраклар булуы искәртелгән [39, 466, 470].

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| кирәк | کراک | کراک | کراک |
| мәктәп | مکتب | مکتب | مکتب |
| аның | آننک | آنک آنک | آنک آنک |
| түгәрәк | توگراک | توگراک | توگرک |

| | | | |
|---|---|---|---|
| камил | كامل | كامل | كامل |
| таң | تانك تاڭ | تانك | تاڭ |
| Гөлҗамал | گلجمال | گلجمال | گلجمال |
| Гөлбикә | گلبيكا | گلبيكا | گلبكا |
| -ның, -нең | ننک | تنك ننك | ننک |
| угылыңыз | اوغلنكز | اوغلنكز | اوغيلڭز |
| Тәбарәк | تبارك | تبارك | |
| мәлик | ملك | ملك | |
| сәнең | سنك | سنڭ | |
| килгәй | كلكاى | كلكاى | كيلكاي |
| кисәк | كساک | كساک | |
| күрсә | كورسا | كورسا | |
| бик | بيک | بيک | بيك |
| җөрдек | جردوک | جردوک | |
| таки | تاكه | تاكه | تاكه |
| тереклек | تركلك | تركلك | |

Югарыда бирелгән мисаллардагы «Тәбарәк» сүзеннән алып «күрсә» дигәнгә кадәрге сүзләр XVII гасыр кулъязмаларыннан алынды.

Хәзерге татар алфавитында каты «къ» һәм йомшак «к» авазлары бер генә хәреф белән белдерелүенә ияреп, гарәп хәрефле иске текстлардагы «каф» белән «кәф»нең аермасына төшенеп җитмәүчеләр бар. Шулай ук хәзерге алфавитта каты «гъ» һәм йомшак «г» авазлары да бер генә хәреф белән белдерелгәнгә, гарәп хәрефле текстлардагы «гайн» белән «г»не бутыйлар.

Гарәп әлифбасындагы «ләм» хәрефе кульязмаларда үзгәрешсез диярлек язылган. «Ләм» белән «әлиф» (ла, лә, ля) хәрефләре янәшә килгәндә, гадәттә, «әлиф» хәрефе үзгәртебрәк язылган һәм үзеннән соң килгән хәрефкә тоташкан.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| мулла | ملا |  |  |
| дамелла | دملا |  |  |
| безләр | بزلار |  |  |
| белән | بلان |  |  |
| булды | بولدى |  |  |
| ел | يل |  |  |

«Мим» хәрефе – кульязмаларда төрлечә язылышларга ия булган хәрефләрнең берсе. Аның нәсех, сөлес һ.б. каллиграфик язу төрләрендә кечкенә тамчысыман теркәлгән өлеше тәгъликъ, нәстәгъликъ, шикәстә, рокъга һ.б. төрләрдә бүтәнчәрәк (сытылган кебегрәк) сурәттә булган.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| бардым | باردم |  |  |
| кызым | قزم |  |  |

| | | | |
|---|---|---|---|
| бирдем | بيردوم |  |  |
| сум | صوم |  |  |
| булдым | بولد وم |  |  |
| килдем | كيلدوم |  |  |
| сүземез | سوزومز |  |  |
| әс-сәлам | السلام |  |  |
| мәгълүм | معلوم |  |  |

«Нун» хәрефе кульязмаларда шулай ук төрлечә теркәлүе белән үзенчәлекле. Аның бу хасияте турыдан-туры гарәп каллиграфиясенең төрләренә бәйле. Аның сүз ахырларындагы язылышын аеруча боргалап, чәчәксыман бизәккә охшатып та язганнар. «Нун» үзеннән соң килгән «җим» шәкелендәге һәм «мим» хәрефләренә тоташканда «би» шәкелле хәрефләр кебек, үзенчәлекле итеп тә язылган. Искәрәк текстларда «нун» хәрефенең ике очы тоташып, түгәрәксыман булып, ноктасын шуның өстенә яисә эченә дә язган очраклар бар. Андый язылыш гарәп каллиграфиясенең дивани төренә хас.

Мисаллар:

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | | *искәрмә* |
|---|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* | |
| мин | مين |  |  | «нун» хәрефе 1 нче вариантта рокъга язуы төрендәгечә, 2 нче вариантта шикәстә төрендәгечә язылган |
| | | | | |
| син | سين |  |  | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| мөэмин | مؤمن | مؤمن | مؤمن | |
| улан | اولان | اولان | اولان | |
| Госман | عثمان | عثمان | عثمان | |
| Локман | لقمان | لقمان | لقمان | |
| көн | كون | كون | كون | 2 нче вариантта «кәф» хәрефенең өске сызыгына «нун» хәрефе тоташкан |
| дин | دين | دين | دين | |
| имән | ايمن | ايمن | ايمن | |
| гомерен<br>бирсен | عمرون<br>بيرسون | عمرون<br>بيرسون | | |
| вирсен | ويرسون | ويرسون | | |
| җиһан | جهان | جهان | جهان | |
| Рахман | رحمان | رحمان | رحمان | |
| Гыйльман | علمان | علمان | علمان | |

«Һа» һәм «ә»не белдергән «һаи рәсмия» кульъязмаларда төрле рәвешләрдә теркәлгән. Бу хәрефнең, гарәп каллиграфиясендәге язылышлары кулланылуы белән бергә, шактый бозылган очраклары да күп.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульъязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| һава | هوا | هوا | هوا |
| бичара | بچاره | بچاره. | بچاره. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Һибәтулла | هبة الله | هبة الله | هبة الله |
| Баһман | بهمان | بهمان | بهمان |
| ки | كه | كه | كه |
| җөмлә | جمله | جمله | جمله |
| әһел | اهل | اهل | اهل |
| әһеле | اهلى | اهلى | اهلى |
| һай | هاى | هاى | هاى |
| бөһтан | بهتان | بهتان | بهتان |
| ниһаять | نهايت | نهايت | نهايت |
| Шиһабеддин | شهاب الدين | شهاب الدين | شهاب الدين |

Сүз уртасындагы һәм ахырындагы язылышлары бер төрле үк булганга, гарәп хәрефле иске текстлар белән эшләүчеләр кайчагында «һ» хәрефен «ә» дип, «ә»не «һ» дип ялгыш кабул итәләр. Мәсәлән, «кинә» сүзен «көнһ» дип, «ганһ» сүзен «ганә» дип тәкъдим итәләр.

Гарәп әлифбасындагы «уау» хәрефенең кульязмаларда зур үзгәрешләре юк. Шулай да, үзеннән соң килгән хәрефләргә тоташтырып язылган очраклары күп. «Уау» хәрефе татарча текстларда *w, у, ү, ө, о* авазларын белдергән.

Элекке чорлардан алып XVIII гасыр ахырына кадәр өрелмә «в» (уау) хәрефе өстенә өч нокта кую күренеше киң кулланылган һәм ул, «фа» хәрефе кебек, еш кына ике ягыннан тоташтырып язылган. Әүвәлге чорлардан алып XVIII гасырның I яртысына хәтле «у» һәм «w» авазларын белдерү өчен «фа» хәрефе язылган очраклар да бар.

Өстендә өч нокта куелган «уау» хәрефен тел галиме Фазыл Фәсиев Алтын Урда чоры ярлыкларына һәм XVI–XIX гасырлардагы Идел буе-Касыйм текстларына хас үзенчәлек дип искәрткән.

«Уау»ның өстенә өч нокта куеп язу XIX гасырда шактый кимегән. Аны шул гасырның соңгы чирегендә рус һәм һәм Европа телләреннән кергән алынма сүзләрдәге «в» авазын белдерү өчен куллана башлаганнар һәм ул XX гасырда да дәвам иткән. «Уау»ның өстендәге өч ноктасын язганда кулны кәгазьдән аермыйча гына да теркәгәннәр.

Сүз башында «әлиф» һәм «уау» хәрефләре икесе янәшә язылганда *у, ү, ө, о* авазларын белдергәннәр. Сүзнең эчендә һәм ахырында бу хәреф *ы, е* авазларын белдерү өчен язылган.

Мисаллар:

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кулъязмалардагы вариантлары* | | *искәрмә* |
|---|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* | |
| угыл | اوغول | اوغول | اوغول | |
| куйдым | قويدوم | قويدوم | قيدم | |
| салдым | صالدوم | صالدوم | صالدم | |
| явыз | يۋوز | يۋوز | يقوز | XVII–XVIII гасырларда |
| явып | يۋوب | يۋوب | يقوب | XVII гасырда |
| яулак | ياولاق | يۋلاق | يقلاق | XVII гасырда |
| ауга | آوغا | آۋغا | آقغ | XVII гасырда |
| түә (дөя) | توه | تۋا | تقا | XVII гасырда |
| дәйү | ديو | ديۋ | ديق | 2 нче вариантта өч нокта шул рәвешле белдерелгән |
| су (сыв) | سو | سۋ | سف | ике вариант та XVII гасырның бер үк текстында язылган |

Гарәп әлифбасындагы «йа» хәрефенең сүз башында һәм уртасындагы язылышлары «би» шәкелендәге хәрефләр кебек үк. Ләкин сүзнең ахырында ул бүтәнчә язылган. Аның астында ике нокта куелган. Бу хәреф *и, й, ы* авазларын белдергән.

«Йа» хәрефе язылу юнәлеше буенча кире якка (уңга) борылган рәвештә бик күп кулланылган. Хәрефнең әлегечә язылышын каллиграфиядә «йа-и мәгъкүс» (кирегә караган «йа») яки «йа-и сәйфи» (кылычсыман «йа») дип атаганнар. Каләмнең кәгазьгә төртелмичә шомарак язылуы өчен дә мондый язылыш кулайрак күрелгән.

Гарәп телендәге сүзләрнең ахырларындагы «йа» хәрефенең астына, гадәттә, икешәр нокта куелган. Ә XVI–XVII гасырлардагы татар кулъязмаларында төрки-татар һәм фарсы сүзләренең ахырындагы «йа» хәрефе астында да (гадәти һәм кирегә борылган язылышларында) күпчелек очракта ике нокта куелган. Бу хәреф астындагы нокталар XVIII гасырның беренче яртысында шактый, ә шул ук гасырның икенче яртысына караган текстларда сирәгрәк күренә.

Элеккерәк текстларда – кулъязмаларда һәм кабер ташларында «й» (кыска и) авазы ноктасыз гына «и» сыман хәреф билгесе белән белдерелгән. Аның мисалларын бу китаптагы «Сиражел-колүб» тексты үрнәкләрендә күрергә мөмкин (мәсәлән, «куйды» сүзе). Дөрес, әлеге текстны күчергән кеше башка сүзләрдә дә ялгышлык белән шундый ук хәреф элементын артык язган урыннары да бар («андаг», «анлар», «мондин» сүзләрендә). Мөхәммәдьяр әсәрләренең күчермәләрендә һәм башка кайбер иске текстлардагы аерым сүзләрдә «кыска и» шундый ук билге-хәреф белән язылган. Андый язылыш XVII гасыр татар кулъязмаларында да теркәлгән. XVI гасырның беренче яртысы татар кабер ташларындагы «аенда» сүзе, гадәттә, шундый рәвештә – آیندا дип язылган. Менә шул ноктасыз бер хәреф элементы булуы сәбәпле, элекке ташъязмаларны укыганда «аенда»

сүзен кеше исеме «Әсәд» [31, 68–71, 74–75] дип ялгыш танучылар булган.

Сүз башындагы «и» хәрефенең ئـيـ сурәтендә язылуы 1920 нче елларда кабул ителгән татар орфографиясенә хас икәнлеге билгеле. Ләкин шундый ук язылыш иске кульязмаларда – XVIII гасыр истәлекләрендә (мәсәлән, ئيدى (иде) сүзе «Кыз хикәяте» текстының күчермәләрендә) дә бар.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылыш* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | |
|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* |
| ике | ایکی |  |  |
| керде | کردی |  |  |
| ир | ایر |  |  |
| каты | قاطی |  |  |

Гарәпчә язылыштагы «йа» хәрефен хәзерге татар графикасына күчергәндә сүзенә күрә «и, ы, е» хәрефләре белән бирмичә, бары тик «ый» дип кенә тәкъдим итүче текстологлар хаксыз икәнлеген дә искәртик. Мәсәлән, ялгыш итеп бирелгән «кыйлдыйкыймыз» кебек сүзне әйтеп-укып бетерергә дә читен. Китапның III бүлегендә «ый» дип бирелгән башка мисаллар да бар.

Гарәп язуындагы һәмзә билгесенең кульязмаларда теркәлешендә зур аерма юк. Бары тик бик ашыгыч язылганда ул зигзагсыман рәвештә булырга мөмкин.

Рус һәм Европа телләреннән кергән алынма сүзләрдәге «ц» һәм «щ» авазлары гарәп хәрефле текстларда, гадәттә, «тс» һәм «шч» рәвешләрендә язылган.

Белорус татарларының гарәп хәрефләре белән язылган иске кульязма истәлекләрендә кайбер хәрефләрнең язылышлары һәм хәрәкәләр кулланылышы аерым үзлекләргә

ия. Иске татар палеографик үзенчәлекләренең кайберләрен гарәп язуындагы хәзерге уйгур орфографиясендә дә күрергә мөмкин.

Бу бүлекчәдә гарәп хәрефләренең аерым сүзләрдәге язылыш вариантлары күрсәтелде. Аларның аңлатма-искәрмәләренә зур игътибар биреп, хәтердә калдырырга тырышу тиешле. Югыйсә, мисал итеп күрсәтелгән сүзләрне җөмләләр һәм текстлар эчендә җайлы гына тану бик үк җиңел булмас. Кульязма текстларның башка күптөрле үзенчәлекләре (мәсәлән, хәрефләрнең бер-берсенә охшашлыклары, аларны бер-берсе өстенә урнаштырган хәлдә сүзләрне тартмалап, кысынкы һәм вак итеп бирү) бергә кушылганда, серле йомгак җебен җае белән сүтеп-аңлап уку зур түземлек таләп итә.

Кайбер белгечләр гарәп язуының элементар палеографик үзенчәлекләрен төшенеп җитмәгәнлектән, шактый тупас хаталар җибәргәлиләр. Татар кабер ташларындагы язмаларны өйрәнүче А.Гайнетдиновның шундый ялгышларына махсус тукталганыбыз булды [88, 38]. Аларның кайберләрен монда да искә алу зыян итмәс, гарәп язулы чыганаклар белән эш итүчеләр андый хаталарны кабатламасыннар иде. Мәсәлән, исеме күрсәтелгән белгечнең гарәп палеографиясендәге сүз ахырларында кирегә борып язылган (кылычсыман) «йа» («йа-и мәгъкүс», «йа-и сәйфи») хәрефен белмәве-аңламавы Арча, Әтнә районнарындагы татар эпиграфик истәлекләренә багышланган һ.б. хезмәтләрендә ачык күренә. Ягъни, ташъязма текстларында бик күп кабатланган «-нче», «-нчы» кушымчалары «-нч» «-нҗ» рәвешендә бирелгән, «язгучы» сүзе дә «язгуч» дип тәкъдим ителгән. «Дәл» хәрефенә «ә» хәрефе ялгануын да шул ук авторның нәрсә икәнлеген төшенмәгәнлеге күренә. Чөнки аның китапларында «-ндә» урынына «-нд» дип бирелгән урыннар аз түгел (мәсәлән, *яшенд; йылд; 24 нд; үктәберд; көненд*).

Иске текстлар белән эшләүчеләрнең аерым сүзләрдәге гарәп һәм фарсы орфографиясенә хас үзенчәлекләрне белеп җиткермәгәнлектән җибәргән хаталарын да искәртик. Мәсәлән, бер төркем сүзләр һәм кеше исемнәре ахырларында кыска ә (а) авазын белдергән «әлиф мәкъсура» астында ноктасыз «йа» хәрефе белән язылган. Шундый язылышлардан مولی مرتضی مصطفی (Мостафа, Мортаза, Мәүла) исемнәрен ялгыш итеп *Мостафи, Мортази, Мәүли* дип танып, китап һәм мәкаләләрдә бастыручылар бар. Фарсы теленнән кергән алынма сүзләрдәге «ки» кисәкчәсенең икенче хәрефе гарәби текстларда «ә» белән язылса да, «и» дип укылырга тиешле икәнлеген дә хәтергә төшерик. Югыйсә, گویاکه چونکه بلکه یاکه (яки, бәлки, чөнки, гүяки) сүзләрен *якә, бәлкә, чөнкә, гүякә* дип ялгыш танучылар аз түгел. خواجه خوارزم (Хәрәзем, Хуҗа) атамаларын Хвәрәзем, Хваҗә (хуаҗә) дип тәкъдим итүләр дә булгалап тора.

## Хәрәкәләр һәм тәнвиннәр

Хәрәкәләр, нигездә, гарәп телендәге Коръән текстларында кулланылган. Сузык авазларны (*ә, и, у*) белдерү өчен гарәп хәрефләренең өсләрендә һәм асларында куелган билгеләр – хәрәкәләр VIII гасыр урталарында барлыкка килгән дип яза галимнәр [85, 113]. Гарәпләрдән башка мөселман халыклары Коръәнне дөрес укысыннар өчен IX–X гасырларда махсус хәрәкә билгеләре кулланылышка кертелгән. Башлангыч чорда алар төп тексттан аермалы – бүтән төстәге кара белән язылганнар.

Татар кульязмаларында исә гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнүгә багышланган дәреслек текстларында һәм аерым сүзләрнең, географик атамаларның һәм кеше исемнәренең дөрес укылышларын тәэмин итү өчен хәрәкәләр куелган. Кеше исемнәреннән, мәсәлән, төрлечә укылуы мөмкин булган **زبیر** (Зәбир, Зөбәер), **سرور** (Сәрвәр, Сорур) кебекләрне әй-

тергә мөмкин. Төрки-татар телендәге борынгы шигъри әсәрләрнең текстлары дөрес укылсыннар өчен тулаем хәрәкәләр белән язылган. Моның шулай икәнлеген XIII–XVI гасырларда иҗат ителгән әсәрләрнең соңгырак – XVIII–XIX гасырлардагы күчермәләренең дә өлешчә хәрәкәләр белән язылган булуы раслый. XVII гасыр авторларының да кайбер әсәрләрендә хәрәкәләр кулланылган.

Болардан тыш, элекке төрки-татарча текстларда кайбер кушымчалардагы һәм сүз ахырларындагы хәрефләрнең *-ан (-ән), -ин, -ун (-үн)* рәвешендәге тәнвиннәр (өстәмә билгеләр) белән язылышы да булган.

Идел буе Болгар дәүләте чорындагы шагыйрь Кол Гали тарафыннан 1233 елда иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» әсәренең XVII гасырдан элеккерәк кулъязмалары сакланмаган, әле ул гасырныкылары да санаулы һәм фрагментар гына. XVII һәм XVIII гасыр күчермәләрендә хәрәкәләр (шул исәптән, тәнвиннәр) күбрәк кулланылган булуы күренә. Иҗат ителгән вакытлары элеккегерәк әсәрләрдән мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасының XVII–XIX гасырлардагы күчермә нөсхәләрендә тәнвиннәр булуы – әлеге әсәрнең автор варианты ук берникадәр күләмдә хәрәкәләр кулланып язылганын дәлилли. Чөнки әсәр текстының төрле нөсхәләрендәге тәнвиннәр язылышы күчерүчеләр генә уйлап чыгарган әйбер түгел.

«Кыйссаи Йосыф» күчермәләрендә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр кулланылган булуы әсәрнең 1983 елгы кулъязма тасвирламаларында да күрсәтелгән [39, 441, 442, 447, 464, 478]. Бу мәсьәләне «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары тасвирламасында без дә язган идек [42, 9, 13–20, 24, 26, 30, 34, 47, 50, 55, 58, 60, 62]. «Татар археографиясе» сериясе басмаларының беренче тышлык битендә «Кыйссаи Йосыф»ның XVII гасыр күчермәсеннән бирелгән фотода ук مفستدًا نفسٍ مانع قلسٌ امدى

(Мөфситд(*əн*) нəфс(*ин*) манигъ кылс(*ун*) эмди) дигəн бер юл эчендə генə өч тəнвин кулланылган булуы күренə. «Кыйссаи Йосыф» күчермəлəрендə күп очрый торган «бəн» һəм «сəн» сүзлəре дə тəнвинле итеп – بًا һəм سًا рəвешлəрендə язылган[12].

Иҗат ителгəн вакыты белəн Йосыф турындагы кыйссадан өч гасыр чамасы соңгырак «Кыз хикəяте» текстының XVIII гасыр ахырындагы күчермəсендə дə тəнвиннəр барлыгын күрəбез [41, 35]. Анда сүз ахырындагы «ан», «əн» кушымчалары урынына тəнвиннəр язылган сүзлəр очрый. Мəсəлəн, «бəн» сүзе بًا, «сəндəн» сүзе سندًا рəвешендə язылганнар [41, 35, 97].

XVII гасырның соңгы чирегендə күчерелгəн дастанда исə кайбер сүзлəрнең язылышы тəнвин билгесе куелмыйча гына теркəлгəн. Мəсəлəн, «пəйгамбəрлəрдə(н)», «мəшрикъдə(н)», «йылда(н)» сүзлəренең ахырларындагы «н» хəрефлəре текстта булмавын чагыштырмача хатасыз күчерелгəн дастан текстында «нун» хəрефлəре төшеп калган дип кенə фаразларга җирлек юк [29, 35–36].

XIX гасырдагы алыш-биреш язмаларында да кайбер сүзлəрдə тəнвин кулланылган очраклар булуы кызыклы күренеш. Мəсəлəн, 1824–1825 еллардагы документларда «угылынд(ан)» [38, 97, 99] дип теркəлгəн мисалларга юлыккан идек. Моңа охшаш үзенчəлекнең гадəти һəм көндəлек язуларда кулланылуына элекке текстлар тəэсир иткəндер, күрəсең.

---

[12] Тəнвиннəр иң күп кулланылып язылган, шулай ук башка палеографик үзенчəлеклəргə ия «Кыйссаи Йосыф» əсəренең күчермəлəре, кызганыч ки, Рəшит Кадыйровның хезмəтендə бөтенлəй искə алынмаган. Гəрчə XIII–XVIII гасырлардагы палеография хосусиятлəренə багышланган махсус фəнни тикшеренү эшенə хронологик яктан да туры килə торган һəм иҗат ителгəн датасы төгəл билгеле язма əдəбият истəлеге турында тəҗрибəле белгечнең фикерлəре бик файдалы булыр иде. Кадыйров диссертациясенең фəкать бер урынында – 34 нче битендə XI–XIII гасырлардагы болгар авторлары (барлыгы 7 кеше) исемнəре арасында Кол Гали исеме аталган һəм шуннан башка үзе дə, əсəре дə бүтəн телгə алынмаган.

XIV гасырда Сәйф Сараи иҗат иткән «Гөлстан биттөрки» әсәренең текстында да хәрәкәләр күп кулланылган [69].

Болгар ташларында сүз ахырындагы соңгы иҗектә «йа» хәрефе урынына «и» авазын белдерә торган «кәсрә» хәрәкәсе генә куелганлыгы уңаеннан (мәсәлән, أوِل – улы) Р. Кадыйров андый күренешнең, гомумән, борынгы язмачылыкка хас булганын әйтә [36, 65]. Димәк, ахыргы иҗекләрдә «кәсрә» куллану – кыска авазны белдергән, ә وی һәм وا рәвешле язылышлар авазның озын икәнлеген белдерү өчен кулланылган.

Кадыйров шулай ук иске төрек язмаларында (мәсәлән, XIV гасырда) төрки сүзләрдә хәрәкәләр еш кулланылган дип искәртә.

Иҗат ителгән вакытлары белән бер үк чордагы әсәрләр кулъязмаларында – XVI гасырдагы «Гыйлем Хакка илтер» текстының күпчелек сүзләрендә хәрәкәләр куелган, ә «Кыйссаи Мансур» әсәрендә, Түләк дастанында, Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Нуры содур» поэмасының XVIII гасыр күчермәләрендә хәрәкәләр аерым сүзләрдә генә бар [61, 92–109; 62, 121; 79, 17; 59, 124].

«Чыңгызнамә» исеме белән берләшкән дастаннарның текстларында да хәрәкәләр кулланылган. 1727 елгы күчермәсендә алар аеруча күп, шулай ук башкаларында да күренә [90, 117]. 1732 елгы күчермәсендәге кайбер сүзләрдә хәрәкәләр кулланылган.

Искерәк текстлардагы хәрәкәләрнең күчерүчеләр тарафыннан аерым очракларда хәреф дип ялгыш кабул ителгән мисаллары да билгеле. Мәсәлән, «сәкен» хәрәкәсе, күчерүче тарафыннан хәрефнең өстендә язылсы урында, кайбер сүзләрнең ахырларында хәрефләр белән бер рәттә «ә» яисә «һ» хәрефе кебек язылган. Шул сәбәпле, тексттагы «ирер, үр, тәбигъ» сүзләре «ирерә, үрә, тәбигъә» дип, сузык хәрефкә беткән сүзләрдә исә «һ» буларак – «көнгә, таба»

сүзләре «көнгәһ, табаһ» [90, 90] рәвешендә язылган. «Кыз хикәяте» күчермәсендә шундый ук күренеш – 165 бәйтнең ахыргы сүзләре булган «әшикяр» һәм «көффар» сүзләренең соңгы хәрефләре өстенә куелган «сәкен» хәрәкәләре кулъязмада түбәнгәрәк, аерым хәреф кебек язылып, «әшикярә» һәм «көффарә» дип укылырлык рәвештә, ялгыш язылганнар [41, 66].

«Кыз хикәяте» кулъязмасындагы «күрде» сүзенең كردى, «кәсүче иде» сүзенең كسجدى, «эдүбән» сүзенең ادبن рәвешләрендә, ягъни сузык авазларны белдергән хәрефләрдән башка гына язылганлыгы һәм боларга охшаш язылышларның тагын да очравы – әлеге әсәр тексты башлангыч чорда, гомумән, хәрәкәләр куелып язылган булгандыр дигән фикергә этәрә. Кулъязма тексттагы байтак кына сүзләрнең ахырларында сузык авазларны белдергән «ә, е, и, ы» хәрефләренең бөтенләй язылмыйча калган булуын да күчерүче хатасы дип уйлау дөрес булмас. Чынлыкта, ул сүзләр элеккерәк кулъязмаларда хәрәкә белән белдерелгән булганнардыр.

«Кыйссаи Мансур» күчермәләренә хас грамматик үзенчәлекләрдән кайбер очракларда «а» авазын белдергән әлиф хәрефе, язылырга тиеш булып та, төшерелеп калдырылган. Мәсәлән, «калмады» сүзе قلمادى , «варырым» сүзе وروزم дип язылган. Шуңа охшаш күренеш «у» һәм «и» хәрефләрен төшереп калдыруда да очрый. Ягъни, алар да язылмыйча калган урыннар бар. Мәсәлән, «тулды» сүзе طلدى, «сүзем» – سزم, кач – قج , һич – هج. Соңгы ике сүздәгечә «ч» урынына «җ» хәрефен язу күренеше текстларда да шактый күп. Гомумән, ч/җ (һич = һиҗ, ачылды = аҗылды), б/п (йеб = эп, һәб = һәп), т/д (ишет = ишед, йегет = йегед), с/з, къ/гъ (тупрак = тупраг), к/ң кебек хәрефләрне язгандагы орфографик тотрыксызлык татар кулъязма истәлекләренә хас.

Мәүла Колый поэмаларының 1754 елгы күчермәсендә кайбер сүзләр шулай ук хәрәкәләр белән язылган. Бигрәк тә,

«заммә» һәм «сәкен» куелган. Мәсәлән, «Береккәннәр сыйфаты» поэмасының 45 нче бәйтендә Заһид исеменең соңгы хәрефе өстендәге «сәкен» сүз ахырындагы тагын бер хәреф рәвешендә язылганлыктан, «Заһидә» [53, 64]дип укылу ихтималы бар. Әмма бу очракта аның Заһид буларак укылышы бәхәссез.

Мәүла Колый поэмаларының кулъязма текстында төрки тамырлы сүзләрдә бер төрле үк тартык хәрефләр икешәр мәртәбә язылырга тиеш булган очракларда (кайтты, китмәклеккә, үттеләр, берлеккә һ.б.) берәр хәреф кенә язылган. Мондый очракта әсәрләрнең башлангыч вакытында бер төрле тартыклар кабатланганны белдерү өчен икеләтү билгесе – «тәшдид» хәрәкәсе куелган булса кирәк яки, гомумән, тәшдид үзе язылмаса да, аның барлыгы күздә тотылган имля үзенчәлеге гамәлдә булган дияргә мөмкин. Мондый күренеш башка текстларда да бар [79, 17; 59, 124; 62, 26; 41, 33; 61, 109; 29, 35], шулай ук XVI–XVII гасырлардагы кабер ташларында да очрый. «Кыйссаи Мансур» текстларында да جهانک (җиһанның), خلقه (халыкка), ایله (иллә) һ.б. язылышлар бар [62, 26]. Шундый ук язылышлар «Кыз хикәяте» күчермәсендә дә теркәлгән [41, 33].

«Дастане җайә»нең текстындагы төрки-татар сүзләрендә берникадәр хәрәкәләр куелган, шулай ук элек әлеге әсәр текстында хәрәкәләр белән язылган булып, XVII гасыр күчермәсендә алар куелмаганлыгына ишарә итә торган сүзләре бар [29, 36].

Тасвирлап үтелгәннәрдән күренгәнчә, элекке чор төрки-татар кулъязмаларында хәрәкәләр һәм тәнвиннәр киң кулланылган.

Татарча шигъри текстларда хәрәкәләр куллану XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында (хәтта 1920 нче елларда) да кулланылган очраклар бар. Мәсәлән, Нигъмәтулла Солтанбәков (1841–1928) үзенең һәм бабасы – шагыйрь Колмөхәммәтнең әсәрләрен укучыларга аңлаешлы булсын өчен хәрәкәләр кулланып язган [66а, 36].

## Исем-фамилияләр

Татар кулъязмаларында очрый торган бик күп төрле кеше исемнәренең язылыш үзенчәлекләренә аерым тукталмыйбыз. Аларның беразы бу китаптагы мисалларда да күренә. Әгарәп теленнән кергән исемнәрнең төп хасиятләреннән берсе – гарәп әлифбасындагы «ай» һәм «кояш» хәрефләренең язылыш һәм укылыш кагыйдәләренә бәйле.

Кулъязмаларда сирәк булса да фамилияләр язылган очракларны да күрергә мөмкин. XX гасыр башында инде алар шактый. Алардагы «-ов, -ев, -ин» һәм рус фамилияләрендәге «-ский» кушымчалары төрлечә язылган булырга мөмкин. Ир-ат фамилияләренең ахырындагы «в» хәрефе урынына бөтен очракта да диярлек «ф» язылган, ә хатын-кыз фамилияләрендә өстендә өч нокталы «в» (яки «уау» хәрефе) белән әлиф теркәлгән.

Мисаллар:

| *хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кулъязмалардагы вариантлары* | | *искәрмә* |
|---|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* | |
| Галиев | عليیف | علیيف | علی اوف | «-ев» кушымчасы төп сүздән аерым язылган |
| Вәлиев | وليیف | ولیوف | ولی اوف | |
| Хәкимова | حكيموۋا | حكيموا | حكيموۋا | |
| Шәрипова | شريپوۋا | شريپوا | شريپوۋا | |
| Волконский | ۋولكونسكی | ۋولكونسكی | ۋولكون اسكی | «-ский» кушымчасы төп тамырдан аерып, «эски» дип язылган |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Гайнуллин | عيناللين | عين اللين | عين الله اين | 2 нче очракта «-ин» кушымчасы төп тамырдан аерып язылган |
| Вәлиуллин | وليللين | ولي اللين | وليواللين | |
| Дивиев | ديوييف | ديويوف | ديوى اوف | |
| Солтанов | سلطانف | سلطانف | سلطان اوف | |

Фамилияләрнең язылышларындагы төрле вариантларга мисаллар күп китерергә мөмкин. Аларның күпчелеге югарыда язылганча рәвештә. Шулай да, «Дивиев» кебек фамилияләрнең язылышлары дөрес итеп уку өчен читен. Ә гарәп теленең төп орфография кагыйдәләрен белеп бетермәүче кайбер текстологларның моннан 20 еллап элек «Шәһри Казан» газетасында Гайнуллин һәм Зәйнуллин кебек фамилияләрне «Гиналлин» һәм «Зиналлин» дип бирүе – кызык та, кызганыч та бер күренеш иде.

## Саннар

Гарәп саннары түбәндәгечә:

1 – ١ , 2 – ٢ , 3 – ٣ , 4 – ٤ ۴ , 5 – ٥ ه ل , 6 – ٦ , 7 – ٧ , 8 – ٨, 9 – ٩ , 0 – ٠ ٥ .

Болар арасыннан 4, 5, 0 саннарының берничә төрле язылышы бар. 5 һәм 0 саннарының түгәрәк шәкелдәге язылышлары бер-берсенә бик охшаш булганга, текстлар белән эшләгәндә аеруча игътибар зарур. 6 цифры татар язма чыганакларында еш кына һәмзәгә охшаш итеп ۶ рәвешле язылган. Кайбер язмаларда 2 саны ۲ һәм 3 саны ۳ сурәтләрендә теркәлгән.

Билгеле булганча, күп урында гарәп саннары султан-

уңга таба юнәлештә, ә кайчакларда исә уңнан-сулга да язылган. Мәсәлән, 84 – ٨٤ , 137 – ١٣٧ , 1925 – ١٩٢٥ , 2024 – ۴۲۰۲ .

Саннарны хәрефләр белән белдерү ысулы (әбҗәд) татар кулъязмаларында шактый киң кулланылган. Нинди хәреф кайсы санны белдергәнлеге турындагы мәгълүмат башка хезмәтләрдә аңлатып язылганлыктан, монда кабатлап тормыйбыз.

Иске кулъязмаларда саннарның цифрлар белән язылышларында тотрыклы кагыйдә булмаган. Гомумән, саннар язылышы һәм аларның кулланылышы мәктәп-мәдрәсәләрдә тәртипле һәм нигезле итеп өйрәтелмәгән. Бу турыда Ризаэтдин Фәхретдин ачык итеп язып калдырган. Ул муллалар тутырган метрикаларда никахлашучы пар кызына 17 һәм егеткә 19 яшь дип теркәгәндә саннарны 107 һәм 109, мәһәр күләмен исә 150 сум диясе урында 10050 рәвешләрендә язылганын мисал итеп китергән. Шулай ук саннарның бозык сурәттә теркәлүләрен дә искәрткән. Казан шәһәрендәге мәдрәсәләрдә, ихтимал, саннар өйрәтелгәндер, ләкин авыллардагы мәдрәсәләрдә ул булмады, дип язган [84, 560].

Кулъязмаларда Р.Фәхретдин күрсәткән рәвештәге язылышлар бик күп очрый. Мәсәлән, 1815 датасының 18015 рәвешендә теркәлгәнен моңарчы басылып чыккан кулъязма факсимилесендә дә күрергә мөмкин [38, 81].

Милли китапханәдә саклана торган «Тәргыйбес-саләт» исемле кулъязма китапның (саклану шифры «8611т») күчерелгән датасы һиҗри 1225 елда дип күрсәтеләсе урында 102025 дип теркәлгән (125б кәгазь). Шул ук китапның күчергән кешесе тарафыннан куелган бит саннары да 88 урынына 808, 93 урынына 903, 114 битеннән алып 122 биткә кадәрге пагинациясе 1014–10202 рәвешендә куелган. Гомумән, саннарны бу рәвештә язу күренеше кулъязмаларда, шулай ук иске кабер ташларында аз түгел.

Элеккерәк чор текстларында саннарны һәм даталарны сүзләр белән язу күбрәк гамәлдә булган. Кулъязмалар-

да тәртип саннарын сүзләр белән язганда палеографик үзенчәлекләр шактый очрый. Мәсәлән, 1357 елда Мәхмүд Болгари иҗат иткән «Нәһҗел-фәрадис» әсәренең бүлек атамаларында «икинч, учинч, төртинч, бәшинч» [3, 382] һ.б. рәвештәге язылышлары шундыйлардан. Саннарның мондый рәвештә язылуы Орхон-Енисей ташларында һәм уйгурча истәлекләргә теркәлгән. Әмма XIII–XIV гасырлардагы болгар кабер ташларында юк [78, 29]. «Нәһҗел-фәрадис» текстында, күрәсең, иске язма телгә хас борынгылык-архаизм чагылыш тапкан дип гөманларга кала. Үзебез исә, 1420 елда татар сугышчысына куелган кабер ташында айның егерменче көнен белдергән «йикерминч» [89, 16] дип уелган мисал очраткан идек. Моны да шундый ук архаизм күренеше дип уйлыйбыз.

Саннардагы кушымчаларның шундый рәвештәге язылышлары 1554 елгы «Сиражел-колүб» текстында да бар: *беренч, икинч, өчүнч, түртүнч, бишинч, алтынч, йитенч, тукузынч, утузынч, утуз беренч* һ.б. дип язылган саннар бар. Шул ук текстта *бишенче, алтынчы, йитенче, сикезенче* дигән вариантлар да теркәлгән. Бу исә – «-нч» кушымчалы беренче төркемнең язма телгә хас архаизм күренеше булганлыгын, шуның белән берлектә, «Сиражел-колүб» әсәре дә «Нәһҗел-фәрадис» белән бер чорда – XIV гасырда төрки-татарчага тәрҗемә ителгәндер дип фаразларга бер нигез булып тора. Казан ханлыгы чоры әдибе Мөхәммәдьяр иҗат иткән поэмаларның күчермәләрендә һәм XVI гасырдагы татар эпиграфик истәлекләрендә «-нч» рәвешендәге кушымчалы саннар теркәлмәгәнлеге дә фаразыбызны куәтли. Димәк, «Сиражел-колүб»нең тәрҗемәсе XVI гасырда башкарылса, андый архаизм мисаллары кулланылмас иде.

## Палеографик үзенчәлек мисаллары

«Сиражел-колүб» (1554 ел)[13]

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмада* |
|---|---|---|
| булгай | بولغای | بولغا بولغا |
| ирде | ایردی | ایردی ایردی |
| мигъраж | معراج | معراج |
| синең | سیننک | سینک |
| өчен | اوچون | اوجون |
| көн | كون | كون كون |
| баш | باش | باش |
| төн | تون | تون |
| кайчан | قجان | قجان |
| фәрман | فرمان | فرمان |
| Тәңре | تنكری | تنكری |
| Илаһи | آلهی | آلهی |
| Сөбханәһә | سبحانه | سبحانه |
| Мәүля | مولی | مولی مولی |
| Җәлялиһи | جلا له | جلاله |
| икинч | ایکنج | ایکنج |
| бишенче | بشنچی | بشنجی |
| йитинч | یتنج | یتنج |

[13] Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклана торган кульязмадан (Мәскәү, 181 фонд, 16 тасвир, 1468 саклану берәмлеге).

| | | |
|---|---|---|
| ирсә | ایرسا | ایرسا |
| тәкый | تقی | تقی |
| кичмеш | کیجمش | کیجمیش |
| эчендә | ایجنده | ایجنده |
| кирәк (кәрәк) | کراک | کراک |
| яратты | یراتتی | برآتی یراتتی |
| пәриләрне | پری‌لارنی | پری لارنی |
| хәдис | حدیث | حدیث |
| кургашын | قورغاشون | قورغاشون |
| акты | اقتی | اقتی |
| тәсбих | تسبیح | تسبح |
| тәсбихе | تسبیحی | تسبیحی |
| ады | آدی | آدی |
| андаг | انداغ | انداغ |
| агыз | آغز | آغز |
| курыкмыш | قوروقمش | قوروقمیش |
| нидин | نیدین | یاصرین ندین |
| кызыл | قزیل | قزیل |
| еллык | یللق | یلّق |
| әйтсә | ایتسا | ایتسا |
| кылмас | قلماس | قلماس |
| янә | ینا | یَنَا |
| оҗмах | اوجماخ | اوجماخ |

| | | |
|---|---|---|
| анлар | انلار | انلار |
| мәлгунь | ملعون | ملعوة |
| хакы | حقي | حقي |
| мондин | موندين | موندين |
| җавап | جواب | جواب |
| язылды | يازلدي | يزلدي |
| эчсәм | ايچسام | ايچسام |



*«Сираҗел-колүб» әсәренең 1554 елгы күчермәсе*
*(Россия дәүләт борынгы актлар архивы)*



*Кол Гобәйди хикмәтләренең XVII гасыр күчермәсе (Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

## XVII гасыр кульъязмаларыннан

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульъязмада* |
|---|---|---|
| аның | آننک | اننك |
| андин | آندين | اندين |
| бере | برى | بري |
| өчен | اوچون | اوچون |
| сәнгә | سنكا | سنكا |



*«Дастане җәйдә»нең XVII гасыр күчермәсе*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

| | | |
|---|---|---|
| хадим | خادم | خادم |
| бар | بار | بار |
| Дарес-сәлам | دارالسلام | دارالسلام |
| Ишбулат | اشبولاط | اشبولاط |
| берлә | برلا | برلا |
| ягыны | یاغینی | یاغنی |
| суыклык | سووقلق | سقوق لیق |
| әмма | اما | اما |
| заманында | زماننده | زماننده |
| ирсә | ایرسه ایرسا ارسا | ایرسا ایرسه ارسا |
| Хак | حق | حق |
| кыйлды | قیلدی | قیلدی |
| кыйлгай | قیلغای | قیلغای |
| әгъләм | اعلم | اعلم |
| хәреб | حرب | حرب |
| улды | اولدی | اولدی |
| имди | ایمدی | ایمدی ایمدی |
| ягъни | یعنی | یعنی |
| Тәгалә | تعالی | تعالی |
| ул | اول | اول |
| сорды | سوردی | سوردی |
| әйде | ایدی | ایدی |



*Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы.*
*XVIII гасыр уртасындагы күчермә*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

| | | |
|---|---|---|
| тиде | تيدى | تيدى |
| жаным | جانوم | جانوم |
| күңел | كوكل | كوكل |
| мәдәд | مدد | مدد |
| дуст | دوست | دوست |
| кыйлсам | قيلسام | قيلسم |

## «Нуры содур» (XVIII гасыр уртасы)[14]

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульъязмада* |
|---|---|---|
| Гали | على | على |
| гомер | عمر | عمر |
| солтан | سلطان | سلطان |
| эчрә | اچره اچرا | اچره اچرا |
| диде | ديدى | ديدى |
| су | سوۋ | سڤو |
| Тәгалә | تعالى | تعا تعا تفا |
| бел | بيل | پيل |
| пәйгамбәр | پيغمبر | پيغمبر |
| эчте | اچتى | اچتى |
| кем | كم | كم |

[14] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «8667т» шифры белән саклана торган кульъязмадан.




*Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәре. XVIII гасыр күчермәсе (Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

| | | |
|---|---|---|
| могтәбәр | معتبر | معتبر |
| җан | جان | جان |
| дога | دعا | دعا |
| сәгать | ساعت | ساعت ساعت |
| берлә | برلا | برلا |
| ирсә | ايرسا | ايرسا |
| чөн | چون | چون |
| гафу | عفو | عفو |
| җиһан | جهان | جهان |
| йите | يتى | يتى |
| ахирәт | آخرت | آخرت |
| камуг | قموغ | قموغ |
| бәян | بيان | بيان |
| әйде | ايدى | ايدى |
| белдем | بيلديم | بيلديم |

## XVIII гасыр

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кулъязмада* |
|---|---|---|
| ул | اول | اُل |
| каму | قامو | قامُ |
| шул ук дәм | شولوق دم | شلقدم |
| күрекле иде | كوركلى ئيدى | كوركلى ئدى |
| мохтаҗы | محتاجى | محتاجِ |

| | | |
|---|---|---|
| морады | مرادی | مُرادِ |
| сиксән | سکسان | سکسن |
| шөбһә | شبهه | شب |
| ни | نی | نی |



*Мәүла Колый поэмасының 1754 елгы күчермәсе*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

| | | |
|---|---|---|
| иде | ایدی | ایدی |
| һәр | هر | هر |
| һәм | هم | هم هم |
| баб | باب | باب |

## XIX гасыр – XX гасыр башы

(бер үк сүзләрнең төрлечә язылышлары)

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмалардагы вариантлары* | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | *1* | *2* | *3* | *4* |
| Аллаһ | الله | الله | الله | الله | |
| Тәгалә | تعالى | تعالى | تعـ | تعالى | تعالى |
| угылы | اوغلی | اوغلی | اوغـ | اوغـ | اوغلی |
| -нче, -нчы | نچی | نچی | نچ | نچا | نـ |
| сәнә | سنه | سنه | سـ | سنی | سنه |
| Вәли | ولی | ولی | ولی | ولی | ولی |
| Хәсән | حسن | حسن | حسن | حسن | حسن |
| Хөсәен | حسين | حسین | حسین | حسین | حسین |


بو قضانی ویردی بکا مولم جلیل صبر سیز عزیزلاری قیلور ذلیل
با صبر قیلورم صبر جمیل صبر برله مراد حاصل اولور ایمدی
بن سوده اول یسی کاه سوزی چقار دارو کبا اول قیوسیه کاه کوزی بقار
یوسف برله خبرلاشور سوزین اوقور احوالیدن جمله سین بیلور ایمدی
فصل
مصر ایلنده اول ملک اولور ایدی آنینک آدی ملک بنا دوغ ایدی
دغرادیلی ملک بر کون بر دوش کوردی معبّره تا دویلی سوزلار ایمدی
معبّره ایدی بر کون بر دوش کوردم دوشمده ایکه کنعانه واردم ایردیم
… قیوسی … ایردوم کون حقیقت کوکدان ایره اینار ایمدی
… معبّر کوکدان ایندی … قوبیدار … حقوی
… کوکدان … با آنی ایتاکا دیردوم ایمدی
… آنی دیرار ایردم جمیع قیلیب … ایدردم
بو دوشنی هیچ کمسه بیله کوردم یا معبّر بنکا تاویل قیلغیل ایمدی
معبّر ایدی … ییرایم بو دوشکنی تعبیر ایمدی
ایکی … دوشنکنی مبارک یورام ایمدی
اکر سن … دوش کوردونکا ایرسه دوشنکنده اول مقامه وارکنا ایرسه
حقیقت … ایردونکا ایرسه بر بشیر … الیکا کرار ایمدی

*Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре.*
*XIX гасыр башы күчермәсе*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

## 1918–1920 нче еллар

| *сүзнең хәзергечә язылышы* | *басма гарәп хәрефләре белән* | *кульязмада* |
|---|---|---|
| өч | اوچ | اوچ |
| нәрсә | نه رسه | نه رسه |
| һәм | هه م | هم |
| ләкин | لەکین   لکن | لەکین   لکن |
| хәбәр | حه به ر | حه به ر |
| икән | ایکان | ایکان |
| дигән | دیگان | دیگان |
| миңа | میڭا | میڭا |
| бирелəм | بیرله م | بیرلم |
| урында | اورنده | اورنده |
| ыстансия | ئستانسییه | ئستانسییه |
| зәмһәрир | زه مهه ریر | زه مهه ریر |
| төш | توش | توش |
| төсен | توسن | توسن |
| яшь | یه ش | یه ش |
| яки | یه که | یه که |
| мин | مین | مین |
| хуш | حوش | حوش |

Соңгы мисаллардан «төш» һәм «төсен», «яшь» һәм «яки», «мин» һәм «хуш» сүзләре язылышта бер-берсенә бик охшаш икәнлеге күренә.



*Гадел Кутуйның 1926 елгы кульязмасы*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

Инде әйтеп үтелгәнчә, кулъязма истәлекләрдәге палеографик үзенчәлекләр бик-бик күп. Монда аларның характерлырак һәм катлаулырак бер өлешен күрсәтү белән чикләндек.



*Кәрим Тинчуринның 1929 елгы кулъязмасы*
*(Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

# III БҮЛЕК: ГАРӘП ЯЗУЛЫ ТАТАР ЧЫГАНАКЛАРЫН МАТБУГАТТА БАСТЫРУДАГЫ КИМЧЕЛЕКЛӘР

Бу бүлектә гарәп язулы татар чыганакларын өйрәнүгә һәм текстларын матбугатта бастыруга бәйле мәсьәләләрнең кайберләренә тукталабыз.

Милләтнең төп нигезләре булган телебезне, әдәбиятыбызны һәм тарихыбызны яклау хәзерге катлаулы чорда галимнәрдән аеруча зур җаваплылык таләп итә. Кызганыч ки, югары дәрәҗәдәге гыйльми оешмалар тарафыннан (атамалары һәм грифлары куелып!) чыгарылган китап-басмаларның сыйфаты начарлана бару фәнни җәмәгатьчелек вәкилләренең хакыйкать сөюче өлешен бик борчый һәм безне дә хафага сала. Мондый күренеш – язма чыганакларга багышланган татарча фәнни хезмәтләрне нәшер итү культурасы дигән төшенчә асылының мәгънәсе бозылуы, татар китабы тарихы белгечләре буларак та, күңелебездә ризасызлык тудыра.

Кызганычка каршы, гарәп язулы чыганаклардан алып нәшер ителгән хезмәтләрдә ачыктан-ачык хаталар, төгәлсезлекләр тулып ята. Бигрәк тә кеше һәм китап исемнәренең, торак пунктларның, гомумән, төрки-татар һәм гарәп сүзләренең ялгыш укылуларына, хәзерге татар телендә чамадан тыш бозып бирелүләренә таң калырлык. Ялгышларның шактые гарәп язуындагы хәрефләрнең бер-беренә охшаш элементларын дөрес танымаудан, шулай ук хәрефләрдәге нокталарның саннарын (бер, ике, өч) кулъязмада анык белдерелмәвенә күрә, уйламый-нитми

генә күчерүдән һ.б. сәбәпләрдән хасил булганнар. Түбәндә тупланган мисаллардан ул ачык күренә. Мәсәлән, кеше исемнәре һәм нисбәләре: «Котлыгаш Сәмти» (дөресе – Котлыгыш Симети), «Кашми» (Касыйми), «Тумани» (Төмәни), «Абу әл-Галаи» (Әбелгалә), «Гали Ширнави» (Галишир Нәваи), «Галиәлдин» (Галәветдин), авыл атамалары: «Әләт» (дөресе – Алат), «Кара Иван» (Корайван), «Кашкар» (Кышкар), «Мачкярә» (Мәчкәрә), «Нәрсе» (Нырсы), «Нәса» (Носы), «Тәмтәк» (Тымытык), «Тәнки» (Тенеки), «Ури» (Оры), «Хәйретүш» (Чиртуш), «Яңанадыр» (Яңа Нәдер), хәтта гадәти сүзләр: «каблә» (дөресе – кыйбла), «мәниктә» (мең дә), «сагытчы» (сәгатьче), «эмальләп» (әмәлләп), Оренбургтагы мәшһүр «Хөсәения» мәдрәсәсен «Чәсәнбә» дип бирүләр һ.б.

Авылларның атамаларына килгәндә, патша заманнарыннан алып хәзергәчә даими басылып килгән административ-территориаль бүленешләр буенча торак пунктларның исемлекләре, соңгы чорда исә энциклопедия белешмәләре бар. Үзебезнең Татарстандагы авылларның исемнәре матбугатта да еш искә алына, ләбаса. Алар әллә кайлардагы яэҗүҗмәэҗүҗ кавемнәренең татар өчен чит-ят исем-атамалары түгел бит инде. Танылган галим Ризаэтдин Фәхретдиннең XX гасыр башында: «Адәм баласының белмәве, яңлышуы гаеп түгел, ләкин моның да бер чиге бар» дигән сүзләре бик хаклы.

Филология фәннәре докторлары һәм кандидатлары дәрәҗәсен йөрткән кайбер авторларның хезмәтләрендә гарәп язулы чыганакларга бәйле хилафлыклардан тыш, бөтенләй килешсез, фәннилекне какшата торган тел-стиль кимчелекләре, орфографик һәм пунктуацион хаталар да шактый. Мәгълүм булуынча, хаталар – ялгыш аңлауга һәм аңлатуга сәбәпче. Бу хәл исә чын-чынлап борчуга төшерә. Әлбәттә, камиллекнең чикләре юк. Ләкин мондый төр җитди темаларда фәнни җаваплылык тоеп эшләү аеруча зарур.

Галимнәр язган китапларны файдаланучы милләттәшләребез белән дә санлашырга тиешбез, аларның фикерләрен бутамаска һәм ышанычларын акларга кирәк. Фәнни хезмәтләрнең мөмкин булганча хатасызрак тәкъдим ителүе фарыз. Чөнки дөрес итеп язылмаган, хаталар белән тулган китаплар фән әһелләренә карата ышанычсызлык тудыра[1].

Без күрсәткәннәргә охшаш мисаллар аерым авторларга һәм текстологларга гына хас җитешсезлекләр түгел, әлбәттә. Мисал итеп китерелгән очраклар һич тә галимнәребезнең башкарган эшләреннән кимчелек эзләү дип кабул ителмәсен иде. Безнең максат һич тә шәхсияткә тыкшыну түгел, ә хаталарның киләчәктә кабатланмауларын теләү. Хата-ялгышларны, техник сәбәпләргә генә сылтап, аклау да дөрес булмас. Мисаллар алынган хезмәтләрне хәзерләгән белгеч-авторның еш кына фән докторы дәрәҗәсендәге җитәкчеләре, басманың гыйльми советы яки редколлегиясе, җаваплы мөхәррире һәм корректорлары да булган бит. Фәнни басмаларның хаталары елдан-ел ишәеп баруына фән даирәсе хезмәткәрләренең гомуми игътибарсызлыгы һәм битарафлыгы сәбәпче.

Милли фәнебез белән мәшгуль затларга мәкаләдә бәян ителгәннәрдән сабак һәм гыйбрәт алырга мөмкин дип ышанабыз. Киләчәктә татар язма чыганаклары белән эш итәчәк яшь буын фән әһелләре хата-кимчелекләрдән мөмкин хәтле сак булсыннар иде, үзләренең кылган гамәлләренә зур таләпчәнлек тоеп, төгәллеккә омтылсыннар иде. Хаталарны булдырмауны кайгырту, һичшиксез, галимнәрнең һәм фәнни оешмаларның турыдан-туры бурычы.

---

[1] «Чыңгызнамә» исеме белән мәгълүм тарихи дастаннар җыентыгының гамәлдәге татар язуында чыккан басма текстларындагы ялгышларны һәм хаталарны тәгаен мисаллар белән күрсәтеп язган идек. Анда хәрефләрне («би» һәм «нун», «каф» һәм «кәф», «гәф» һәм «гайн», «җим» һәм «ч» һ.б.) буташтырып укыганга бәйле элементар ялгышлыклар һәм башка төр хаталар да искә алынды [90, 30–37].

Электән үк язып килгәнебезчә [45; 46, 58–77, 80–93; 50; 51, 16; 48, 16–19; 93, 222–242; 88], фәндә башбаштаклыклар, аерымачык хаталар һ.б. шундый гаделсезлекләр аз түгел һәм фән өчен җаваплы даирәләр тарафыннан аларны күпмедер дәрәҗәдә төзәтергә дә соң булмас дип уйлыйбыз.

Әлбәттә, моңарчы язган борчулы тәнкыйтьләребезне фәнни җәмәгатьчелек авыр кабул итте. Үзебезгә җавап итеп пычрак ату, гаепләү, түбәнсетү һәм кимсетү сүзләрен әйттеләр, язып та чыктылар. Гамәлебезне аерым авторларга карата, гүяки, махсус әшәке ният белән хәрәкәт итү дип аңлаучылар һәм шуңа инандырырга тырышучылар, үпкәләүчеләр, «ул өлкән яшьтә бит», «аңа тимәгез инде» дип үгетләүчеләр, хәтта мәхкәмәгә бирергә омтылучылар да булды. (Татар орфографиясе мәсьәләләрен катлаулы ысуллар белән хәл итәргә бернинди ихтыяҗ да юк – аның кагыйдәләрен төгәл үтәргә генә кирәк). Китаплардагы хаталарны гына күздә тотканга күрә, «аңа тимәгез» кебек сүзләрдә без бары тик хаталарга кагылмауны, аларны күрсәтмәүне киңәш итәләр дип кенә аңлыйбыз. Әйткәнебезчә, төп мәсьәләне шәхси каршылыкка борырга маташуга без риза түгел. Безне каләм алырга мәҗбүр иткән төп сәбәп – туган телебезнең мыскыллануы һәм фәнни хезмәтләрнең ерып чыкмаслык хаталарга батуы иде. Шулай ук, «без башкача – үзебезчә эшлибез» дип, татар теленең менә дигән кагыйдәләрен бозуны «башкача эшләү» дип белдерергә омтылучыларны да күрдек. Төбәк тарихларын өйрәнүчеләрдән берсе «сез бит кандидат кына, ә ул фән докторы» дип, фәнни иерархиягә формаль нигезләнеп, хаталы язылышлар тарафына өстенлек бирүне кулай күрде. «Эшләгән кешенең хатасы була инде ул» һәм «хатасыз китап юк хәзер, техник хатага аптырыйсы юк инде», «тизрәк эшләп калырга кирәк безгә, юкса чыганаклар бетеп бара бит», «әллә нинди таләпләр куеп булмый инде – һәркем дә югары сыйфатлы итеп эшли алмый», «хаталарын төзәтеп укырлар», «компьютерда хаталар китсә

дә, фәннилеккә зыян килми ич», «шулай чыккан бит, хәзер шулай кереп китте инде ул» кебек хисапсыз аклану һәм битарафлык (асылда – татар теленең фәннилек дәрәҗәсен хөрмәт итмәү, түбәнсетү) сүзләрен күп ишеттек. Әле тагын «Сезнең кебек, хезмәтемә алтыннар алсам, редактор да яллаган булыр идем» [11] дип, безнең хезмәт хакларыбызны патша заманындагыча алтын белән түләнүен гөманлап шакkаттыручылар да булды.

Барыбыз өчен дә газиз татар теле фән теле буларак үзен күптәннән таныткан һәм шуны раслаган югарылыгын җуймасын иде. Күп гасырлык, искиткеч бай язма мирасыбызны мыскыллауга юл куелмасын иде. Элеккеге кыйммәтле истәлекләрне өйрәнеп бастыручы галимнәрдән берсенең дә, ваемсызлык күрсәтеп, ядкярләрнең фәнни кыйммәтенә зарар китерергә хакы юк.

Мәгълүматларны берникадәр төркемләбрәк бирергә тырыштык.

## Язма истәлекләрнең даталары турында

Бу мәсьәләгә китапның беренче бүлегендә аерым тукталган идек. Монда кайбер ялгышу очракларын тасвирлап үтәбез.

Китапның беренче бүлегендә татар кульъязмаларының XVII гасырдан элеккерәкләре санаулы икәнлеген, әүвәлгеләре исә табигый һәм тарихи сәбәпләр нәтиҗәсендә юкка чыкканлыгын яздык. Кайбер әдәби истәлекләрнең иң әүвәлге күчермәләре XVII–XVIII гасырлардагы кульъязмаларда гына сакланып калганлыгына нигезләнеп, алар нәкъ шул чорда иҗат ителгән дигән караш [76, 231] дөрес түгел. Бу уңайдан 1233 елда иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф»ның иң элекке күчермәләре XVII гасырда, Мөхәммәдьяр 1541 елда язган «Нуры содур» поэмасының иске нөсхәләре XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башыныкы булуын да искә төшерик.

Текстологиядә даталар мәсьәләсендә, төрле ялгышлыклар белән бергә, гомуми сыйфатлауларда да шактый төгәлсезлекләр булып тора. Галимнәр (хәтта тарихчылар) тарафыннан андый илтифатсызлык мисаллары бар. Мәсәлән, Беренче Бөтендөнья сугышында алман әсирлеген кичергән кешенең хатирәләрен бастыручылар аны Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәреннән борынгы» [94, 7–8] дип билгеләгәннәр. Җәлил дәфтәреннән 30 еллап кына элеккеге вакытны «борынгы» дип атау мәгънәви яктан бөтенләй дөрес түгел. Гомумән, XX гасырдагы вакыйгалар турында сүз барганда «борынгы» дигән термин урынлы түгел. 1930 нчы еллардагы татар эпиграфик истәлекләрен «борынгы» дип, хаталы тәгаенләү мисаллары [21, 4] да бар. Мәгънәви яктан «борынгы» сүзе «бик күптәнге» дигәнне белдерә бит, ә тарих даирәсендә – безнең эраның бишенче гасыры белән чикләнгән чор шартлы рәвештә «борынгы тарих» дип йөртелә.

Кабер ташларын өйрәнүче кайбер замандашларыбыз, мәрхүмнең үлгән елына һәм ничә яшьтә булуына нигезләнеп, җайлы гына туган елын билгеләү белән мавыгып ялгышалар. Чөнки андый рәвешле исәпләү, элек мөселман татарларның һиҗри календарь белән эш иткәнлеген игътибарга алганда, дөрес булмый.

***

Танылган татар мәгърифәтчесе, педагог, китаплар авторы Шакирҗан Таһирига (1858–1918) багышланган нәфис альбомда XIII гасыр гарәп шагыйре Мөхәммәд әл-Бусыйриның «Касыйдәи бөрдә» әсәре күчермәсенең факсимилесе бирелгән [91, 36–44]. Зиннәтле гонванлы һәм һәрбер битендәге тексты өчәр кат алтын кысалар эчендә язылган, гарәп телендәге төп тексты астында татарча тәрҗемәсе дә вак язу белән теркәлгән бу кульязма истәлекне беренче караштан ук XVIII гасыр кульязмасы дип билгеләргә

мөмкин. Һәрхәлдә, аның XIX гасыр уртасыннан да соңрак күчерелмәгәнлеге чамалана. Кызганыч ки, үзендә колофонлы бите юк. Шунлыктан, кайчан, кайда һәм кем тарафыннан күчерелгәнлеген төгәл белеп булмый. Кульязманың беренче кәгазендә «Шакирҗан бине ахунд Әхмәдҗан Таһиров» дигән штамп сугылган. Шул мәгълүмат нигезендәме (безгә билгесез), әлеге альбомда бу кульязма истәлек Ш.Таһири тарафыннан 1880 нче елларда күчерелгән һәм тәрҗемә ителгән дип язылган [91, 6, 36, 45]. Ләкин бу мәгълүмат дөрес түгел.

***

Эпиграфик истәлекләрнең заманнарын берничә гасырларга ялгыш тәгаенләп язылган мисаллар аз түгел. Ләкин зур абруйга ия тарихчы галимнәрнең хаталанулары авыр кабул ителә. Мәсәлән, М.Госманов хатирәләрендә «Олы Мәңгәр янындагы Болгар чоры кабер ташлары...» [27, 343] дигән гыйбарә төгәл булмавын искәртергә кирәк. Татарстанның Әтнә районындагы Иске Мәңгәр авылы янындагы борынгы зиратта иң элекке ташъязма истәлек 1495 елга карый, ә калганнарының күбесе XVI гасырныкы [47, 145–150].

***

Алабуга дәүләт педагогика университетының музеенда гарәп хәрефләре уелган бер серле ташъязма турында 2010 елда Гөлзадә Әхтәмова мәкаләсе басылып чыккан иде [12]. Автор ташны болай тасвирлаган: «Әлеге ташбилгенең үлчәме 115х4х19 см. Аның өске өлешендә 16–19 сантиметрлы түгәрәк диск ясалган. Шуның эченә түгәрәкләп гарәп имлясы белән нидер язылган. Дискның уртасы бик бозылган. Кырларындагы язуларны да укуы җиңел түгел».

Мәкаләдә язылганча, ташъязманың күренгән өлешендәге «ш, н, җ» хәрефләре танылган (шунда ук бирелгән график рәсемдә «Т.С.Ш.Җ.» хәрефләре һәм һәрберсеннән соң куел-

ган нокталар аермачык күренеп тора). Мәкалә авторы гарәп хәрефләре белән билгеләнгән саннар (әбҗәд) ярдәмендә, бер караганда, кызыклы гына нәтиҗәләргә килгән. Ул болай ди: «...350 саны барлыкка килә. Аны һиҗридән миладига күчерсәк, якынча 962 саны килеп чыга. Чү, Алабуганың борынгылыгын – меңьеллыгын дәлилләүче сан түгелме соң бу? ...Безнең ташбилге – иң борынгысы булып чыкты: (962 ел)».

Әлеге мәкаләдә, ташъязмадагы башка хәреф өлешләрен бай фантазия һәм ярымфараз рәвешендә күзаллап, 52 яшендә дөньядан киткән кеше биредә яшәүче халыкның, алыпларның, сугышчыларның башлыгы һәм аның исеме, ихтимал, Алып буга булгандыр дигән гаҗәеп мәгълүматлар бирелгән. Гөлзадә Әхтәмова үзенең фикерен «Шулай итеп, Алабуга җирендә табылган иң борынгы ташбилгенең сере бераз ачыла төште кебек... Бу ташбилгенең кыйммәте бәяләп бетергесез, дип ышанам» сүзләре белән тәмамлаган.

Мәсьәләнең торышы, чынлап та, шушы мәкаләдә тасвирланганча булса, һичшиксез, ул сенсация дәрәҗәсендәге зур фәнни ачыш дип бәяләнер иде. Чөнки монгол яуларына кадәрге Болгар дәүләтенең кабер ташлары бөтенләй (берсе дә) сакланмаган бит. Әлеге серле ташбилге белән без дә кызыксындык һәм хезмәттәшем Ирек Һадиев белән барып күрергә ниятләдек.

«Мәдәни җомга» газетасында басылган мәкаләдәге рәсемнән үк ачык күренгән әлеге ташъязма хәрефләре нәрсә аңлаткан булуы һәм аның кайсы чорга караганлыгы безнең өчен аңлашыла төшкән иде. Аның тышкы кыяфәте үк безнең җирлектәге һәм, гомумән, төрки-мөселман кабер ташларыннан аермалы. Беренче карашка, ул чик баганасын хәтерләтә. Шәкеле дә үзенчәлекле – калынлыгы 4 кенә см булуы гаҗәп. Түгәрәк даирә эчендәге уелып язылган хәрефләре дә кабер ташларына бөтенләй хас түгел.

Археология музеендагы серле ташның өске өлешендәге түгәрәк даирәсенең эче шактый уалган. Бары тик түгәрәкнең

сул тарафындагы чиге буенча «Т.С.Ш.Җ.» рәвешендәге кыскартылма-абррeвиатура хәрефләре яхшы танылa. Хәрефләрдән соң куелган нокталары да әйбәт күренә.

Бу урында нокталар мәсьәләсенә ачыклык кертеп китү бик мөһим. Гарәп әлифбасы белән таныш кешеләргә бик яхшы мәгълүм ки, бу язудагы хәрефләрнең нокталары хәрефнең төп элементы өстендә яисә астында куела, ә төп элементның алдында яки артында куелмый һәм элек тә куелмаган. Безнең җирлектәге гарәп хәрефле язмаларда нокта һәм башка тыныш билгеләре XIX гасыр ахырында куела башлаган, гарәп хәрефле аббревиатуралар исә гомумән 1917 елдан соң гына кулланылышка кергән.

Музейдагы ташка уелган аббревиатурага килгәндә, ул «Татар Социаль Шуралар Җөмһүрияте» дигәнне белдергәнлеге һәм аның 1920–1925 нче елларга нисбәтле булуы безгә – гарәп язулы татар матбугаты (шул исәптән, 1920 нче елларга караган өлеше) белән эш иткән һәм архивларда совет чорындагы документларны өйрәнгән кешеләргә бик яхшы таныш. 1920 нче еллардагы татар матбугатында һәм рәсми оешмаларның мөһерләрендә мондый аббревиатуралар очрый. Алабугадагы әлеге серле ташъязманың түгәрәк читендәге ТСШҖ кыскартылмасының нәрсә икәнлеге турында һичбер шигебез юк. Шул ук хәрефләргә каршы ягында диярлек – түгәрәкнең уң як читендә әлеге аббревиатураның рус хәрефләрендәге «Т.С.С.Р.» дигәннең бары тик ике «С» хәрефенең түбәнге өлешләре һәм алардан соң куелган нокталары сакланган. Әмма түгәрәкнең эчендә нәрсә язылган булгандыр – анысы билгесез. Гомумән, бу ташка республика атамасының кыскача язылышы уелганлыгына караганда, ул нинди дә булса рәсми чикне (межаны) белдерү өчен махсус эшләнгән кечкенә таштакта – стелла булганлыгы аңлашыла.

Археолог Альберт Нигамаев: «бу таш җиргә күмелгән булган, аны межа өчен куелган булган дип әйтәләр», – диде. Ләкин ул «Бу – монголларга кадәрге чор ташы, бордюр...»

дип, үз карашын белдерде һәм безнең фикерне сорады. Без югарыда язылганча фикеребезне әйттек. Ул вакытта бездән кычкырып көлделәр... Алабугадагы археология музеенда бу ташъязма янына аның нәкъ менә монголларга кадәрге эпиграфик истәлек булуы турындагы ялгыш мәгълүмат язып куелган.

Бу ташбилге, чынлыкта да, борынгы дәверләр истәлеге булса, без дә бик шатланыр идек. Ләкин күзгә күренеп торган фактлар аның борынгы Болгар заманы ядкяре булу ихтималын кире кага. Татар эпиграфикасын өйрәнүдә кайбер ялгышлыклар һәм кимчелекләр күренгәләсә дә, тарихи истәлекләрнең даталарын билгеләү мең ел чамасы чикләрендә үк булырга тиеш түгел дип саныйбыз.

***

Кайбер татар язма чыганаклары элеккерәк чорда ялгыш даталанып, ләкин аннары төгәл ачыкланган һәм төзәтелгән булсалар да, галимнәр фәнни хезмәтләрдә мондый мәсьәләләргә игътибар биреп җиткермиләр. Мәсәлән, Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Төхфәи мәрдан» поэмасының Пермь өлкәсендә табылган кулъязма күчермәсе 1600 елга карый дип элегрәк билгеләнгән мәгълүматы ялгыш булганлыгы һәм аның дөреслектә XVII гасыр ахырында күчерелгәнлеге 1999 елда ачыкланган иде. Бу хакта без дә искәрттек [93, 240]. Әмма галимнәр һаман искергән 1600 ел турында язуны дәвам итәләр [76, 214].

Хәзерге Киров өлкәсенең Нократ авылы зиратындагы XVI гасырга караган ике кабер ташының дөрес даталары 1520 һәм 1553 елларга нисбәтле икәнлеге анык итеп белдерелгән һәм өстәвенә, ул ядкәрләрнең шигый мәзһәбенә мөнәсәбәтләре булмаганлыгы язылганга [49, 4–12] карамастан, аларны элекке китапларда ялгыш билгеләнгәнчә – 1522 һәм 1555 елларныкы дип кабатлау [76, 40–41] дәвам итә. Шуның белән бергә, «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтендә

Нократ татарларын шигыйларга[2] бәйләргә омтылган ялгыш караш тагын кабатланган.

Бу мәсьәләдә сүзне йомгаклап, галимнәр еллар-даталар турында фикер йөрткәндә аеруча игътибарлы булсыннар иде дип телибез.

## Авторлык табышмаклары

Татарларда яратып укылган элекке әсәрләрне шактый киң тикшереп, тарихи фактларны, чагыштыруларны һәм ярымфаразларны бергә кушып, кызык нәтиҗәләргә ирешүчеләр бар. Аларның кайбер фикерләре, еллар узу белән үзгәрә һәм тагын да камилләшә. Мәсәлән, әдәбият тарихчысы Фәрит Яхин «Кыйссаи Авык» әсәрен «XII гасыр азагында язылган» дип, «Мәликә китабы»ның иҗат ителгән датасын XI гасырның урталарына нисбәт итеп, «Кисекбаш китабы»ның 1064 елда язылганын һәм хәтта авторын да – Шәмс Тәрази (Мөхәммәд әд-Дәрази) дип тәгаенләде [95, 9; 96, 163; 99, 126–129]. Дөрес, ул элегрәк: «Кыйссаи Авык» үзенең стиле, шигъри формасы белән бигрәк тә «Кисекбаш» кыйссасына якын. Кайвакыт ике әсәрнең дә авторы бер үк кеше түгелме дигән интуитив сиземләүгә киләсең» [95, 9] дип тә белдергән иде. Шул ук галим ике дистә ел әүвәлрәк «Кисекбаш китабы»ның авторы XIII гасырда яшәгән суфи әдип Җәлалетдин Руми дип белдергәнен дә искә алыйк [100, 244].

Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» күчермәләреннән берсендәге төгәл язылып җитмәгән датасы һәм шул ук кульязмада аерым теркәлгән кеше исеме буенча фаразлап, Ф.Яхин әлеге әсәр 1628 елда язып төгәлләнгән һәм авторы Мәүлүдгол исемле шагыйрь булуы ихтимал дип язган иде

[2] Әдәбият тарихы хезмәтенең күрсәтелгән томында (31 h.б. битләрдә) «шигыйлар» сүзенең нилектән «шыгайлар» дип (гүяки, Апас яки Сарман районнарындагы Шыгай исемле авыл кешеләре кебек) язылган булуы да аңлашылмый.



*Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре. XVII гасыр күчермәсе (Татарстан Республикасы Милли китапханәсе)*

[101, 21–22]. Бу очракта галим текст күчермәсенең ахырындагы язылып бетмәгән елны әсәрнең иҗат ителгән вакыты дип ялгышкан. Хәер, ул зур хата булмаган да. Чөнки аннан соң Ф.Яхин төгәлрәк ачыклап, «Нәсыйхәтнамә» әсәренең авторлыгын Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» хезмәтендә телгә алынган Хуҗамшөкер бине Гаваз-байга нисбәт итеп, иҗат ителгән вакытын 1703 ел дип белдерде [98, 224–239]. (Шуны искәртик, «Нәсыйхәтнамә»нең Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган XVII йөз күчермәсе бу версиянең хаклыгын шик астына ала. Чөнки

1703 елда иҗат ителгән әсәрнең 1659–1660 еллардагы кәгазьгә язылa алу ихтималы бик шикле).

***

«Татар әдәбияты тарихы» сигезтомлыгының 2014 елда нәшер ителгән 2 нче томында «Кыз хикәяте» кыйссасы турында мәкалә бар [75, 123–139]. Мәкалә ахырында бу кызыклы әсәрнең авторы мәсьәләсендә фараз да белдерелгән. Ә шул томның яңартылган 2022 елгы басмасында «Кыз хикәяте»нең авторы Хаҗи Мәхмүд дип бирелгән [76, 141]. Гәрчә бу исем мәкаләдә башка әсәрнең авторы буларак телгә алынган. Әсәрнең авторлыгын Хаҗи Мәхмүдкә нисбәт итү очрагы әлеге томны хәзерләгән галимнәрнең, йомшак итеп әйткәндә, ваемсызлыгына бәйле. Әдәбият тарихы китабына кертелгән мәкалә шул томны төзүчеләр тарафыннан укып чыгылса яисә кыйсса турындагы мәкаләне язган авторга китап вариантының корректурасы күрсәтелсә, мондый тупас ялгышлык китмәс иде. Гомумән, татар әдәбияты тарихына багышланган күптомлыклар дистә еллардан соң гына чыкса да, мондый хаталары төзәтелер дигән ышаныч, кызганыч ки, юк.

«Сираҗел-колүб» исемле әсәрнең авторы дип саналган Адниш хафиз мәсьәләсендә фикеребезне белдергән идек [29, 21–23; 44; 93, 230–232]. Беренчедән, аның исеме ялгыш язып йөртелүен искәрттек. 1554 елгы кульъязмада ул үзен «Адниш хафиз ибне Мөхәммәдаднаш хафиз» дип теркәгән. Икенчедән, ул иҗат иткән дип, аңа нисбәт ителгән «Сираҗел-колүб» нөсхәсе фән өчен озак вакытлар билгесез калган һәм XX гасыр уртасында гына (!) ачыкланган була торып, аның башка күчермәләре ничек итеп халык арасында таралырга мөмкин дигән сорау куелган иде. «Татар әдәбияты тарихы»ның яңартылган томында бу мәсьәләләр берсе дә исәпкә алынмаган. (Гәрчә Фәннәр академиясенең бу томнарны чыгару өчен җаваплы галимнәренә безнең мәкаләбез

билгеле иде). «Әдәбият тарихы»ның яңартылган басмасында (2022) Аднищ хафизның үз исеме урынына әтисенең исеме һәм рухани титулны белдергән «хафиз» (мулла) сүзе кеше исеме рәвешендә «Аднаш Хафиз» дип бирелгән һәм ул «Сиражел-колүб»нең авторы итеп тәкъдим ителгән. Әдәбият тарихы томын басмага хәзерләүче галимнәр филология фәннәре кандидаты Р.Мәрдановның фикере белән килешмәгән очракта, һичьюгы астөшермәдә авторлык мәсьәләсендә башка карашлар да булуы искәртелергә тиеш иде. Шул ук икенче томның 158 битендәге астөшермәдә Колшәриф (Шәрифи) авторлыгы турында искәрмә бирелгән хәлдә, бүтән авторларга карата зарур булган искәрмәләр юклыгы – китап төзелешенең принцибына да туры килми. «Сиражел-колүб»нең 1554 елгы күчермәсе палеографик үзенчәлекләреннән кайберләре XVI гасырга хас түгеллеген, ә элеккерәк – XIV гасыр текстларына охшашлыгын бу китапның II бүлегендә дә искәртеп үттек.

«Татар әдәбияты тарихы»ның әлеге икенче томында шундый ук искәрмәләргә мохтаҗ урыннары тагын да бар. Мәсәлән, шагыйрь Габдессәламнең биографиясендәге (309 бит) каршылыклы урыннар турында, аерым алганда, аны Габдессәлам Урай улы белән тәңгәлләштерүнең дәлилсезлеге һәм 60 яшендәге (!) кешенең рус гаскәрендә Польшага яу чабу ихтималы булмаганлыгы турында язылган иде [93, 234–237]. «Татар әдәбияты тарихы»ның 2 нче томындагы фототупламда «Габдессәламнең бер шигыре. 1757 ел» дип астына язылган кульязманың күчермәсе, чынлыкта, башка авторныкы. Аның башында ук «Мескен Габди...» дип, авторының исеме анык белдерелгән.

Шулай ук 1766 (1767) елда иҗат ителгән «Фәүзеннәҗат» әсәренең Ибраһим ахунга нисбәт ителүе ялгыш икәнлеген дәлилләр китереп – Ибраһим ахунның 1761 елда вафат булганын белдереп язган идек [93, 237–238]. Бу да исәпкә алынмаган, искәрмә-фәлән бирелмәгән һәм «Татар

әдәбияты тарихы»ның 2 нче томында (315–316 битләрдә) иске мәгълүмат кабатлап басылган.

Сүз уңаеннан, әлеге томның фототупламындагы «Үтәмеш Хаҗи. Чыңгызнамә. 1870 елгы күчермә» дип тәкъдим ителгән кульязма фотокүчермәсе, дөреслектә, Үтәмеш Хаҗиныкы түгел, ә «Дәфтәри Чыңгызнамә» исеме белән танылган тарихи дастаннар җыентыгы. Бу күчермәнең фотосы һәм астындагы язуы 2014 елгы «Татар әдәбияты тарихы» сигезтомлыгының 2 нче томында ук бар иде һәм аның ялгыш икәнлеген искәрткән идек [93, 270].

Габдерәхим Утыз Имәнинең гыйлемне данлаган «Әбйате төрки фи фазыйләте гыйлем» исемле, күләмле шигыренең утыз юлы XV гасырда Вафаи иҗат иткән «Раунакыльислам»нан һәм ун юлы XVI гасырда язылган башка бер шигъри әсәрдән алынган булуын ачыклап, берничә мәртәбә искәрттек [61, 27–30; 93, 19]. Бу мәсьәләне дә галимнәр игътибарсыз калдыра – «Татар әдәбияты тарихы» сигезтомлыгының яңартылган 2022 елгы басмасында Г.Утыз Имәни иҗаты турында язганда (421 бит) «Әбйате төрки...»гә бәйле бернинди үзгәреш юк.

Мәшһүр «Бәдәвам» әсәренең иҗат ителгән вакыты һәм авторлыгы турындагы бәхәсле фикерләр, аның ничә мәртәбә басылып чыкканлыгы турында дәлилле итеп язган идек [93, 222–229]. Әмма әдәбият тарихы томнарын төзүчеләр безнең тарафтан китерелгән дәлилләр белән исәпләшмичә һәм фикерләребезгә бернинди әһәмият бирмичә, һаман иске мәгълүматны кабатлауны кирәк дип тапканнар [76, 291–292]. Әдәбият тарихы китабында «Бәдәвам»ны 1914 елга кадәр дөнья күргән дистәдән артык басмасын телгә алып үтсәләр, без аның 1915 елга кадәр 67(!) мәртәбә басылганлыгын язган идек [93, 228].

Монда әйтелгәннәр барысы да, ни кызганыч, әдәби мирас мәсьәләләренә игътибарсызлык һәм ихтирамсызлыкны күрсәтеп тора.

## Текстологик фантазия мисаллары

Кайбер галимнәр элекке язма чыганаклар белән эш иткәндә фантазияләре белән әллә кайларга кереп китәләр һәм укучыларны да үзләренә ияртәләр. Кайчагында исә адаштыралар да...

Шиһабетдин Мәрҗанинең 1989 елда басылган «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтендә кайбер сүзләрнең мәгънәләре бөтенләй ялгыш һәм мантыйкка сыймаслык итеп аңлатылган урыннар бар. Мәсәлән, «...Матур язу остаханәләре идарәсендә сәүдә белән шөгыльләнә» һәм «Хәттат фабрикалары тотып, сәүдә белән дә шөгыльләнгән...» [52, 301, 304] дигән җөмләләр шундыйлардан. Соңгысындагы «хәттат» сүзенә астөшермәдә «бизәк, бизәү, каллиграфия» дип, мәгънәсе искәртелгән. Аптыраш тудыра торган бу очракта «Мөстәфадел-әхбар...»ның гарәп язулы әүвәлге басмасындагы «хытат» сүзе (дөреслектә «къ» урынына «х» хәрефе белән бирелүе) ялгыш мәгънә чыгарырга сәбәпче булган. Башлангычта Кытай атамасына бәйле булган «кытат» сүзе «тукыма, киже-мамык» дигәнне белдергән. Төрки телләрдә къ/х авазларының күчеше язуда да чагылыш тапкан, шул ук Кытай атамасын Хытай дип язганнар, *бакча, акча, вакыт* кебек сүзләр дә элекке чорда *бахча, ахча, вахыт* рәвешләрендә теркәлгән. Менә шушы үзенчәлек исәпкә алынмаганга күрә, Ш.Мәрҗани хезмәтенең 1900 елгы басмасындагы «хытат кярханәләре» (тукыма мануфактуралары) гыйбарәсе «матур язу остаханәләре» дип ялгыш тәкъдим ителгән. Тарихи чынбарлыкны истә тотканда, рус империясе чорында татарларның каллиграфия үзәкләре тота алу мөмкинлеге бөтенләй булмаган. (Бу турыда китапның I бүлегендә язып үттек). Ә шундый остаханәләрнең (күплек санында!) идарәсендә (!) сәүдә белән шөгыльләнү, мантыйк ягыннан караганда, бөтенләй сәер.

Тарихи хезмәтнең шул ук 1989 елгы басмасында «ка-

берлегендә тимер ишекләр белән ясаткан таш стенасы» [52, 387] дигән өземтәдәге «стена» сүзе чынлыкта «астанә» (ягъни, төрбә, мавзолей) дигән гыйбарәне ялгыш аңлау-аңлатудан чыккан.

Шул ук китапның иске басмасында «ару төрки» дип басылган сүзләрнең 1989 елгысында «ар һәм төрки» дип, асылдан ялгыш бирелгәнлеген дәлилләп моңарчы язган идек [86, 12].

***

Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1997 елгы басмасындагы текстологик кимчелекләр турында галимнәр язганнар иде. Мәсәлән, филология фәннәре докторы Мәсгуд ага Гайнетдин тәфсилле күзәтүләре белән уртаклашты [20, 97–113]. Филология фәннәре докторы Фәрит Яхин да Шакир Абилов хезмәтендәге җитешсезлекләрне ачып бирде. Ул, аерым алганда, «Нуры содур» поэмасы авторы тарафыннан күрсәтелгән һиҗри 948 елның 12 мөхәррәм датасын, 1542 елның 14, 15 май көннәренә яисә 1541 елның 12 маена туры килә дип, төрлечә буталуларга игътибар юнәлтте [100, 319]. (Чынлыкта, ул дата 1541 елның 8 май көненә туры килә). «Төхфәи мәрдан» әсәренең язылу датасы уңаеннан Ш.Абиловның буталчык фикерләре бар. Ул аны 1540 елның 9 яки 10 гыйнварында төгәлләнгән дип язганнан соң, бөтенләй мантыйкка сыймаслык фантазияләргә бирелгән. Ягъни, «Тугызында – җомга көнне шагыйрь инде тәмамланган әсәрне тагын да бер кулына алып, аның ерак киләчәктәге оныкларына барып ирешәчәге турындагы өметләре белән җылынып, дога кылып, инде көмеш төсенә кергән чәчләрен сыпырып, ак каурый каләмен кулыннан төшермичә, Казанның Олы капкасы янына гадәти җыела торган халык төркеменә күзләрен төбәп, уйлары Казансу өстендә уйнаклап җилпенгән акчарлаклар белән каядыр еракка, якты һәм кояшлы киңлеккә очыргандыр...» [57, 168].

Китапны төзегән галимнең гыйнвар ае турында сүз барганда «Казансу өстендә җилпенгән акчарлаклар...» дигән хыялый фәлсәфәсе, фәнни хезмәтнең искәрмәләр өлеше өчен, әлбәттә, урынсыз һәм бөтенләй кирәксез иде.

Менә болар хакында, шулай ук «Нуры содур» текстының бүтән күчермәләрендә өстәмә дүрт икеюллык строфа барлыгын, әсәрдәге өч бүлекнең башларында Коръән гыйбарәләре теркәлгәнен (алар Ш.Абилов басмасында юк), 1997 елгы басмада Урдага барып худның йөзен күрү турындагы аңлаешсыз җөмләнең дөресе ханның йөзен күрү турында икәнлеген һ.б. ачыклап язган идек [59, 8]. Ни кызганыч, башка галимнәрнең дә, безнең дә дәлилле төзәтмәләр һәм тәкъдимнәр хәзергәчә игътибарсыз кала – Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1997 елда чыккан китабындагы бөтен хата-кимчелекләр ничек булсалар, әдипнең соңгы – 2021 елгы басмасында нәкъ шулай ук кабатланган: «худның йөзе», гыйнвар аендагы акчарлаклар һ.б. [58, 252, 265] – һәммәсе үз урыннарында.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, Мөхәммәдьяр әсәрләренең моңарчы чыккан басмасындагы кимчелекләрен һәм ялгышларын төзәтеп, яңадан нәшер итү ихтыяҗы зур. Мөхәммәдьяр кебек борынгы әдипләрнең иҗади мирасы, һичшиксез, хәзерге фәнни таләпләр югарылыгында камилрәк рәвештә басылырга тиешле. Шулай ук, «Нәһҗел-фәрадис» кебек борынгы ядкярләрне, 2004 елда нәшер ителгән «Могҗизнамә» китабын һәм Мәүла Колый әсәрләрен камилләштереп, кимчелекләреннән мөмкин булганча арындырып бастыру зарур. Болардан «Могҗизнамә»нең гомуми җитешсезлекләрен элегрәк искәрткән идек [61, 54–55]. Мәүла Колый әсәрләренең исә хәзергә тулы булган басмасы – 2010 елда Уфада 100 данә тираж белән чыккан китабында да төзәтмәләргә мохтаҗ урыннары шактый. Ә «Нәһҗел-фәрадис» текстына килгәндә, моңарчы дөнья күргән китаптагы хаталарын төзәтеп, 2024 елда Милли китапханә

экспедициясендә табылган тулы кулъязма күчермәсе белән чагыштыру да файдалы булыр иде.

***

Иске текстларны өйрәнүчеләр кайвакытта, ялгыш уку нәтиҗәсендә, ихтыярсыз, шактый шагыйранә һәм кызыклы гыйбарәләр хасил итәләр. Мәсәлән, 1870 елда вафат булган бер мәрхүмәнең кабер ташындагы текст ахырында «Аллаһы Тәгалә рәхмәт әйләсен» дигәч язылган «Коелды яшь учыма» [81, 166] сүзләре мантыйк-мәгънә ягыннан бик ярашып тора һәм гади генә сүзләр белән образлы итеп сыйфатланган дип, соклану тудыра. Ләкин бу соңгы җөмлә дөреслектә кабер ташының «куелды баш очына» дигән сүзләрен белдерә. Аның шулай икәнлеге китапның үзендә үк һәм нәкъ әлеге ташъязма текстында дөрес итеп тә басылган [81, 22].

## Иксез-чиксез хаталар галәме

Гарәп хәрефләре белән басылган чыганаклардагы авыл һәм төбәк атамаларының (кайберләре аерым шәхесләрнең нисбәләрендә), шәхесләр һәм китап исемнәренең, гарәп сүзләренең гамәлдәге татар язуына ялгыш күчерелүе электән дәвам итеп килә һәм, кызганыч ки, ишәя генә кебек. Сүзләрне һәм атамаларны гарәп хәрефле текстлардан ялгыш тану һәм хәзерге басмаларда хаталы итеп тәкъдим итүләрнең бер өлеше палеографик үзенчәлекләрне белмәүдән, аларны бутаудан яисә исәпкә алмаудан килеп чыкканлыгы ачык күренә. Аерым хезмәтләрдә исә башка төрки кардәшләрнең фәнни әдәбияты тәэсире дә сизелгән кебек.

Түбәндә андыйларны китапларның басылган еллары буенча хронологик рәвештә тәкъдим итәбез. Таблицаларда аерым китаплардагы һәм мәкаләләрдәге хаталарның бер өлеше урын алды, кайбер таблицаларның ахырында аңлатмалар бирелде. Мисаллар алынган басманың китап тексты ахы-

рында китерелгән исемлектәге тәртип саны күпчелек очракта «чыганак һәм бите» графасында квадрат җәяләр эчендә күрсәтелде.

***

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *чыганак һәм бите* |
|---|---|---|
| Иске Әҗем | Иске Өҗем | [52] 171 бит |
| Ат Җитәр | Атҗитәр | 214 бит |
| Әл-Әрбәшчи | Әр-Ырбишчи | 215 битәр |
| Әчкен | Эчкен | 248, 276 битләр |
| Әйсак | Исак | 301, 330 битләр |
| Әл-Ишкени | Әл-Әшнәки | 302 бит |
| Әл-Антави | Әл-Әтнәви | 316 бит |
| Бүкәли | Пүкәли | 286, 337 битләр |
| Башад (Сергач өязендәге Башад) | Пашат | 393 бит |
| Җаникъ Шашы | Җаның Шашы | 276 бит |
| Минкәри | Миңгәри | 300 бит |
| Әш-Шәншәкәри | Әш-Шеңшеңәри | 352 бит |
| Иске Рәҗ | Иске Рәч | 349 бит |
| Лаз | Лаж | 247 бит |
| Бур | Бөр | 352 бит; елга исеме |
| Сафар | Сәфәр | 278 бит |
| Симак | Симәк | 288 бит |
| Үтай | Үтәй | 284 бит |
| Бимаҗ | Бимәч | 289 бит |
| Тимай | Тимәй | 289 бит |
| Мемтай | Мәмәтәй | 305 бит |
| Бикай | Бикәй (Бигәй) | 315 бит |
| Әснай | Исәнәй | 386 бит |
| Мөхәммәд Әмин | Мөхәммәдәмин | 284 бит |
| Мәску | Мәскәү | 289 бит |
| Миңлегөл | Миңлегол | 307 бит |
| Габделмансур | Габделмөсаувир | 316 бит |

Югарыда күрсәтелгән атамалардан «Бүкәли» (дөресе – Пүкәли) дигәне гарәп язулы төп чыганакта «п» хәрефе урынына «б» язылганнан килеп чыккан. Әмма Татарстанның Саба районындагы әлеге авыл исеме элек-электән Пүкәл буларак мәгълүм. Шуның кебек үк «Сергач өязендәге Башад» атамасы да чынбарлыкта Пашат исемле авыл. Ш.Мәрҗани китабының гарәп хәрефле басмасында Ашыт авылы да «Ашыд» дип бирелгән, әмма хәзерге чорда нәшер ителә торган хезмәтләрдә андый исемнәрне «б» һәм «д» хәрефләре белән бирү мәгъкуль түгел. Шул ук хезмәтнең 1989 елгы басмасында 218 биттәге «Нижний өлкәсе Намика авылы» дигәндә «өлкәсе» урынына «губернасы» булырга тиеш. «Намика» атамасы әсәрнең иске басмасында шул рәвештә ялгыш бирелгән булса да, аның дөресе «Камка» икәнлеген ачыклау читен түгел. «Миңгәри» нисбәсендә «г» хәрефенең һәм «Шеңшеңәри» дигәндә «ң» хәрефенең гарәп язулы текстта «кәф» белән бирелгән булуларыннан ялгышлык килеп чыккан. Әмма бу атамаларның (Татарстанның Саба һәм Балтач районнарындагы авылларның) дөрес язылышларын бөтенләй мәшәкатьсез ачыкларга мөмкин иде. «Иске Рәч» авылының исеме дә «Иске Рәҗ» дип – төп чыганакта «ч» урынына «җ» хәрефе язылганнан киткән элементар хата.

Китапта (1989 елгы басмада) «Бәрәңге ягыннан, Лаз исемле авылдан» дип бирелгән атама әлеге әсәрнең 1900 нче елда чыккан текстында да шулай ук басылган. Ләкин иске басманың ахырында – 366 битендәге төзәтмәләр сәхифәсендә «Лаз» дип басылган атаманың дөресе «Лаж» икәнлеге искәртелгән. Кызганыч ки, 1989 елгы басманы хәзерләгәндә андый төзәтмәләргә әһәмият бирелмәгән. Саф гарәп әлифбасында һәм телендә «ж» авазы-хәрефе юклыктан, иске текстларда аның урынына «зә» хәрефе язылган очраклар булган. Соңгы елларда басылып килә торган хезмәтләрдә дә «Әл-Лази» дигән ялгыш язылыш-

лы нисбәнең бөтенләй «Лари» дигән бозык язылышы да очрап тора. «Лаж» авылының исеме чынлыкта «Лаш» (Олаш) дигән төрки-татар атамасы, ә аның «ж» белән язылуы русча документларда теркәлүенә карап кулланылышка кергән. Бу җәһәттән ул «Иш» дип аталган елганың «Иж» дип рәсмиләшүе, шулай ук Ишбулат, Ишбирде кебек татар исемнәренең Ижбулат һәм Ижбирде дип үзгәрүләренә охшаш. Татар тарихына багышланган хезмәтләрдә «Лаж» («Лаз») атамасы, күпчелек очракларда XIX гасырда Казанда мәшһүр мөдәррис һәм имам булган Исхак бине Сәгыйть белән аның улы Сәләхетдин бине Исхак турында язганда искә алынган. «Сафар», «Бикай», «Үтай» кебек басылган исемнәр гарәп язулы төп чыганакта «ә» хәрефләре «әлиф» белән бирелгән булуына һәм аның «а» авазын гына белдерә алуы мөмкин дип ялгышканнан чыккан.

***

1802 елда Казанда басылган китаплар исемнәренең бик бозып бирелгән мисаллары түбәндәгечә:

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *чыганак һәм бите* |
|---|---|---|
| Пиркули китабы | Пиргули китабы | [26] 189 бит |
| нүреннәҗат | Фәүзен-нәҗат | 189 бит |
| сөбагателгаҗизин | Сөбател-гаҗизин | 189 бит |
| эстваны | Устуани | 189 бит |

***

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *чыганак һәм бите* |
|---|---|---|
| Гомәр Разыйулла Ганә | Гомәр (разый Аллаһу ганһә) | [18] 28 бит |

***

Шагыйрь Колмөхәммәднең бер шигырендәге «Фи бәйан хакел-зәүҗә галиел-зәүҗәтә» (астөшермәдә мәгънәсе: хатын-кыз хакы бәянында һәм хатын-кыз бөеклеге) [77, 239] дип бирелгән гарәп телендәге атаманың дөресе: «Фи бәйани хаккыль-зәүҗи галәл-зәүҗәти» (Ирнең хатынга хакы турында).

***

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *чыганак һәм бите* |
|---|---|---|
| ила | илә | [57] 55 бит |
| чөнкә | чөнки | 68 бит |
| бергә | бер ки | 87 бит |
| йараббена | Йа Раббәна | 87 бит |
| белде | булды | 91 бит |
| йөзмере | йәэмүре | 176 бит |
| берла | берлә | 182 бит |
| йәнаша | йәнәшә | 211 бит |
| кот | куәт | 224 бит |
| худның | ханның | 224 бит |

Шул ук китапның искәрмәләрендә гарәп хәрефләре турында шактый примитив сыйфатлаулар булганлыгын да искә алу зарар итмәс. Чөнки аларга охшаш аңлатмалар соңгы чорда да күренгәли. Әлеге китапта (311 биттә): «Бу сүз өстән өч төрткеле «са» хәрефе белән язылган», «син (өч тырма тешле)...». Менә бу хәрефләрне башкачарак та тасвирларга (мәсәлән, «төртке» диясе урынга «нокта» дип) һәм, гомумән, хәрефләрнең гарәпчә язылышларын бирергә мөмкин иде. Монда күрсәтелгән ялгышлар һәм, гомумән, китаптагы барлык хата-кимчелекләр автор әсәрләренең 2021 елгы басмасында да кабатланган.

***

Төрки телләрдә басылган кайбер хезмәтләрнең татарча чыккан китапларга йогынтысы тоемланган берсен искә алыйк.

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *чыганак һәм бите* |
|---|---|---|
| вуслат | восләт | [70] 78 бит |
| Нәһл | Нәхел | 152 бит, сүрә исеме |
| муракабә | моракабә | 237 бит |
| Али Имран | Алү Гыймран | 268 бит,<br>сүрә исеме |
| Гөнәйд | Җүнәйд | 13, 284 битләр |
| укъба | гокба | 290 бит |

***

Казанда 2000 елда чыккан «Бакырган китабы» текстын укып чыккач та Үзбәкстанда 1991 елда басылган «Бокиргон китоби»ның йогынтысы булганмы әллә дигән уй башка килә. Һәрхәлдә, Казан басмасындагы «совет, һовл, нув, минг» [14, 101, 122, 127, 218][3] кебек сүзләр татар текстологиясендә һәм сүзлекләрдә «саут, һәүл, нәү, мең(?)» дип бирелә иде.

Бу китаптагы башка ялгышлыкларны да күздән кичерик:

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *бите* |
|---|---|---|
| белмин | белмәйен | 30 бит |
| кылмассен | кылмассән | 44 бит |
| алмассен | алмассән | 44 бит |
| сокланып | шәвекъләнеп | 49 бит |
| тапмаен | тынмаен | 49 бит |
| Шәбләй, Җәнид | Шибли, Җүнәйд | 58 бит |
| богаты | ботагы | 189 бит |
| татаин | татайын | 209 бит |
| күрәин | күрәйен | 209 бит |

[3] Бәлки, мондый рәвештәге язылышлар фарсыча-русча сүзлек тәэсирендә булгандыр?

| | | |
|---|---|---|
| бирәин | бирәйен | 209 бит |
| аер син | әййүрсән | 210 бит |

Шул ук китапның 74 нче битендәге «Мәнзурйанлыг булыбән / Дарда мәҗлес корсам мин» строфасындагы беренче сүзгә карата «максатчыл» дип бирелгән аңлатма дөрес түгел. Чөнки «Бакырган китабы»ның иске басмаларында ул «Мансур йанлыг» (Мансур кебек) дип басылган һәм бу очракта суфичылык каһарманнарыннан Мансур Хәлляҗ шәхесе күздә тотылган. Әлеге китап текстында «ирән» сүзенең «әйран» дип бирелеше дә аптыраш тудыра. Чөнки асылда «ирән» дигән сүзнең кайбер сүзлекләрдә ялгыш варианты (әйран) басылганлыгы белгечләргә мәгълүм. Китапның 32 нче битендәге «Шәйхем утынга изсә» дигән гыйбарәдәге «изсә» сүзе «изү» мәгънәсендә түгел, дөресе «изесә» (җибәрсә, юлласа). Шул ук сүзгә («эзди») 27 биттә бирелгән «бар итте, бирде» дигән аңлатма да ялгыш. 64 биттәге «өезге санма» дигән сүзләр иске басмаларда «үзенгә изге санма» дип бирелгән. Китапның 71 нче битендәге «монча ятыбың бетте» гыйбарәсе («ятыбың» сүзенең мәгънәсе «ятывың» диелгән – күрәсең, «ятуың» тиеш булгандыр) дөреслектә «монча ятып нәң бөтте», ягъни – «болай ятып нәрсәң артты». 87 биттәге «илтеп күмәр илем хишем» сүзләрендәге «хишем» дигәненә карата бирелгән «үземне» дигән аңлатма дөрес түгел. Чынлыкта, фарсы телендәге «хишем» татар телендәге «ишем» (якыннарым) дигәнне белдерә.

«Бакырган китабы»ның (2000) 96–97 битләрендә ун строфаның ахырларында «Тән-җан берлә һуһудай» гыйбарәсе кабатланган һәм «һуһудай» сүзе «һөдһөд – ябалак кебек» диелеп, мәгънәсе аңлаешсыз бер нәрсә килеп чыккан. Дөресе исә «Тән-җан берлә «Һу», «Һу» ди!» булырга тиеш иде. «Һу» (Ул) сүзе бу очракта Аллаһы Тәгаләне белдерә. Китапның 226 нчы битендәге «Килеп, Дөлдөл

яшар түбән күзене» дигәндә соңгы ике сүз чынлыкта бер – «яшәртүбән» (яшәртеп, яшьләндереп) сүзе. Аңа охшаш гыйбарәләр бу китапта (мәсәлән, 68 биттә) «әлиф» хәрефен «ә» дип укыйсы урында «а» белән «ултырыбан, килтеребан, теләйебан» рәвешләрендә тәкъдим ителгән. Шундый ук сәбәптән («әлиф»не «а» дип танудан), «үләр, үлмәс» сүзләре китапның 60 битендә «үлар, үлмас» дип бозып бирелгән. Китаптагы «алубәни, алыбәни, ярыбани» (172, 178, 186 битләрдә) язылышлары дөреслектә «алып аны, ярып аны» булырга тиешле иде.

***

Борынгы бер әсәрнең 2002 елда чыккан басмасына [3] игътибар итик.

| *хаталы (төрлечә) басылган* | *дөресе* | *бите* |
|---|---|---|
| «Ихъяул-гулум», «Ихъйаул-гулум», «Әхйаул-гулум», «Әхйа’у-л-гулум» | «Ихъйаэл-голүм» | төрле битләрдә |
| «Тәнбиятул-гафилин» | «Тәнбиһел-гафилин» | 10 бит |
| Абул-Лейси Самарканди, Абул-Ләйси | Әбелләйс Сәмәрканди | 10, 329 битләр |
| Абдуллаһ, Габдуллаһ, | Габдулла | 36, 43, 68 битләр |
| Абу Бәкер | Әбүбәкер | 37 бит |
| Абу Мугид | Әбү Могыйд | 36 бит |
| Аби Сагид | Әбү Сәгыйд | 47 бит |
| Мөслим бер Йасар | Мөслим бине Йасар | 208 бит |
| тез казнасы | теш казнасы | 290 бит |
| Абу әл-Галаи | Әбелгалә | 319 бит |
| Хәсән Басыйр | Хәсән Басрый | 319 бит |

| | | |
|---|---|---|
| Абу Җаһил | Әбүҗаһил | 319 бит |
| Фузаил | Фөзаил | 335 бит |
| Әнәси бине Мәлики | Әнәс бине Малик | 368 бит |
| Габдулгазиз | Габделгазиз | 372 бит |
| кәйфийт | кәйфият | төрле битләрдә |
| мәсәлә | мәсьәлә | төрле битләрдә |
| дарул-фәнәдин | дарел-фәнадин | төрле битләрдә |
| мукабила | мокабәлә | төрле битләрдә |
| муфид | мөфид | төрле битләрдә |
| мукаррар | мокаррар | төрле битләрдә |
| муталлиг | моталлигъ | төрле битләрдә |
| мусанниф | мосанниф | төрле битләрдә |
| бисми | би-исми | төрле битләрдә |

Бу китаптан алып таблицада күрсәтелгән хата дигәннәребезне һәм монда әйтелмәгәннәрен гомуми күзаллаганда, соңгы заманда төрки телләрдә басылган башка хезмәтләрнең йогынтысы булганлыгы сизелеп тора.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсендәге кулъязма истәлекләрдә Мәхмүд Болгариның «Нәһҗелфәрадис» әсәреннән күчерелгән өземтәләр барлыгы турында матбугаттагы мәкаләләребездә язып килә идек. Тик бу факт шушы әсәрнең 2002 елда дөнья күргән басмасындагы кереш мәкаләдә һичничек искә алынмаган.

***

Мәскәү тарихчыларының берсеннән 2001 елда «Гасырлар авазы» журналында бастыру өчен 1657 елгы хатка багышланган мәкалә килгәч, әлеге басманың җаваплы хезмәткәрләре редакцияләү өчен без фәкыйрегезгә мөрәҗәгать иткәннәр иде. Хат текстының яхшы сыйфатлы факсимилесе белән чагыштырып чыгу һәм аңа төзәтмәләр кертү кыенлык тудырмады. Хәзерге хәрефләргә күчерелгән татарча текстта орфографик хаталар да, дөрес укылмаган

сүзләр һәм аларга бәйле ялгыш аңлатмалар да табылуы гадәти күренеш. Әмма Мәскәү галиме С.Фәизов Казан төзәтмәләренә риза булмады. Шул сәбәпле, журналда бу материал төзәтмәләрсез басылып чыкты [30]. Хаталарының кайберләреннән *«ирдән, азатлы, галимәтле, ителенерсә, лилля тәгали, бәлясез, ярсын, куввә шәкайсыз»* сүзләре дөреслектә *«йирдин, гыйззәтлү, гали һиммәтле, улынырса, Лилләһи Тәгалә, беләсез, йа Рахман, кавышкайсыз»* икәнлеген искәртү белән чикләнәбез.

***

Тәфкилевләр нәселенә багышланган бер мәкаләдә Йосыф Тәфкилевнең кызларыннан «Сара-Бәнат, Котлызаман-Бәнат» телгә алынган [28]. Бу исемнәр тарихчы Ризаэтдин Фәхретдиннең «Шура» журналындагы (1915, №2, 36 бит) «Сәлимгәрәй мөфти Тәүкилев» мәкаләсендәге «Сара бинте Йосыф, Котлугзаман бинте Йосыф» (ягъни, Сара Йосыф кызы, Котлугзаман Йосыф кызы) дигәндәге «бинте» сүзен «бәнат» дип укудан хасил булган.

***

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *чыганак һәм бите* |
|---|---|---|
| Иклек би | Игелек би | [4] 106 бит |
| Мең әйләвеның | Мең илүенең (иленең) | 117 бит |
| Әл-хөкем Аллаһ, әл-гали, әлкәбир<br>Көлли нәфси диакати<br>Әл-мәүвте сәм әлинә тәрҗигун | Әл-хөкме Аллаһи әл-Гали әл-Кәбир<br>Көллү нәфсин заикатил-мәүт сүммә иләйна түрҗәгунә | 230 бит |
| мәтүфи | мөтәваффа | 301 бит |

## Письмо Кучукая Сакаева Абдулле Байцину

"Ху[1]

Би-инайат раббиль-галямин[2].

Ерак ирдән якын көнел берлән азатлы вә хөрмәтле, вә галимәтле кәрендәшемез Абдулла Билялаевич хәзрәтләрен Кучукайдин чокдин чок догалар кылыб, сәләм-сәләмләр ирдезәмездер ки, рухым восулында кабул боерылыр. Саниян, Юлдашыгыз вә кәрдәшегез, вә җөмлә оныздa, үзегездә калган йөсерләренез, бары җәмагатыгыз сезләрнен догагызның бәрәкәте илән, әлхәмде лилля, шөкер торадардыр. Абдулрахим йомышка китти, Полежаевны ебәрделәр, Мирзагильди алар берлән китте[3]. Вә бәгдә, Әгәр лөтыйф-җаныгыз улыб, бу җәнаб әхвәлендән сөәл шәрифыгыз итеденерсә, бихәмде лилля, тәгали һәм галигыз бәрәкәтендә мөбәрәк зу-ль-каада айның әввәлендә, дүшәнбе көнендә[4] саг в сәлим бәлясез. бакый әмир-әфәнде[5] мөкәррәр, иншалла, ярсын мөбәрәк, дидар шәриф[6] [...] Аллаһ-тәгалә хәзрәтләре мөйассер кыла в хәсрәтегезгә, куввә шөкайсыз, амин ярыб, илхамыз. Даги, кәрендәшемез Абдулла, җөмләмезгә Аллаһ-тәгаләнен бер тәкъдире булды. Абриль айның игерме икенче көнендә, чәһаршәмбә көндә Кадашовтан ут чыгыб, җөмлә эвләремез калмай, янды вә үзләремез көч илән уттан әсбабларымыз берлән качыб котылдык. Вә андин сонра янган сәбәбле чок заман баш ордык. Шул укка бер унар сум җөмләмезгә бирделәр, вә сезнең юлдашыгыз бер горнича Панасий[7] берлән ун биш сумга алыб салдылар. Бикеләрдә ул хәлдә Мәскәүдә иде. Даги ярлыкаб, ул будыр. Алардай [дәфтәр] мәтагларыгызны алгайсыз. Җөмлә ашларыгызны һәм акчаларныда алгайсыз. Мәгәр, акча житмәсә, ул кадәр акча кушкайсыз. Даги, бен сезгә Терентий телмач[8] берлән бер золатой[9] ебәрдем. Бер илле акчалык шәфагать[10] итеб [...] алгайсыз. Даги бер оч айгы курашлык[11], ярбакыр манет[12], алгайсыз [...]

РГАДА. Ф.119. Оп.2. Ед.хр.14. Л.154.

## Перевод

Он.

Милостью владыки миров.

Из далекой земли с близкой душой благородному и почтенному, и ученейшему брату нашему, Абдулле Билялаевичу, их превосходительству, со многими молитвами наши приветствия. Пусть сбудется желаемое от души моей. Во-вторых. Спутница Ваша и домочадцы, и все имущество, что осталось в уделе Вашем и непосредственно у Вас, все, чем Вы обладаете, благодатью Ваших молитв, хвала Аллаху, благополучно пребывают. Абдулрахим уехал с порученцем, Полежаева отправили, Мирзагильди уехал вместе с ними. И затем, если, проявив любезность души Вашей, спросите с высоты своего благородства о состоянии дел в этой стороне, во славу Аллаха, благодаря мудрости Всевышнего и Великого, в начале благословенного месяца зу-ль-каада, в понедельник, остающийся в здравии



«Гасырлар авазы» журналының 2001 елгы 1/2 саны

Китапның 79 битендә «Тәбәрле Чаллысы» дигән атама язылган булса да, андый исемле авыл элек тә булмаган һәм хәзер дә юк. Ә аерым Тәбәрле (Әгерже районында) һәм Тәберде Чаллысы (Балык Бистәсе районында) авыллары бар.

***

Рус һәм Европа сүзләрен, шулай ук кеше исемнәрен язганда «е» һәм «э» хәрефләре иске татарча текстларда «һаи рәсмия» ه ـه хәрефләре белән теркәлгән. Шундый үзенчәлекнең исәпкә алынмавы сәбәпле, хәзерге татарчага күчерелгән текстларда еш кына хаталар пәйда була. Мәсәлән, Һади Такташ әсәрләренең 2010 елда басылган өч томлыгының өченче томында француз сәясәтчесе Пуанкаре фамилиясе «Пуанкарә» [74, 160, 301] дип бирелгән, ә 1 нче томында [73, 393] дөрес басылган.

Гаяз Исхакыйның рус әдибе Лев Толстой турында язган мәкаләсендәге «...һәр ләфнәк(?) дә арыслан булмаганын...» [55, 326] дигән өзектәге «ләфнәк» сүзенең дөресе – «Левның» дип бирелергә тиеш иде. Бу очракта төп чыганакта «ләм» хәрефеннән соң «һаи рәсмия» һәм ахырдагы «ң» урынына «кәф» язылганлыгы сүзне ялгыш тануга сәбәп булган.

***

Ризаэтдин Фәхретдиннең бик мөһим тарихи хезмәте «Асар»га багышлаган фәнни китаптагы [13] исемнәр һәм атамалар язылышында җибәрелгән хаталарның бер өлешен күздән кичерик. Рус телендәге бу китапның 168 нче битендә 3 нче кушымта итеп, «Асар»ның 1 нче һәм 2 нче томнарыннан алып, мәдрәсәләр урнашкан авыллар һәм төбәкләр исемлеге бирелгән. Исемлекнең татар телендә бирелүенең сәбәбе итеп бик күп торак пунктларны рус телендә тәгаенләп бул-

мавы искәртелгән[4]. Әмма татарча диелгәне дә төгәллектән ерак шул.

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *бите* |
|---|---|---|
| Ачули авылы | Ачулы авылы | 168 бит |
| Бикяш авылы, Динәс | Бигәш авылы, Динис | 168 бит |
| Тимаш, Тыймази | Тимәш, Туймазы | 168 бит |
| Буби, Ижбубый | Бубый, Иж-Бубый | 169 бит |
| Букай иле | Бүкәй иле | 169 бит |
| Бури мозафаты | Бөре мозафәте | 169 бит |
| Туйми, Исяк, Йултимер | Туймы, Исак, Юлтимер | 169 бит |
| Әлги, Тәнки (Тәнәки) | Өлге, Тенеки | 169, 171 битләр |
| Камәргуҗа, Кушар | Комыргуҗа, Күшәр | 170 бит |
| Мәндеш, Нурма | Мөндеш, Норма | 170 бит |
| Мазар баш, әл-Мәнгари | Мазарбаш, әл-Мәнгәри | 170 бит |
| Кашкар, Кәвам, Күк Тәкә | Кышкар, Күәм, Күктәкә | 171 бит |
| Киук, Шытчы, Мәчтай | Көек, Шәдче, Мәчти | 171 бит |
| Шәгай | Шыгай | 171 бит |
| Йулук, Радут, Салагуш | Юлык, Редут, Салагыш | 172 бит |
| Казаклар урисы | Казаклар Орысы | 172 бит |
| Тануп | Танып | 172 бит |
| Мәраса, Йәргян | Мораса, Йиргән (Җиргән) | 174 бит |
| Утак, Яңа Кашир | Үтәк, Яңа Кәшер | 174 бит |
| Яңанадыр | Яңа Нәдер | 174 бит |

[4] Китапның үзендә болай диелгән: «Указатель составлен на татарском языке, так как многие названия населенных пунктов трудно идентифицировать на русском языке».

***

Бер мәкаләдә Чистай зиратындагы 1912 елгы кабер ташына уелган исем «Исхак Туфит хатыны»[10, 20] дип ялгыш бирелгәнлеген искәртик. Бу очракта «Туфит» дигәне кеше исеме түгел, ә гарәп телендәге «түвүффият» (вафат булды) – хатын-кыз җенесенә карата әйтелгән сүз. Чынлыкта, ул кабер ташында гарәп телендә уелган мәрхүмәнең исеме – Бибизөһрә Садыйк кызы, Исхак хатыны.

***

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *чыганак һәм бите* |
|---|---|---|
| калдыйкә | калды ки | [5] 11 бит |
| Атыш елгасы | Ашыт елгасы | 152 бит |
| Җөри улы[5] | Җөри юлы | 218 бит |
| дийүвинә | диюенә | 336 бит |

***

«Асар» хезмәтенең бер китап булып басылган 3 нче һәм 4 нче томнары [83], ни кызганыч, хаталар белән тулган.

Китапның керешендә «Басманың теле мәгълүм дәрәҗәдә хәзерге әдәби тел кагыйдәләренә яраклаштырып һәм шул ук вакытта, мөмкин булган кадәр, авторның стиль нечкәлекләре сакланган хәлдә бирелә» (4 бит) диелгән. Автор текстының беренче җөмләсе мондый: «Малмыж мозәфәте Түнтәр карьясендә имам вә мөдәррис һәм дә мөхтәсиб гонванында мәншүр сахибы булып...» (16 бит) рәвешендә. Әлеге өзектәге кайбер сүзләрнең мәгънәләре астөшермәдә бирелгән, ләкин *мозәфәте, карьясендә, гонванында, сахибы* сүзләренең аңлатмалары юк. Китапның бөтен тексты шушындый табышмаклар белән тулы – сүзләрнең бер өлешенә тәрҗемә-аңлатмалар бирелсә дә, байтагының аңлатмасы язылмаган.

[5] Китапта болай бирелгән: «Сөләйман Манашевның улы Йосыф Җөри улы Чаллы Казаклары авылында утар торткан».

| *хаталы басылган* | *дөресе* | *бите* |
|---|---|---|
| Җәляледдин әд-Дивани | Җәлаледдин әд-Дәвәни | 20 бит |
| Шәрех Гале әл-кари... | Шәрхе Гали әл-Карый... | 22 бит |
| Мәктубат әл-имам Рәбахи | Мәктубател-имам Раббани | 23 бит |
| Муаййддин, Мухйиддин | Мөхеддин | 25 бит |
| Габдерризак | Габдерраззак | 33 бит |
| Шириздан | Ширияздан | 36 бит |
| имаз, итәс | имәс | 49, 455 битләр |
| Галя авылы | Галә (Гали) авылы | 50 бит |
| көнһ | кинә | 51, 465 битләр |
| истер, яхүд | истәр (эстәр), яхуд | 55 бит |
| Кинәле, Кинале | Кенәле | 62 бит |
| Галикай, Галикяй | Галикәй | 64, 440 битләр |
| Лази, әл-Лази | Лажи, әл-Лажи | 65, 503 битләр |
| Габделгалям | Габделгалләм | 66 бит |
| бина галәйһи, бинаэ галәйһи | бинаән галәйһи | 67, 179 битләр |
| гөррә | горрә | 67 бит |
| Җамалетдин бине Бикяш әш-Шатаҗы әс-Суни | Җамалетдин бине Бигәш әш-Шәтчи әс-Сони | 67 бит |
| Габделзаһир | Габдеззаһир | 67 бит |
| Бәнйамин | Бинияминн | 70 бит |
| Һәди әл-Килми | Һади әл-Килеми | 76 бит |
| Мәнасиб | Монасыйб | 84 бит |
| Әби Бәкр, Әбубәкер | Әбүбәкер | 84, 90 битләр |
| Әш-Шонкари, Шоңар | Әш-Шыңари, Шыңар | 85, 336 битләр |
| Хәбибрәхмән, Тәмай | Хәбибрахман, Тәмәй | 87 бит |

| | | |
|---|---|---|
| Әл-Кышкый | Әл-Кыешкый | 89 бит |
| Әл-Карабашы | Әл-Карабашый | 89 бит |
| Кайбычы | Кайбычи | 90 бит |
| каляме | каләме | 95 бит |
| Кенәри | Кенәри | 97 бит |
| Кашкари, әл-Кашкари | Кышкарый, әл-Кышкари | 97, 284 битләр |
| Тумани, Габделваххаб | Төмәни, Габделваһһаб | 104 бит |
| Туляк | Түләк | 106 бит |
| Утыз Имьни | Утыз Имәни | 107 бит |
| Чокри, әл-Чокри | Чокрый, әл-Чокрый | 110, 399 битләр |
| Утакол, Иштиряки | Үтәкол, Иштирәки | 111 бит |
| Иске Җәләби, Бәрнак | Иске Җөлби, Борнак | 111 бит |
| Давид, Давыд | Дауд | 111, 138 битләр |
| Чәти авылы | Чыты авылы | 111 бит |
| Әл-Әчкәни | Әл-Эчкени | 112 бит |
| Әл-Букалы | Әл-Пүкәли | 112, 491 битләр |
| Кичу авылы | Кичү авылы | 113 бит |
| Зиминчә, Зимәнчәви | Зимничә, Зимничәви | 114, 500 битләр |
| Әл-Әшкарави | Әл-Ишкарави | 116 бит |
| Нүнгәр | Нөнәгәр | 119, 515 битләр |
| Байлар Сәрдәке | Байлар Сәрдеге | 122 бит |
| Мәфрәхә, Мәфлихә | Мөфәррихә, Мөфлихә | 122 бит |
| Нәрсе | Нырсы | 123 бит |
| Әл-Әткули | Әл-Этколый | 124 бит |
| Тәмтәк, Тәмтак | Тымытык | 124, 447 битләр |
| Салихшакол | Салих Шакул | 129 бит |
| җәһхәт | җәһәт | 130 бит |
| ляф | лаф | 134 бит |
| Миңаубай, Чагыдайи | Миңлебай, Чыгадайи | 135 бит |

| | | |
|---|---|---|
| Мәсгүд, Мәсәгад | Мәсгуд | 135, 266 битләр |
| Зәһра | Зөһрә | 137 бит |
| Хәҗәтелхәким | Хөҗҗәтелхәким | 143 бит |
| Әл-Кәвами | Әл-Куәми | 145 бит |
| «Мәшәкате шәриф» | «Мишкяте шәриф» | 146 бит |
| Чәсәнбә мәдрәсәсе | «Хөсәения» мәдрәсәсе | 148 бит |
| Кывак елгасы | Куак елгасы | 149 бит |
| Кушкати | Көшкәти | 150 бит |
| «Мишәкател-мәсабих» | «Мишкятел-мәсабих» | 150 бит |
| Кран авылы | Каран авылы | 155 бит |
| Фәрнәкстан | Франкистан | 157 бит |
| бойла | бөйлә | 161 бит |
| Алмөхәммәд | Әлмөхәммәд | 163, 269 битләр |
| Мөхийиссөннә, Мәхисөннәт | Мөхиссинә | 163, 238 битләр |
| Бәһаэддин | Баһаведдин | 169 бит |
| Кара Иван | Кыр Айван | 171 бит |
| Мамаширмә, Пошангяр | Мәмәшир, Пешәнгер | 172 бит |
| Кутаймаз, Катаймаз | Котаймас | 172, 438 битләр |
| Пичмән Тау | Печмәнтау | 172 бит |
| Нәса | Носы | 181 бит |
| Хәфыз | Хафиз | 185 бит |
| Каракучек | Каракөчек | 195 бит |
| Тәнәби | Таныбый (Таныпый) | 198 бит |
| хазирләп | хәзерләп | 198 бит |
| Әл-Мәки, Әлмәки | Әл-Мәкки | 201, 256 битләр |
| Әл-Муртышы | Әл-Мортыши | 202 бит |
| «ән-Нәйл» | «ән-Нил» | 204 бит |
| Мәнгари | Мәнгәри | 207 бит |
| Куиш бине Туиш | Коеш бине Туеш | 207 бит |
| тәбәрәкләнү | тәбәррекләнү | 211 бит |

| | | |
|---|---|---|
| Хәсән Гата | Хәсәнгата | 212 бит |
| Әл-Кушари, Кушари | Әл-Күшәри, Күшәри | 214, 233 битләр |
| сатр | сәтыр | 217 бит |
| Аминә | Әминә | 218 бит |
| Корычы | Корычый | 221 бит |
| Талаш | Теләш | 225 бит |
| Әл-Бәйданги | Әл-Бидәнги | 229 бит |
| Комшәханәви | Көмешханәви | 233 бит |
| Кан | Казан | 236 бит |
| Ками Исмаил | Камы Исмәгыйль | 240 бит |
| Ил-Бәк | Илбәк | 242 бит |
| Байтүгял | Байтөгәл | 246 бит |
| Әл-Каширии | Әл-Кәшери | 248 бит |
| Тәмтәкый | Тымытыкый | 251 бит |
| шәрхе муафыйк | «Шәрхе мәвакыйф» | 253 бит |
| сагытчы | сәгатьче | 260 бит |
| Әл-Аждани | Әл-Ыждани | 265 бит |
| әслән | аслан | 266 бит |
| Миргаляэддин | Миргаләведдин | 269 бит |
| Туйми авылы | Туймы | 269 бит |
| Ширдани | Шырдани | 273 бит |
| «Гайнел-галәм» | «Гайнел-гыйлем» | 273 бит |
| Звериный Галяуский | Звериноголовски | 275 бит |
| Гөлвәли | Келәүле(?) | 275 бит |
| анасы Хәсәнҗан | анасы Хөсниҗан | 277 бит |
| Әхмәд-әл-Латыйф | Әхмәделлатыйф | 278 бит |
| Сүнчәле | Сөнчәли | 284 бит |
| Гөтинген | Гюттинген | 292 бит |
| Пәһүпали | Бһопали | 302 бит |
| хәсән хат | хөсне хат | 303 бит |
| Өммикәмал | Өмми Камал | 309 бит |
| Бары тәгалә | Бари Тәгалә | 313 бит |
| Таш Билге | Ташбилге | 316 бит |

| | | |
|---|---|---|
| мәлгүн | мәлгунь | 319 бит |
| Бигяш, Бикәш, Бикяш | Бигәш | 320, 508 битләр |
| шигә | шигый | 321 бит |
| Мәгәри | Мәгарри | 325 бит |
| мокри | мокъра | 329 бит |
| Яхшы Бай, Тәүкә | Яхшыбай, Төке | 333 бит |
| Хөсәен шәех | Хәсәншәех | 336 бит |
| Түнтәргали мәдрәсәсе | Түнтәр Гали мәдрәсәсе | 336 бит |
| Мәчтай, Мачкярә | Мәчти, Мәчкәрә | 337 бит |
| Хәрәмшаһ | Хөррәмшаһ | 339 бит |
| Әл-Кяйнәви | Әл-Гәйнәви | 343 бит |
| Ишале | Ишали | 347 бит |
| Виршавәт | Вершаут | 362 бит |
| Яңа Шәнбәр | Яңа Шинбер | 387 бит |
| Хваризми | Хәрәзми | 392 бит |
| Бурганский | Бораганский | 394 бит |
| Прижевал шәһәре, Йәки | Пржеваль шәһәре, Яке | 396 бит |
| Колындыр, Әстрехани | Каләндәр, Әстерхани | 397 бит |
| Телякайи | Теләкәйи | 398 бит |
| Югары Кадаш, Әл-Курчи | Югары Кодаш, Әл-Корычи | 399 бит |
| Хәсәнгали | Хәсән Гали | 405 бит |
| битләр | бәйтләр | 407 бит |
| Бурҗан, Бәрҗан | Бөрҗан | 409, 415 битләр |
| Әл-Йулкый, Йулки | Әл-Юлыкый, Юлыкый | 416, 418 битләр |
| Кәшкат Баш, Кәшкят Башы | Көшкәтбаш | 412, 452 битләр |
| Нәркарә | Нөнәгәр(?) | 412 бит |
| Камаш заводы | Кокшан заводы | 421 бит |

| | | |
|---|---|---|
| Тунгавир | Тәнгәүр | 422 бит |
| кадерел-халь | кадәрил-хәл | 426 бит |
| Тимас | Темәс | 429 бит |
| шаид | шайәд (шаять) | 429 бит |
| Дәвкай | Дәүкәй | 440 бит |
| әһле каблә | әһле кыйбла | 456 бит |
| Челепи | Чәләби | 461 бит |
| ни яза юк | ни язаек | 466 бит |
| Мөхәммәдгомәри | Мөхәммәд Гомәри | 483 бит |
| Җәблистан | Җәбәлстан | 486 бит |
| Тәлкашый | Талкыши | 487 бит |
| «Милек» сүрәсе | «Мөлк» сүрәсе | 488 бит |
| сәммел-Бәйтамани | сүммә әл-Битамани | 489 бит |
| Хөсни | Хысна (Кысна) | 489 бит |
| Зәйнитулла | Зиннәтулла | 490 бит |
| Әфлятун әл-Балтачы | Әфләтун әл-Балтачый | 490 бит |
| Кече авылы | Кәче авылы | 491 бит |
| Әл-Лабыты, Әл-Әләти | Әл-Лабити, Әл-Алатый | 492 бит |
| Бәрбаши | Бөрбашый | 493 бит |
